Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ
Центр истории и теории национального
образования им. Х.Фаезханова

# ПРЕПОДАВАНИЕ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ В СИСТЕМЕ СРЕДНЕГО И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ:

## ИСТОРИЯ, СОВРЕМЕННОСТЬ И ПЕРСПЕКТИВЫ

Материалы региональной научно-практической
конференции, посвященной 190-летию
со дня рождения ***Каюма Насыри***

Казань – 2015

УДК 37.02
ББК 74.03
П 72

**Научный редактор:**
кандидат педагогических наук *Гибатдинов М.М.*

**Составители:**
кандидат педагогических наук *Муртазина Л.Р.*,
кандидат филологических наук *Абызова Р.Р.*

**Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы.** Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – 184 с.

**ISBN 978-5-94981-199-3**

© Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015

# I. НАУЧНО-ПЕДАГОГИЧЕСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КАЮМА НАСЫРИ

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

УДК 37.02

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ФӘННИ-МЕТОДИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*mshakurova@inbox.ru*

Татар телен чит тел буларак укыту методикасының фәнни нигезләрен булдыру XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче яртысына карый (К. Насыйри, В.В. Радлов, В.А. Богородицкий, М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов һ.б.). Әлеге чорда төп игътибар телне өйрәнүгә, татар теленә өйрәтүнең максатларына, бурычларына, ысул һәм алымнарына юнәлтелә. Лингвистика, шулай ук методика фәннәренең барлыкка килүе һәм үсеше Каюм Насыйри эшчәнлеге белән бәйле. Аның фикерләре лингвометодика фәне формалашуга хәлиткеч йогынты ясый.

***Төп төшенчәләр:*** Каюм Насыйри, лингвометодика фәне, рус телен укыту методикасы, рус-татар сүзлеге, педагогика, грамматика.

XIX гасыр – мәктәпләр өчен дәреслекләр, үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр язу, сүзлекләр төзү һәм тәҗрибә туплау чоры буларак тарихта билгеле. Бу чорда нигездә рус телендә сөйләшүчеләр өчен кулланмалар дөнья күрә (А. Троянский, М. Казимбәк, С. Кукляшев,

М. Иванов, М. Бикчурин, Г. Ваһапов, Н. Ильминский, И. Кондратов, Г. Мәхмүдов, Г. Фәезханов, К. Насыйри һ.б.). Татар теле Тубыл, Томск, Оренбург, Саратов, Әстерхан, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә укытыла. Яңа белем бирү системасы берберсе белән нык бәйләнгән дүрт баскычтан тора: югары – университет (һәр округта), урта – гимназия (һәр губернада), урталыкта – өязләрдәге училищелар (һәр өяздә берәр), түбән – мәхәллә (шәһәрләрдә һәм авылларда). Казан университеты училищелар, гимназияләр, мәктәпләр ачуга, программалар, дәреслекләр эшләүгә, укытучылар әзерләүгә дә зур көч куя. 1804 елда Устав («Устав учебных заведений, подведомых университетам») басылып чыкканнан соң, яңа типтагы гимназияләр ачыла башлый.

XIX гасырның 60 елларында бер төркем рус педагоглары (П.Г. Редкин, К.Д. Ушинский, А.С. Воронов, Д.Д. Семенов, В.Я. Стоюнин һ.б.) Санкт-Петербургта Педагогик җәмгыять төзиләр, искечә укыту алымнарын, тәрбия чараларын, дәреслекләрне тәнкыйтьлиләр, Россиядә грамоталылык дәрәҗәсе түбән булуны ассызыклыйлар, бигрәк тә авыл җирләре өчен белемле укытучылар әзерләү, алар өчен китапханәләр ачу кирәклеге турында фикерләшәләр, «Педагогик елъязмалар» дигән журнал чыгаралар [1: 7]. Кызганычка каршы, 1879 елда патша хөкүмәте бу Педагогик җәмгыятьне яба.

Татарлар арасында К.Д. Ушинскийның педагогика һәм уку-укыту методикасына караган фикерләрен дәвам иттерүче, татар телен фән буларак мәктәпләрдә өйрәнү кирәклеген пропагандалаучыларның берсе – Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров [2:17]. Ул 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы гаиләдә туган. Ул тәрҗемәче, тарихчы, эпиграфист, тел галиме, лексикограф һәм педагог буларак танылa. Каюм Насыйриның гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарыннан башлана: нәкъ шушы чорда ул төрле уку китаплары һәм дәреслекләр яза башлый. 1860 елда аның «Нәхү (Рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип атала): Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды» дигән китабы дөнья күрә. Үзенең «Фәвакиһел җөләса» хезмәтендә К.Насыйри, татар һәм рус телләренең грамматикасын яхшы белгән мәгърифәтче-укытучы буларак, чагыштырма методка нигезләнеп

болай дип яза: «...Ләкин гайре телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйдатен белмәк зарурдыр» («Фәвакиһел җөләса»). Әлеге дөньякүләм танылган хезмәт бүген дә әһәмиятен югалтмаган.

К. Насыйри XIX гасырның икенче яртысында татар лингвистикасы үсешенә үзеннән зур өлеш керткән галим. XX гасыр башларында татарларга рус телен өйрәтү барышында файдаланылган табигый, тәрҗемәи (чагыштырма), катнаш һ.б. методларга тирән анализ ясаган профессор Л.З. Шакирова тәрҗемәи (чагыштырма) методның нәкъ менә Каюм Насыйрилар заманында ук кулланылышка керүен, аның тарафыннан тәкъдим ителүен ассызыклый [3:5–6].

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында Каюм Насыйриның да роле бик зур. Бу чорда ул татар һәм рус телләрен укытуга сизелерлек өлеш кертә [4: 56]. Духовная семинариядә татар телен укыту белән беррәттән, үзе дә рус телен яхшылап өйрәнә, соңыннан булачак галим Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1889 елда К. Насыйри татарларны русча укырга-язарга өйрәтү өчен «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән. Телгә өйрәтүдә галимнең татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләре дә (1878, 1892) мөһим роль уйный: «Сүзләрне берәм-берәм ятлап, һәрбер ишеткән сүзне исеңдә тотып, берәм-берәм зиһен тубалына тутырырга кирәк. Моның мисалы менә шундый: берәү, бер чиләк алып, урманга җиләк җыярга бара. Иң элек, урман авызына кергәч, чиләгенә бер җиләк өзеп сала. Шулай кичкә чаклы йөреп, чиләген тутыра» («Русча-татарча лөгать»тән) [5: 36].

К. Насыйри әхлак, тәрбия, уку-укыту мәсьәләләрен бер яссылыкта карый («Гыйлемлек вә наданлык», «Ата-ана хакы», «Хәйләкәрлек», «Әдәп» һ.б.). Педагог баланы яшьтән үк акны карадан, яхшыны яманнан аера белергә өйрәткәндә, үсеп җиткәч аңа күпкә җиңел булачагын, тормышта үз урынын, үз юлын дөрес табачагын ассызыклый, «... балалар яшь агач кебектер, яшь агач һәрникадәр кәкре булса да, төзәтмәк асатдыр» («Әхлак рисаләсе», 1890) [5: 38].

1892 елда К. Насыйриның «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре») дигән кулланмасы басылып чыга. Галимнең «Әнмүзәҗ» дигән хезмәтен (1895) шул чорның беренче гыйльми тулы грамматикасы дип атыйлар [6: 57]: «Утыз-утыз биш елдан бирле ике тел фәннәреннән, ягъни үз телебездән вә дәхи рус теленнән балаларга сабак укытканда, хосусан рус телен укытканда үз телебезнең кагыйдәсен бәян кылгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем». Бу уңайдан татар телен гыйльми өйрәнүгә, татар телен укыту методикасын үстерүгә зур өлеш керткән Казан тюркология мәктәбенең ролен дә ассызыкламый мөмкин түгел (В. Радлов, Н. Катанов, Бодуэн де Куртене, В.А. Богородицкий һ.б.).

Россиядә XIX ның ахырына кадәр уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләре буенча проектлар эшләнсә дә, 1917 елга кадәр аларны тормышка ашыра алмыйлар. Балаларны үстерү, аларны укыту, югары тәрбия бирү, ир балалар белән бергә кызларны да мәктәпкә тарту, мәктәпләр төзү, укучыларны ашату-эчертү – рус һәм татар педагог-галимнәренең уртак проблемаларына әйләнә (С.А. Рачинский «Заметки о сельских школах» (1883), Н.И. Ильминский «Казанская центральная крещено-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещеных татар» (1887), В.Д. Сиповский «Чего недостает современной школе», «Чему и как учить» (1895) һ.б.). Болар арасында «аягыма кияргә юк дип укырга йөрмәүче балага кәвеш алып биргән», ач-ялангач шартларда, фатир эзли-эзли, шунда дәресләр үткәргән олы җанлы, белемле Каюм Насыйри да бар.

К. Насыйриның педагогик һәм методик характердагы мәкаләләрен һәм китапларын өйрәнү аны шәкертләрнең психологиясен яхшы белә торган оста педагог, уку-укыту һәм тәрбиягә караган мәсьәләләр белән бик теләп, яратып шөгыльләнгән тәҗрибәле укытучы һәм методист дип таныарга мөмкинлек бирә. Аның лингвистика, методика өлкәсенә караган хезмәтләренең тарихи әһәмияте туган телебезгә, татарча укытуга игътибар бермә-бер арткан хәзерге заманда тагын да ачыграк күренә. К. Насыйри хезмәтләре, грамматика китаплары, сүзлекләре татар телен укыту методикасы өлкәсендә яңа эзләнүләргә этәрә, укытуның эчтәлеген ачыкларга, эш алымнары эзләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Антология педагогической мысли России второй половины XIX – начала XX в. / Сост. П.А. Лебедев. М.: Педагогика, 1990. 608 с.

2. Ханбиков Я.И. История развития педагогической мысли татарского народа. Казань: КГПИ, 1975. 162 с.

3. Шакирова Л.З. Обучение русскому языку в татарской школе: теория и практика. Казань: Магариф, 2002. 191 с.

4. Шакурова М.М. Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. 2010. № 3. С. 207–214.

5. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда: Т. 1. Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. 321 б.

6. Татар грамматикасы: Өч томда: Т.1. М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998. 512 б.

## SCIENTIFIC AND METHODICAL ACTIVITIES OF KAYUM NASYRI

***Shakurova Muslima Magsumovna,***
*Candidate of Philology,*
*Kazan (Volga region) Federal Univercity,*
*mshakurova@inbox.ru*

The scientific bases for teaching of Tatar as a second language was created at the second half of 19th and begining of 20th centuries by K. Nasyri, V.V. Radlov, V.A. Bogoroditsky, M.H. Kurbangaliev, R.S. Gazizov etc. During this period, the focus was on the goals and objectives, methods and forms of learning of Tatar language. Initial milestone of Tatar linguistic and teaching methodology closely connected with the activities of Kayum Nasyri. His ideas have had a decisive influence on the formation of Tatar linguo-methodical science.

***Keywords:*** Kayum Nasyri, linguo-methodical science, methods of teaching the Russian language, Russian-Tatar dictionary, education, grammar.

УДК 81-112

# ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА КАЮМА НАСЫРИ

***Батыршина Гузель Гумеровна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы*
*и искусства имени Г.Ибрагимова АН РТ,*
*guzel_asnur@rambler.ru*

В данной статье впервые исследуется труд выдающегося татарского просветителя, ученого Каюма Насыри «Татарская грамматика, изложенная в примерах» (1860). В статье выделяются и описываются морфологические, синтаксические нормы татарского языка, приведенные в книге.

***Ключевые слова:*** Каюм Насыри, грамматика, татарский литературный язык, грамматические категории, грамматические нормы.

История обучения татарскому языку уходит вглубь веков. В конце XVIII – начале XIX вв. в России этот процесс приобрел научный характер. В связи с этим были изданы различные словари, хрестоматии, пособия по грамматике (авторы И. Гиганов, И. Хальфин, А. Казембек, М. Махмудов, М. Иванов, С. Кукляшев и др.). Среди них выделяются труды выдающегося ученого-просветителя, филолога Каюма Насыри. Во второй половине XIX века он одним из первых начал обучение татарскому языку в русскоязычной среде, а также русскому языку среди татар. Каюмом Насыри «… составлялись учебники для русско-татарских школ, велась агитация за них среди татарского населения. Он сам организовал подобную школу и был ее руководителем» [1: 29]. Ученый-педагог понимал важность и необходимость русско-татарских школ в развитии просвещения татарского народа, «которые способствовали развитию диалога русской и татарской культур в национальном образовательном пространстве» [2: 69].

Первый печатный труд К. Насыри называется «Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах». Он был издан в 1860 году. Следует отметить, что это пособие ранее не изучалось

учеными-лингвистами, имеются лишь его упоминания в отдельных трудах некоторых исследователей [3: 8].

«Краткая татарская грамматика» носит больше практический характер. Она написана как для татар, изучавших русский, так и для русских, изучавших татарский язык. В предисловии к своей грамматике автор сообщает следующее: «На примерах представляю основные правила грамматики татарского языка ... от примеров русский узнает особенности татарского языка, а татарин – особенности русского языка». При таких особенностях языка автор предлагает свои способы его изучения. Также в предисловии К. Насыри дает сведения о татарском языке: то, что он входит в состав тюркских языков, подразделяется на несколько «…наречий, каковы: казанское, мишарское» [4: 2]. Он подчеркивает, что литературный язык сильно отличается от разговорного и характеризует это следующим образом: «Татарское наречие бедно собственною литературою. У татар в употреблении книги, написанные на первых двух наречиях, чагатайском, а особливо турецком. В незначительных сочинениях, составленных татарами в России, язык в грамматических формах представляет смесь форм из двух главных наречий» [4: 3]. Таким образом, «К. Насыри понял такое положение татарского литературного языка, он со всей энергией начинает ему служить» [5: 83]. При таких особенностях языка автор предлагает свои способы его изучения.

«Грамматика» К. Насыри состоит из четырех разделов. В первом разделе, называемом «Письмо и чтение в татарском языке», автор знакомит читателя с алфавитом (имеется в виду татарский алфавит, основанный на арабской графике), дает сведения о татарских гласных и согласных. Особое внимание К. Насыри уделяет позиционным изменениям согласных. Явления протезы, эпентезы и эпитезы, наблюдаемые в звуковой системе современного татарского языка, в грамматике представлены примерами: *булмак-улмак* (быть), *һәйдәмәк-әйдәмәк* (призывать); *олы-олуг* (большой), *эссе-эссег* (жаркий); *сүзләмәк-сүләмәк* (говорить), *үгрәтмәк-үрәтмәк* (учить); *абзар-азбар* (хлев) и т.д. В книге есть примеры на уподобление согласных, т.е. на ассимиляцию: *көнләр-көннәр* (дни), *адәмдән-адәмнән* (от человека), *сумдан-сумнан* (по рублю) и т.п. Достаточно полно автор описывает явление элизии – выпадение одного гласного у двух слов при одном фразовом ударении: *ни эшләмәк-нишләмәк* (что делать), *яңа ай-яңай* (новая

луна). Автор примечает, что ударение в татарском языке падает на последний слог.

Второй раздел работы называется «Лексический состав языка», он посвящен частям речи. Остановимся на некоторых примерах. Как известно, в татарском языке, да и в тюркских языках вообще, нет родовой категории. К. Насыри одним из первых и с уверенностью доказывает отсутствие этой категории и показывает родовое различие при помощи лексических средств: *мужчина – ир кеше, женщина – хатын кеше, петух – әтәч, курица – тавык, голубь – ата күгәрчен, голубка – ана күгәрчен* и т.д.

В отличие от грамматики «Әнмүзәҗ» («Образец»), изданной в 1895 году, в этой работе автор выделяет всего лишь четыре падежа: основной, притяжательный, винительный и два вида направительного. Он правильно отмечает употребление единственного числа вместо множественного в именах существительных: *видел своими глазами – күзем берлә күрдем, купил сапоги – итек сатып алдым* и т.д. К. Насыри, с учетом особенностей татарского и русского языков, показал стилистическую правильность данных выражений.

В «Грамматике» К. Насыри имена прилагательные склоняются как имена существительные, что нехарактерно для современного татарского литературного языка. Необходимо отметить, что автор в своей работе не показал свойственность этого явления только в случаях конверсии. У прилагательных К. Насыри выделяет две степени сравнения: превосходная (*ап-ак – пребелый, туб-туры – прямейший, чәйнең яхшысы алты сум – фунт самого лучшего чая шесть рублей*) и сравнительная (*бүген кичәгедән җылырак – сегодня теплее вчерашнего*). Что касается других частей речи, в частности местоимения, имени числительного и наречия, имеются некоторые расхождения с современным татарским языком. Так, автор грамматики выделяет пять видов местоимений, три разряда числительных и десять видов наречий (некоторые виды местоимений рассматриваются как наречия).

В «Краткой татарской грамматике» К. Насыри достаточно полно показывает все особенности глагола. Категории залога, времени, наклонения, отрицания и утверждения соответствуют нормам современного литературного языка. Еще в то время ученый смог понять семантические и грамматические особенности этих категорий и их показателей. Автор также приводит многочислен-

ные таблицы спряжения глаголов. В них отмечены и аналитические формы типа *язган идем – я писал, язса иде – если бы (он) писал*, позволяющие выразить тончайшие оттенки мысли. Приведено много примеров причастий и деепричастий: *язган – писавший, язар – который будет писать, язуб – писавши, язгунча – до времени писания* и т.д. В этом разделе автор рассматривает и связывающие части речи – послелоги (*өчен – для, за; берлә-белән-билә-илә – с, со*) и союзы (*һәм, дә – и, дәхи – ещё; я, яки – или*), а также некоторые аффиксы в составе послелогов (*чә – до, дән-дин – без, сез – без*).

Третий раздел книги посвящен словообразованию и называется «Флексические формы языка». Здесь автором подробно рассмотрено образование имен существительных, прилагательных, глаголов и приведено множество их моделей. Некоторые примеры: *-кыч/-кеч, -гыч/-геч* (ачкыч, угыч, ургыч); *-ма/-мә* (бүлмә, төймә); *-ын/-ен* (очкын, иген); *-даш/-дәш* (юлдаш, карендәш, сабакташ); *-сыз/-сез* (гакылсыз, тозсыз, тәмсез); *-лы/-ле* (ботаклы, гакыллы, эшле); *-кыч/-кеч* (ерткыч, исерткеч); *-ла/-лә* (котламак, эшләмәк, башламак) и т.д. В основном словообразование соответствует современному татарскому языку. Однако К. Насыри полностью не разделял некоторые суффиксы и формообразующие аффиксы. Например, в словах *язу*, *килү*, *ашамак, язмак* аффиксы *-у/-ү, -мак/-мәк* являются формообразующими, хотя автор рассматривал их как словообразовательные.

Последний раздел «Правила словосочинения в татарском языке» включает в себя основные вопросы синтаксического строя татарского языка. К. Насыри здесь рассматривает виды и типы предложений, главные и второстепенные члены предложения, их взаимную связь и средства связи. Автор выделяет именной и глагольный типы простого предложения, различая утвердительные (*Төн озын*), отрицательные (*Тыкрык тар түгел*), вопросительные (*Кәгазь яхшымы?*) и т.п. предложения. Переходя к сложному предложению, К. Насыри характеризует различные типы придаточных и сложносочиненных предложений, приводит примеры некоторых из них: *Иртәгә барырмын, диде; Имтихан беткәч, өйгә кайткан; Акчасы бар кеше нишләргә белә; Сиңа да, миңа да файда булды; Мин яисә бүген киләм, яисә иртәгә килермен.*

В «Грамматике» К. Насыри примеры взяты, в основном, из разговорной речи, что максимально приближает данный труд к преследуемой автором цели. В качестве иллюстраций Каюмом

Насыри использованы образцы народной литературы, такие как пословицы, поговорки, крылатые выражения, часто употребляемые в разговорной речи того периода. Это в некоторой степени облегчает освоение языка иноязычными.

Таким образом, уже в своей первой грамматике К. Насыри определяет основные вопросы и грамматические категории татарского национального литературного языка. Впервые он теоретически разработал и частично ввел в практику единые фонетико-морфологические, орфографические, лексические и стилистические нормы национального литературного языка. Данная работа Каюма Насыри имела большое значение для своей эпохи в аспекте преподавания татарского языка по грамматическому принципу.

**Литература**

1. Эфиров А.Ф. Нерусские школы Поволжья, Приуралья и Сибири. М.: Учпедгиз, 1948. 278 с.

2. Мухаметшина Р.Ф. Диалог русской и татарской культур в системе литературного образования. Казань: Магариф, 2007. 200 с.

3. Мифтахова И.Г. История татарских грамматик: исследование именных частей речи (XIX – начало XX в.). Ч. I. Казань: Хэтер, 1998. 162 с.

4. Насыри К. Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах. Казань, 1860. 80 с.

5. Закиев М.З. К. Насыри и формирование современного татарского национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976. С. 79–86.

## KAYUM NASYRI'S «TATAR GRAMMAR»

***Batyrshina Guzel Gumerovna,*** *Candidate of Philology,*
*G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,*
*Tatarstan Academy of Sciences,*
*guzel_asnur@rambler.ru*

This article first examines the work of the outstanding Tatar educator, scholar Kayum Nasyri "Tatar Grammar, described in Examples" (1860). The author highlighted and described morphological, syntactic rules of the Tatar language, which was contained in this book.

***Keywords:*** Kayum Nasyri, grammar, Tatar literary language, grammatical categories, grammatical rules.

УДК 339

# ГАБДЕЛКАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БҮГЕНГЕ КӨН ӘҺӘМИЯТЕ

***Шәймәрданов Рәфис Хәсән улы,***
*педагогика фәннәре докторы,*
*Соргыт дәүләт педагогика университеты,*
*rafis55@mail.ru*

Мәкалә Габделкаюм Насыйриның кыскача тормыш юлын һәм киңкырлы иҗади-мәгърифәтчелек эшчәнлеген яктыртуга багышланган. Габделкаюм Насыйри – бик күп фәннәр буенча төзелгән дәреслекләр, уку ярдәмлекләре мөгаллифе, татар телен фәнни нигезгә салып, аның тәгълимати нигезләрен эшләүче, татар милләте тарихын һәм татар халык авыз иҗатын өйрәнүче галим буларак тасвирлана.

***Төп төшенчәләр:*** Габделкаюм Насыйри, мәгърифәтче, язучы, тел галиме, тарихчы, халык авыз иҗаты, мөгаллим, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре мөгаллифе.

Татар милләтенең атаклы галиме, татар мәгърифәтчелегенең иң күренекле вәкилләреннән берсе, киңкырлы гыйлем иясе, язучы, акыл иясе-гуманист, мөгаллим Габделкаюм Насыйри 1825 елның 14/2 февралендә элеккеге Казан губернасы Зөя өязе (хәзерге Яшел Үзән районы) Югары Ширдан авылында укымышлы, алдынгы фикерле Насыйр мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне атасыннан алганнан соң, 1841 елда Габделкаюм Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга керә һәм 15 ел дәвамында гарәп, фарсы телләрен, үзлегеннән рус телен үзләштерә.

Мәдрәсәдән ул пишкадәм (мәдрәсәнең барлык баскычларын үткән һәм мөгаллимлек эшчәнлегенә әзерләү өчен анда калдырылган зат) исеме алып чыга. Мәдрәсәдәне тәмамлагач, ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан университетына йөри, анда рус галимнәре белан элемтәләр урнаштыра. Мәдрәсәдә уку аңа мөселман мәдәниятенең гуманистик фикерләрен өйрәнү һәм әл-Фараби, Әбугалисина, Ибне Рөшд, Алишер Нәвои кебек бөек акыл ияләре

мирасы белән танышырга мөмкинлек бирсә, Казан университетында дәресләр алу һәм рус галимнәре белән аралашу Европа фәненә һәм мәдәниятенә якынаюга юл ача.

1855 елда Габделкаюм Насыйрины христиан руханилары әзерли торган Духовное училищега, ә аннары Духовная семинариягә татар теле мөгаллиме итеп чакыралар. Анда ул 1871 елга кадәр эшли. Духовная семинариядән киткәч, Габделкаюм татар балаларына рус телен өйрәтү мәктәбе ача. 1879 елда мөгаллимлек эшчәнлеген туктата һәм барлык гомерен тулаем фәнгә һәм язучылык эшенә багышлый.

Киңкырлы, энциклопедик белемле галим буларак, Габделкаюм Насыйри татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдыра. Аның игътибарын фәнни проблемалар да, әхлакый, педагогик һәм әдәби-зәвык мәсьәләләре дә җәлеп итә.

Бер яктан – Көнчыгыш мәдәниятен, икенче яктан – Европа фәнни агымнарын яхшы белүе, күпкырлы әзерлекле галим булуы Насыйрига XIX йөздә татар халкы алдында торган мөһим проблемаларны тирәнтен һәм һәрьяклап бәяләргә мөмкинлек бирә. Мәгърифәтченең тикшеренү нәтиҗәләре ул нәшер иткән хезмәтләрдә һәм башка басмаларда киң чагылыш таба.

Габделкаюм Насыйриның 40 лап хезмәте дөнья күрә. Моннан тыш, ул гаять зур кульязма мирас калдыра. Мәгърифәтче галимнең иң күләмле хезмәтләренең берсе – «Фәвакиһелҗөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») китабы. 1880 елда «Кырык бакча» исеме астында ул әлеге әсәрнең кыскартылган вариантын бастыра. Ә 1884 елда Казан университеты нәшриятында китап тулы килеш дөнья күрә. Кырык бүлектән торган бу төпле, зур әһәмияткә ия булган хезмәттә кеше тормышы һәм эшчәнлегенә турыдан-туры кагылышы булган мәсьәләләр яктыртыла, теге яки бу халәттә нишләргә кирәклек хакында киңәшләр бирелә. Куелган һәр мәсьәләне мөгаллиф афоризмнар, мәсәлләр, новеллалар һәм мәзәкләр белән бизәп сурәтли. Һәр бүлек башында күренекле галимнәрнең әлеге мәсьәләгә кагылышлы әйтемнәре китерелә. Китапның соңгы, кырыгынчы бүлеге тел, әдәбият тарихы һәм тәгълиматы мәсьәләләренә багышлана. Әлеге бүлекнең башында Габделкаюм Насыйри мәкальләрнең, табышмакларның, шигырьләрнең, гомумән матур әдәбиятның әһәмияте турындагы мәсьәләне яктырта һәм шактый җентекле аңлатмалар бирә.

Мәгърифәтче галим халык авыз иҗатына аеруча зур әһәмият бирә, үзе җыйган татар җырларын, мәкальләрен, әйтемнәрен китерә.

Киң карашлы галим буларак, Габделкаюм Насыйри фәнни белемнәрнең төрле өлкәләренә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Аның татар тел гыйлеме буенча хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Габделкаюм Насыйри хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы тел галимнәрнең иң күренеклесе булып кала бирә. Ул татар теленең фәнни атамаларын эшләүгә шактый зур өлеш кертә, грамматика һәм синтаксис буенча гаять эчтәлекле китаплар яза. Татар теле буенча беренче хезмәте – «Кыскача нәхү китабы» 1860 елда басылып чыга. Ә 1895 елда нәшер ителгән «Әнмүзәҗ» китабы мәгърифәтче галимнең татар тел гыйлеме буенча күпьеллык тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып тора. Бу хезмәттә татар теленең фәнни грамматикасына нигез салына, аның фонетикасына һәм морфологик үзенчәлекләренә һәрьяклы бәяләмә ясала. Әлеге китабы белән Габделкаюм Насыйри татар телен алга таба өйрәнүне дәвам итү өчен бай фәнни җирлек әзерли. Стилистика һәм матур язу фәнни мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре») хезмәтендә ул татар теленең фонетикасын, лексикасын һәм башка грамматик нормаларын киң яктырта.

Галимнең татар теленең лексик байлыгы мәсьәләләренә багышланган ике томлык «Ләһҗәи татари» дигән китабы [I т., Казан, 1895; II т., Казан, 1896] татар теленең лексикографиясе буенча иң зур хезмәт булып тора. Ул татар теленең лексикасын формалаштыруда һәм аның фәнни атамаларын эшләүдә мөһим роль уйный. Хезмәттә шул чорда татар теленең лексик байлыгы шактый тулы чагылыш тапкан.

Мәгърифәтче язучы буларак, Габделкаюм Насыйри татар матур әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә. Татар әдәбияты тарихында Көнбатышка йөз тоту белән бәяләнгән яңа юнәлеш аның исеме белән бәйле. Иске татар әдәбияты фәкать Шәрык идеяләре йогынтысында үсте. Әлеге ганганәне Көнбатыш сәнгате гамәлләре белән берләштерүдәге тәүге адымнар Габделкаюм Насыйриның әдәби эшчәнлеге белән бәйле.

Үз әсәрләрен киң халык массаларына аңлаешлы телдә яза башлавы, татар телен бар көченә гарәп һәм фарсы телләре басымыннан азат итәргә тырышуы Габделкаюм Насыйриның татар әдәбияты тарихында күренекле роль уйнавын раслау өчен җитди

нигез булып тора. 1859 елда язылган беренче хезмәте «Мәҗмәгыл-әхбар» дөньяга чыгу уңаеннан, ул әлеге китапны барча татарларга да аңлаешлы итеп язарга тырышуын белдерә. Галим гомере буе шул мәсләккә тугры булып кала.

Габделкаюм Насыйри татар әдәбияты тарихында берничә матур әдәби әсәр мөгаллифе буларак та билгеле. Аның әдәби мирасында кыска хикәяләр, новеллалар һәм шигырьләр бар. Әдәби иҗат эше белән бергә, ул гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә нәшер ителгән иң яхшы повесть, хикәя һәм новеллаларны татар теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Әдәби эшчәнлегендә Насыйри халык авыз иҗаты үрнәкләреннән киң файдалана.

Күп гасырлар дәвамында бөек акыл иясе саналган Әбугалисинаның исеме Идел буе һәм Җаек алды татарлары арасында инде шактый билгеле була. Аның тормышы һәм эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килгән мәгълүматлар белән беррәттән, гади халык арасында әлеге галимне әкият каһарманы итеп тасвирлаган байтак риваятьләр дә йөри. Әлеге риваятьләргә таянып һәм төрек язучысы Сәед Яхъяның «Кәнҗинәи хикмәт» китабы нигезендә Габделкаюм Насыйри үзенең атаклы «Әбугалисина» әсәрен яза һәм 1872 елда нәшер итә. Анда Әбугалисина мәгърифәт нурлары һәм югары әхлакый идеаллар таратучы, үзенең тапкыр, зирәк һәм зыялылыгы белән дөреслек һәм гаделлек өчен җан атучы, ярлы-ябаганы яклаучы, золымга каршы аяусыз көрәшүче итеп гәүдәләндерелә.

Моннан тыш, Габделкаюм Насыйри гарәп телендәге «Кырык вәзир турында хикәят» әсәрен яңадан эшкәртеп нәшер итә (1868), урта гасырлар фарсы әдәбияты ядкаре «Кабуснамә»не (1886) һәм Шәрыкта киң таралган «Җәваһирәл-хикәят» («Повестьлар хәзинәсе», 1884) әсәрен татар теленә тәрҗемә итә һәм нәшер итә. 1896 елда ул «Әфсәнәи Гөлрух вә Камәрҗан» дигән баш астында зур әдәби әсәренең бер өлешен бастыра. Мәгърифәтче-галим роман дип атаган бу тәмамланмаган язма Кече Азия төрекләре арасында таралган повестька нигезләнә. Ләкин үз әсәренең героен мөгаллиф Идел-Чулман төбәгеннән чыккан зат итеп тасвирлый.

Бу әсәрләрнең барысы да татар әдәбиятын үстерү һәм мәгърифәт фикерләрен тарату эшенә җитди өлеш кертәләр. Фәнни нотыкларында һәм календарьларында басылган публицистик мәкаләләрендә Габделкаюм Насыйри татар әдәби тәнкыйте һәм әдәбият гыйлеменең нигезләрен сала. Аның әсәрләрендә без үткән чорлар

татар шагыйрьләре Г.Утыз Имәни һәм Г.Кандалый иҗатларына тәүге мәртәбә бәя бирү омтылышы белән очрашабыз. Габделкаюм Насыйри яңа нәшер ителгән китапларга бәяләмәләр яза, аларның эчтәлеген дә, бизәлешен дә яхшырту зарурлыгын күрсәтә.

Габделкаюм Насыйри туган халкын заманының алдынгы фәнни гыйлемнәре белән таныштыру буенча да шактый эш башкара. 1860 елда «Буш вакыт» исеме белән табигать күренешләре турында гомуми мәгълүматлар туплаган җыентык басыла. Бу хезмәт татар телендә басылган беренче фәнни-популяр әсәр була. Аннан соң галим математика (1873) һәм география (1895) буенча дәреслекләр яза һәм нәшер итә. География буенча Габделкаюм Насыйри «Истыйляхат җәгърафия» («География нигезләре», 1890) һәм «Җәгърафияи кәбир» («Тулы география», I, II, III өлешләрен, 1894–1899) китапларын язып нәшер итә. Шулай ук аның «Гыйльме зирагать» («Игенчелек нигезләре», 1892), «Гөлзар вә чәмәнзар» («Үсемлекләр һәм чәчәкләр», 1894) һәм «Мөнафигъ әгъза вә кануне сихәт» (1892) китаплары басылып чыга. Соңгысында кеше организмы төзелеше мәсьәләләре һәм чисталык кагыйдәләре яктыртыла. Бу хезмәтләр татарлар арасында фәнни гыйлемнәр таралуда сизелерлек өлеш кертәләр. Татар телендә фәнни атамаларны эшләүдә дә аларның әһәмияте гаять зур.

Габделкаюм Насыйри туган як һәм татар халкы тарихын өйрәнүгә дә зур өлеш керткән галим. Һәр җәйдә диярлек ул татар авыллары буйлап сәяхәт кыла, тарихи низамнамәләр һәм үткәннәрнең халык хәтеренә сакланган ядкарьләрен эзли һәм туплый, авыллар тарихы буенча мәгълүматлар җыя һәм аларны ачыклый, татар халкының этнографиясен өйрәнә. Инде хәзерге заман телендә әйтсәк, кыр экспедицияләре оештыра. Ул беренчеләрдән булып Зөя тамагы төбәгендәге Казан ханлыгы чорыннан калган эпиграфик истәлекләрне өйрәнү эшенә керешә. Тарихи һәйкәлләрне өйрәнеп, Габделкаюм Насыйри Казан татарлары Идел-Чулман Болгарстаны халкы токымыннан булган дигән нәтиҗә ясый.

Насыйри шулай ук Казан шәһәре һәм ханлыгы тарихы буенча да гаять бай гыйлемнәр туплый, аның нигезендә «Казан тарихы турында», «Аксак Каратун», «Пугачау» һәм «Ишбулат мулла хакында риваятьләр», «Археология материаллары», «Татар этнографиясе материаллары» дигән хезмәтләр яза. Мәгърифәтче галимнең әлеге хезмәтлере 1926 елда «Моңарчы басылмаган әсәрләр» исеме

астында басмаханәдә дөнья күрәләр. Бу китапларда Казан шәһәрен салу тарихы һәм аның топографиясе, Зөя кальгасын төзү тасвирлана, татарларның Казанны саклагандагы фидакарьлеге турында сөйләнә. Китапта шулай ук Иван IV һәм аның буйсындырылган халыкка карата рәхимсез сәясәте, мөселман татарлары арасында Аксак Каратунның (Казан губернасының архиепископы Лука Канашевич) ерткычлыклары, Пугачёв баш күтәрүе һәм татар халкының аңа мөнәсәбәте хакында бәян ителә. Галимнең этнография буенча хезмәтләрендә Казан татарларының көнкүрешенә, йортҗирләрен бизәүгә, аларның ничек туклануына һәм киемсалымнарына төпле бәяләмә бирелә.

«Тәрбия китабы» (1891), «Әхлак рисаләсе» (1881, 1890), «Әхлак рисаләсе вә форүз могътәкадәт рисаләсе» (1890, 1910) һәм «Тәрбия» (1892) әсәрләрендә Габделкаюм Насыйри әхлак нормалары, тәрбия һәм педагогика мәсьәләләрен күтәрә. Әлеге мәсьәләләр шулай ук аның календарьларында һәм әдәби әсәрләрендә дә чагылыш табалар.

Габделкаюм Насыйри Россиядәге милли мөнәсәбәтләрнең бөтен катлаулылыгын һәм татарларга моны һәрдаим истә тоту зарурлыгын яхшы аңлый. Мәгърифәтченең шушы инанулары аның фәнни-иҗади һәм педагогик эшчәнлегендә дә киң чагылыш таба. Россия эчендә яшәп, татарлар аның тарихын һәм мәдәниятен, шулай ук рус телен белергә тиеш дип саный ул. Әмма шуны да искәртергә кирәк. Бу ана телен, үз туган телеңне югалту хисабына, я булмаса аның бәрабәренә булырга тиеш түгел. Бу туган халәттән дөрес чыгу юлы. Рус телен үзләштерү Россия империясе кысаларында яшәү өчен кирәк булган мөһим шарт. Аны өйрәнү зарури. Әлеге эштә милләттәшләренә ярдәм йөзеннән ул «Кавагыйде кыйраәте рус» («Русча уку кагыйдәләре», 1889), «Нәмүнә, яки әнмүзәҗ» («Гарәп тел үрнәгендә төзелгән рус теле грамматикасы», 1891), «Лөгате рус китабы» («Рус-татар сүзлеге», 1892), «Зөбдәтен мим тәварихе рус» («Кыскача рус тарихы», 1890) дигән дәреслекләр яза.

Рус һәм татар халыклары арасында милли каршылык киртәләрен бетерүдә һәм үзара аңлашуга ирешүдә Габделкаюм Насыйриның рус кешеләрен татарларның яшәү тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреш гореф-гадәтләре белән таныштыруы да зур әһәмияткә ия. Руслар арасында татарларның мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре

турындагы әдәбиятны тарату, аларны татар халкының тарихи үткәне белән таныштыру милләтебез турындагы тискәре карашны үзгәртүгә китерер дип саный ул.

Габделкаюм Насыйри «рус кешеләренә татар көнкүрешен аңларга булышу»ны, «бу көнкүрешне озак күзәтүләре» турында алар белән матбугатта уртаклашуны үзенең бурычы дип саный. Әлеге максатта ул татарларның тарихи үткәне, татар халык авыз иҗаты һәм көнкүреш гореф-гадәтләре, йолалары турында әсәрләр иҗат итә һәм бастырып чыгара, руслар өчен татар теле дәреслекләре һәм сүзлекләр төзи. Рус укучысы өчен, аерым алганда, аның тарафыннан «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» (1900), «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары» (1880), «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» (1896) хезмәтләре языла.

Габделкаюм Насыйри рус галимнәре белән даими аралаша, элемтәдә тора, аларга татар милләте тарихы һәм мәдәнияте ядкарьләрен барлауда һәм аның тарихи үткәне турында хезмәтләр әзерләүдә ярдәм итә. Казан университеты каршындагы «Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте»нең татар милләте тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре буенча әгъзасы буларак, ул рус җәмәгатьчелеге алдында фәнни гомумиләштерүләр һәм нотыклар белән чыга.

Габделкаюм Насыйри фәнни хезмәтләр иҗат итеп кенә калмый, аларны үзе хисабына нәшер итә һәм тарата да. Китап белгече Ә.Г. Кәримуллин мәгълүматларына караганда, мәгърифәтче галимнең үзе исән чагында ук 100 ләп китабы дөнья күрә (аларның кайберләре берничә мәртәбә басыла), шуларның күпчелеге аның үз хисабына бастырыла һәм таратыла (бары тик унысы гына башкалар тарафыннан нәшер ителә).

Татар телендә «Таң йолдызы» газетасын чыгару мәгърифәтченең күңел түрендәге хыялы була. Ул берничә тапкыр хакимият органнарына газета чыгаруга рөхсәт бирүләрен сорап мөрәҗәгать итә, ләкин аның үтенече кире кагыла. Габделкаюм Насыйрины бу да туктата алмый. Ул 30 ел дәвамында татар вакытлы матбугаты вазыйфаларын үтәгән еллык өстәл календарьлары чыгара башлый, аларда укучыларны табигать белеме, тарих, география, әдәбят, халык авыз иҗаты, тел гыйлеме һәм башка фәнни тармаклар буенча мәкаләләр һәм язмалар белән дә таныштырып бара.

Габделкаюм Насыйри календарьларында басылган материаллар татар милләтенең яшәү һәм хезмәт шартлары турында сөйли, монда шул чорда чыккан китапларга һәм хезмәтләргә бәяләмәләр, әхлак һәм тәрбия, игенчелек һәм сәнәгать буенча гыйлемнәр, публицистика үрнәкләре һ.б. мәгълүматлар очрый.

Габделкаюм Насыйриның күпкырлы эшчәнлегендә, аның әсәрләрендә мәгърифәтченең туган милләте, аның ачы язмышы турындагы уй-фикерләре дә чагылыш таба. Татарларны торгынлыктан һәм хәерчелектән, иҗтимагый һәм милли изүдән коткару, аң-белемле итү галимнең иң олы хыялы була. Үз хезмәтләрендә Габделкаюм Насыйри бу проблеманы мәгърифәтчеләргә хас мәсләктән чыгып хәл итә. Алдынгы үсеш юлына басар өчен, беренчедән, хәзерге заман фәненең үрләрен яуларга һәм алдынгы милләтләр белән киң икътисади һәм мәдәни багланышларга керергә кирәк дип саный ул. Шуннан чыгып, ул фәннең җәмгыятьтәге урыны турындагы мәсьәләне күтәрә, гыйлем көчен тормышта, сәнагатьтә кулланырга өнди, ә фәнне кешелекнең иң кыйммәтле байлыгы дип саный. Аның карашынча, фән – гыйлем чыганагы, ә белемнәр – кеше эшчәнлегенең зарури нигезе.

Габделкаюм Насыйриның әхлак кануннары буенча карашлары тәрбия һәм уку-укыту проблемаларына кагылышлы мирасында да чагылыш таба. Аның фикеренчә, кешедә акыллы җан иясенә хас сыйфатлар булдыруда хәлиткеч урынны иҗтимагый мохит һәм тәрбия алып тора. Әлеге мәсьәләдә ул XVIII йөз мәгърифәтчеләре карашында тора.

Габделкаюм Насыйри, ислам дине тарафдары буларак, мөселман йолалары, әхлагы һәм ислам тәгълиматы таратуга багышланган әсәрләр дә калдыра. Шул ук вакытта ул Аллаһ Тәгалә һәм фани дөнья мөнәсәбәтләрен икелек (деизм) фәлсәфәсе карашыннан торып аңлата. Аныңча, җиһандагы тәртип, табигать күренешләренең агышы Аллаһ тарафыннан билгеләнә, ләкин ул әлеге агыш-күренешләргә турыдан-туры катнашмый. «Бу дөнья, дип яза ул, – сәбәпләр дөньясы. Без мохтаҗ булган бар нәрсә билгеле бер сәбәпкә бәйле. Әлеге сәбәпләрне уй-фикер йөртеп, акыл белән эзләнеп кенә аңлап-белеп була. Күренешләрнең сәбәбен белергә һәм шуларга таянып хәрәкәт итәргә кирәк». Шулай булгач, бу дөньяда кеше язмышка буй-сынырга түгел, сәбәплелек мәсләгенә таянып хәрәкәт итәргә, күренешләрнең сәбәбен аңларга һәм шуңа

бәйле көчләрне кеше файдасына эшләтергә тиеш. Ул фәннең һәм кеше акылының дөньяны танып белүдәге һәм күренешләрнең сәбәпләрен ачыклаудагы урынына аеруча зур басым ясый. Габделкаюм Насыйриның дөньяга, аның күренешләренә булган бу карашы, аның бу фәлсәфәсе – хәзерге көн сулышына туры килә торган уртаклык фикередер. Җан азагы өчен Аллаһны тану, барлау һәм зурлау булса, тормыш өчен – гыйлем, акыл, белем, тәҗрибә зарурлыгы мөһим. Кеше бу дөньяда җан һәм акыл берлегендә яшәргә тиеш. Бу аның тормышны, табигатьне һәм кешенең тормыштагы урынын аңлаудагы иң алдынгы карашларының берседер.

Үзенең фәнни хезмәтләре һәм күпкырлы эшчәнлеге белән Габделкаюм Насыйри татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикерендә тирән эз калдырган шәхес дип таныйбыз. Бар гомерен, акылын һәм әдәби сәләтен ул мәгърифәт нуры таратуга, туган халкын урта гасырлар рухи богауларыннан азат итүгә багышлады. Ул татар иҗтимагый фикерендә тәнкыйди башлангычка нигез салучы, кешеләр фикерен урта гасырлар фанатиклыгыннан азат итүдә мөһим адым ясаучы, чынбарлыкка аек акыл белән бәя бирү мөмкинлеген тудыруга өлеш кертүче акыл ияләренең берсе. Татар теле һәм тарихы буенча хезмәтләре белән Габделкаюм Насыйри туган милләтенә үзенең тарихи үткәнен һәм мәдәни мирасын аңлауда сизелерлек этәргеч ясады. Матур әдәбият әсәрләре һәм әдәбият гыйлеме буенча хезмәтләре белән ул хәзерге татар әдәбиятының нигезен салуга үзеннән зур өлеш кертте. Аның фәнни һәм әдәби мирасы татар мәдәнияте тарихында лаеклы урын алып тора. Инде Габделкаюм Насыйриның киңкырлы фәнни-иҗади эшчәнлегенә бәя биреп, иң мөһим юнәлешләрен санап китик:

1. Ул – XIX гасырның II яртысында татар иҗтимагый-мәдәни тормышына көчле бер ташкын булып килеп кергән мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле, иң алдынгысы һәм эшлеклесе. 1855 елдан 1879 елга кадәр Габделкаюм Насыйри, төрле уку йортларында эшләп, татар мәгърифәтчеләре алга сөргән төп фикерләрне тормышка ашыру, татар милләтенең аң-белемен күтәрү, аны Европа мәдәниятенә якынайту юлында күп көч куя, укыту-мәгариф өлкәсендә гамәли тәҗрибә туплый. Казан шәһәрендә мөселман балаларын рус теленә өйрәтү эшен беренчеләрдән булып башлап җибәрүче кеше дә Насыйри була. Педагог шулай ук татарларга

төрле дөньяви гыйлемнәрне укытуны җайга салу юлында да актив көрәшә.

2. Габделкаюм Насыйри – мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр мөгаллифе. 1879 елда ул даими рәвештә гыйльми һәм язучылык эше белән шөгыльләнә башлый һәм милләтебез өчен бик тә кирәк булган төрле уку әсбаплары, дәреслекләр төзи, нәшер итә. Ул – татар теле («Нәхү китабы», «Кавагыйде китабат» һ.б.), («Кырык бакча», «Кырык вәзир» һ. б.лар), рус теле («Кыйраәте рус», «Нәмүнә, яки әнмүзәҗ» һ. б.лар), рус тарихы («Зөбдәдате мин тәварихе рус»), математика («Хисаплык»), геометрия («Гыйльме һәндәсә»), география («Җәгърәфия кәбир», «Истиляхате җәгърәфия»), ботаника («Гөлзар вә чәманзар, ягьни үләнлек вә чәчәкләр») һәм башка фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр бастырып чыгарган шәхес. Әлеге китапларны санап чыгу гына да Габделкаюм Насыйриның энциклопедик белемгә ия булуын күрсәтә.

3. Габделкаюм Насыйри – телче, татар теле гыйлеме галиме. Ул татар телен гамәли һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зур эшчәнлек күрсәтте. Беренче булып, татар теленең аңлатмалы сүзлеген («Ләһҗәи татар»), русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләрне, татар теленең фәнни грамматикасын («Әнмүзәҗ»), орфография кагыйдәләрен анлаткан кулланманы һ.б. Габделкаюм Насыйри төзи. Аның бу хезмәтләре үз вакытында ук атаклы тел белгечләре тарафыннан югары бәяләнә.

4. Габделкаюм Насыйри татар халык авыз иҗатын туплау һәм бастырып чыгару эшенә дә зур өлеш кертә. Ул кагылмаган, өйрәнмәгән бер генә татар халык авыз иҗаты жанры да юк дияргә була. Аның бигрәк тә җырлар, мәкальләр, әйтемнәр, мәзәкләр, бәетләр һәм кыйссаларны нәшер итү юлында хезмәте зур («Фәвакиһел җөласа фил әдәбият», «Кырык бакча»).

5. Габделкаюм Насыйри тәржемәче дә. Ул рус классикасы әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп кенә калмый, руслар өчен татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен да хәзерләп нәшер итә. Мисал өчен, аның рус телендә «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре», «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары», «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» исемле китаплары дөнья күрә. Шулай ук Габделкаюм Насыйри гарәп һәм фарсы телләрендәге Көнчыгыш әдәбияты үрнәкләрен татарчалаштыруга да күп хезмәт куя, «Кырык

вәзир кыйссасы», «Әбугалисина кыйссасы», «Фәвакиһел жөласа...» китабына кертелгән хикәят һәм экиятләр аның шул өлкәдәге тырышлык җимешләре.

6. Матур әдәбиятка килгәндә, Насыйриның «Әфсәнаи Гөлрөх вә Камәрҗан» исемле күләмле әсәрен, «Әхфале сөкран» шигырьләр җыентыгын атарга мөмкин.

7. Габделкаюм Насыйри татар милләте өчен вакытлы матбугат булдыру өчен күп тырышлык куя. Ул татар телендә «Таң йолдызы» исемле газета чыгару өчен проект төзеп, патшага мөрәҗәгать итә, ләкин рөхсәт ала алмый. 1871 елдан башлап дистә елдан артык ярым журнал характерындагы өстәл календаре чыгарып килә. Бу дәвамлы проектлар рәтеннән. Халыкны агарту, мәгърифәтле итү эшендә әлеге календарьларның әһәмияте шактый зур була.

8. Габделкаюм Насыйриның тарих һәм этнография өлкәсендә дә кыйммәтле хезмәтләре бар. Бу урында аның 1885 елда Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» әгъзасы итеп сайлануын гына атау да күп нәрсә хакында сөйли.

9. Габделкаюм Насыйриның татар теленә карата әйтелгән фикерләренең бүгенге көндә татар мәгарифен оештыручылар, аның белән идарә итүчеләр тарафыннан санга сугылмавы аяныч, билгеле. Әгәрдә ки Габделкаюм бабабыз татар телен хөрмәт итмәгән, яратмаган булса, ул аның тәгълимати нигезләрен эшләп көн-төнен, елларын сарыф итмәгән булыр иде. Бүгенгесе көндә Татарстанда татар теленең гамәлгә куелышы бик түбән. Ул уку-укыту оешмаларында да, дәүләт дәрәҗәсендә дә җиренә җиткереп үтәлми. Татар теле эш коралы, аралашу чарасы булып кулланылырга тиеш. Фәкать менә шул очракта гына аны өйрәнүгә ихтыяҗ туачак, аның әһәмияте үсәчәк. Татар кешесенә татарча белүе белән масаерга кирәк түгел. Ул гадәти күренеш, халәт булырга тиеш. Телне белүгә аның тормыштагы әһәмиятеннән чыгып ихтыяҗ тудырырга кирәк. Ихтыяҗ юк, әһәмияте түбән икән, димәк, аны өйрәнмичә дә яшәп була. Менә мондый фикергә килмәс өчен хөкүмәт даирәләрендә утыручылар, мәгариф белән идарә итүчеләр бер хакыйкатьне дөрес аңларга тиешләр. Тел дәүләттә аралашу чарасы, укыту теле булып кулланылмый икән, ул үлемгә юл алган телләрдән булыр. Телне саклау – ул ватанны саклау кебек үк дәүләт вазыйфасы. Дәүләте булмаган халык телен дә саклый алмый.

10. Кыскасы, Габделкаюм Насыйри – татар милләтенең тәгълим-тәрбия өлкәсендә, әдәбиятында, мәдәниятендә, фәнендә, иҗтимагый фикер тарихында кыйммәтле хезмәтләр, фикерләр калдырган күпкырлы галим. Бу хезмәтләр әле дә көн үзәгендә, бүген дә өйрәнелә һәм укыла.

11. Бүгенге көн кадагыннан чыгып фикер йөртсәк, Габделкаюм Насыйриның күпкырлы эшчәнлегенең төп асылы татар милләтен һәм татар кешесен бу дөньяда, бу тормышта үз-үзеңне башка милләтләргә танытып, үз үсеш дәрәҗәсендә алга киткән милләтләр рәтенә күтәрүдер. Татар кешесендә милли үзаңны формалаштырып, үз кыйблаңны, бу тормышта үзеңә лаеклы урыныңны табу, рус милләте белән кулга-кул тотынышып алга киткән милләтләр рәтендә яшәүне күзаллаудыр.

## GABDELKAYUM NASYRI'S ACTIVITY AND HIS VALUE FOR THE PRESENT

***Shaymardanov Rafis Hasanovich,***
*Doctor of pedagogical sciences,*
*Surgut state pedagogical university,*
*rafis55@mail.ru*

Gabdelkayum Nasyri's life and his public and pedagogical, scientific and educational activities described in the paper. Nasyri characterized as the author of textbooks and manuals, who make a valuable contribution in developing of theoretical bases of the Tatar Linguistics and research of Tatar history and folklore.

***Keywords:*** Kayum Nasyri, education, linguistics, Tatar history, folklore, textbooks, biography.

УДК 374.7

# КАЮМ НАСЫЙРИ ИНСТИТУТЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Хөснетдинов Рәсим Рәхимҗан улы,***
*PhD, Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*knikazan@gmail.com*

Мәкаләдә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында ачылган К. Насыйри институтының Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә татар телен укыту һәм татар мәдәниятен пропагандалау өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртыла.

***Төп төшенчәләр:*** Каюм Насыйри институты, Каюм Насыйри, татар теле.

2014 елда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасы нигезендә, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында халыкара Каюм Насыйри институты эшли башлады. Мәркәзе Казан шәһәрендә урнашкан әлеге фән һәм белем бирү үзәге[1] үз эшен чит төбәкләрдә ачылган белем бирү һәм мәдәният үзәкләре аша алып барачак.

Каюм Насыйри институтының чит төбәкләрдә ачылган белем бирү һәм мәдәният үзәкләрендә татар теле курслары, төрле мәдәни чаралар, фән буенча киңәшләр, «Ана теле» татар телен онлайн өйрәтү мәктәбе дәресләренә катнашу ысуллары, татар теленнән халыкара олимпиадага әзерлек алып бару, 2014–2020 елларга кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан

[1] Татар телендә тулы исеме: Югары профессиональ белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе «Казан (Идел буе) федераль университеты» Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Каюм Насыйри институты» фән һәм белем бирү үзәге. Татар телендә кыскартылган исеме: Каюм Насыйри институты.

Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасы проектларын тормышка ашыру алымнары һ.б. чаралар үткәреләчәк. Әлеге үзәкләрдә шулай ук Татарстан халыклары телләрен үстерү кысаларында рус теленнән дә төрле фәнни-гамәли консультацияләр каралган.

Татарстан Республикасы ярдәме белән Каюм Насыйри институты үзәкләренә куелган заманча җиһазлар университет укытучыларына, студентларга, үзәктә шөгыльләнүчеләргә Казан университеты галимнәре, язучылар, студентлар белән элемтәгә керү, татар һәм рус телләреннән киңәшләр, сорауларга җаваплар алу мөмкинлеген бирәчәк, ә Казан университеты студентлары һәм мөгаллимнәре үзәкләрдәге рус, казах, төрек һәм үзәкләрдәге башка хезмәттәшләренең дәресләрен тыңлый алачак, шулай ук бу җиһазлар ярдәмендә төрле видео-конференцияләр үткәрергә мөмкин булачак.

Үзәкләр ел саен Татарстан Республикасы нәшриятларында басылып чыккан 30 төрдәге (һәрберсе 10 ар данәдән) яңа китап, методик кулланмалар, укыту әсбаплары, сүзлекләр, дәреслекләр белән тәэмин ителәчәк.

Каюм Насыйри институты кебек тел өйрәтү, мәдәният таныту үзәкләре дөньякүләм билгеле булсалар да, алар күп түгел. Милли телләрне, милли мәдәниятне өйрәнү үзәкләрен булдырган институтларга үрнәк буларак берничә дистә ел Германиядә – Гете, 2009 елда Төркиядә – Юныс Әмре, рус теле буенча Пушкин, кытай теле буенча Конфуций, испан теле өлкәсендә Сервантес институтларын атарга була. Мәсәлән, дөньяда Сервантес институтының испан телен, испан мәдәниятен өйрәтүче 77 үзәге эшләве дә мәгълүм.

Каюм Насыйри институты үз эшчәнлегендә дөньяда танылган әлеге инстиутларның тәҗрибәләрен өйрәнә. Программа буенча һәр ел саен чит төбәкләрдә Каюм Насыйри институтының 2–3 белем бирү һәм мәдәният үзәкләрен ачу күздә тотыла. 2014 елда беренче булып Мәскәү һәм Астана шәһәрләрендә шундый үзәкләр ачылды.

Татарстаннан читтә, Россия Федерацисендә ачылган беренче белем бирү һәм мәдәният үзәге 2014 елның 17 декабрендә Мәскәү шәһәрендә Муса Җәлил исемендәге 1186 нче татар этнокомпонентлы мәктәптә урын алды[2].

[2] Мәскәүдәге Каюм Насыйри Институты белем бирү һәм мәдәният үзәгенең методисты (җитәкчесе һәм укытучысы) итеп мәктәптә 6 ел татар

Татарстан хөкүмәте, Мәскәүдәге мәгариф җитәкчеләре һәм татар оешмалары үзәк ачылу вакыйгасына зур игътибар бирде. Татарстанның дәүләт шурасы рәисе Ф. Мөхәммәтшин үзенең чыгышында: «Бу институтның беренче үзәген Мәскәүдә ачу безнең өчен бик мөһим. Һәр халык үзенең телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калырга тырыша. Без аңа зур игътибар бирәбез. Үз ягыбыздан без бу юнәлештә ярдәм итеп торачакбыз. Ләкин эш акчада гына түгел, туган телне өйрәнү, белү һәр кешенең күңелендә, җанында булырга тиеш», – диде. Р. Җамалетдиновның: «Без бу үзәкне бөтен дөньяга таралган татарларны берләштерү, туган тел, мәдәниятне аларга җиткерү теләге белән ачтык. Каюм Насыйри исеме һәр татарга да таныш. Ул бөтен гомерен укытуга, мәгарифкә багышлаган. Билгеле мәгърифәтче. Ул укытучы да, галим дә....», – дигән сүзләренә кушылып, Э. Фәттахов бу үзәкнең эше өчен Татарстаннан 164 миллион акча бүлеп бирелгәнен әйтте.

23.Хакимзянов Ф.С., Шакирзянов Р.А. и др. Русско-татарский нефтепромысловый словарь. Казань: Магариф, 2004. 415 с.

24.Мифтахутдинов И.Х. Словарь архитектурных терминов. Казань: КГАСУ, 1993. 102 с.

25.Кафиатуллина В.И. Немецко-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики. Казань: КГАСА, 1996. 90 с.

26.Кафиатуллина В.И. Англо-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики. Казань: КГАСА, 1996. 83 с.

27.Камалов А.З., Сиразетдинов Ф.Г. Сборник задач по теоретической механике (кинематика). Казань: КИСИ, 1992. 100 с.

28.Минуллин С.М. Сборник задач по начертательной геометрии. Казань: КИСИ, 1992. 89 с.

29.Камалов А.З., Сиразетдинов Ф.Г. Теоретическая механика. Казань: КИСИ, 1992. 128 с.

30.Фатхуллин В.Ш. Железобетонные конструкции. Казань: КИСИ, 1993. 120 с.

31.Салимов Р.Б., Муратов Л.М., Туктамышов Н.К. Элементы линейной алгебры и аналитической геометрии. Казань: КИСИ, 1993. 86 с.

32.Камалов А.З., Сиразетдинов Ф.Г. Сборник задач по теоретической механике (динамика). Казань: КИСИ, 1993. 162 с.

33.Заббаров А.Н., Сафин Р.С. Водоснабжение и канализация сельских населенных мест. Казань: КИСИ, 1994. 112 с.

34.Гилязов Д.Г., Нарбеков А.И. Теплогазоснабжение и вентиляция зданий. Казань: КИСИ, 1994. 126 с.

35.Мифтахутдинов И.Х., Саттаров А.Г., Саттарова Т.Д. История архитектуры. Казань: КИСИ, 1995. 71 с.

36.Терегулов И.Г., Шигабутдинов Ф.Г., Низамеев В.Г. Основы теории расчета тонкостенных стержней открытого профиля на стесненное кручение и смежные вопросы. Казань: КГАСА, 1995. 63 с.

37.Мирсаяпов Ил. Т. Архитектура промышленных зданий. Казань: КГАСА, 1996. 81 с.

38.Шакирзянов Р.А. Динамика сооружений. Казань: КГАСА, 1997. 96 с.

39.Гирфанов И.С. Металлические балки, балочные клетки и центрально-сжатые колонны. Казань: Новое знание, 1997. 96 с.

40.Шигабутдинов Ф.Г. Основы теории упругости (расчет пластин). Казань: КГАСА, 1997. 110 с.

41.Азизова З.Ф. Геодезия. Казань: КГАСУ, 1998. 108 с.

42.Камалов А.З., Шигабутдинов Ф.Г., Ильязов Р.Н. Сборник задач по теоретической механике. Статика. Казань: КГАСА, 1998. 130 с.

43.Куряева Р.И. Введение в лексику и грамматику английского языка. Казань: Новое знание, 1998. 80 с.

44.Салимов Р.Б., Туктамышов Н.К., Муратов Л.М. Дифференциальное исчисление. Казань: КГАСА, 1998. 83 с.

45.Шигабутдинов Ф.Г. Шигабутдинов А.Ф. Решение плоской задачи теории упругости. Казань: КГАСУ, 1999. 110 с.

46.Минниханов Ф.Г. История (с древнейших времен до начала XVII века). Казань, КГАСА, 1999. 95 с.

47.Заббаров А.Н., Сафин Р.С. Водоснабжение и канализация. Казань: КГАСА, 1999. 59 с.

48.Камалов А.З., Шигабутдинов Ф.Г., Ильязов Р.Н. Сборник задач по теоретической механике. Кинематика. Ч. 1. Казань: КГАСА, 2000. 66 с.

49.Саттаров И.Р. Философия. Казань: КГАСА, 2000. 152 с.

50.Минниханов Ф.Г. История (с начала XVIII века до начала XX века). КГАСУ, 2000. 115 с.

51.Туктамышов Н.К. Сборник задач по математике. Казань: КГАСА, 2000. 87 с.

52.Камалов А.З., Шигабутдинов Ф.Г., Ильязов Р.Н. Сборник задач по теоретической механике. Кинематика. Ч. 2. Казань: КГАСА, 2001. 91 с.

53.Шакирзянов Р.А. Строительная механика: Расчет статически определимых систем. Казань: КГАСУ, 2001. 108 с.

54.Камалова З.А. Строительные материалы. Казань: КГАСУ, 2001. 116 с.

55.Газизуллин Р.Г. Начертательная геометрия. Казань: КГАСА, 2001. 124 с.

56.Минниханов Ф.Г. История России. Казань: КГАСА, 2001. 181 с.

57.Шакирзянов Р.А. Строительная механика: Статически неопределимые системы. Казань, КГАСА, 2002. 127 с.

58.Саттаров И.Ф. Философия. Ч. 2. Казань: Рутен, 2003. 259 с.

59.Туктамышов Н.К. Уравнения математической физики. Казань: КГАСА, 2003. 47 с.

60.Камалов А.З. Сборник задач по теоретической механике (динамика). Казань: КГАСУ, 2004. 85 с.

61.Камалова З.А. Строительные материалы. Казань: КГАСА, 2004. 111 с.

62.Шакирзянов Р.А., Шакирзянов Ф.Р. Строительная механика: Метод конечных элементов и теория устойчивости. Казань: КГАСУ, 2006. 84 с.

63.Камалова З.А. Строительные материалы в конструкциях зданий и сооружений. Казань: КГАСУ, 2007. 48 с.

64.Кильдеев М.В. Лекции по социологии. Казань: КГАСУ, 2007. 115 с.

65.Шакирзянов Р.А., Шакирзянов Ф.Р. Курс лекций по строительной механике. Казань: КГАСУ, 2008. 100 с.

66.Шакирзянов Р.А., Нарбеков А.И., Шакирзянов Ф.Р. Выдающиеся татарские ученые. Казань: Тат. кн. изд-во, 2011. 423 с.

67.Крамина Т.А. История архитектуры. Казань: КГАСУ, 2013. 90 с.

68.Фән һәм тел / Наука и язык. 1997–2013. № 1–51.

## CONSTRUCTION HIGHER EDUCATION IN THE TATAR LANGUAGE: HISTORY, PRESENT AND FUTURE

***Shakirzianov Rashit Agleevich,***
*Candidate of technical sciences,*
*Kazan state university of architecture and engeneering,*
*rashitagl@mail.ru*

The article is dedicated to the 85th anniversary of the providing of construction education in tatar language. A long history of higher education, history of the Tatar building industry and architecture, and their impact on the current situation with the construction education analised. The experience of Kazan state university of architecture and engineering as only centre of the preserving of construction education in the tatar language, developing of scientific terminology reported in details.

***Keywords:*** Construction Education, Higher Education, tatar language, teaching of technical subjects, educational literature.

УДК 378.14

# АНА ТЕЛЕНДӘ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ (1990–2005 еллар)

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә 1990–2005 елларда югары уку йортларында татар телен һәм татар телендә укыту мәсьәләләре яктыртыла. Шулай ук фәннәрне татар телендә укытуның торышы, концептуаль нигезләре, методик яктан тәэмин ителеше, кадрлар әзерләү, татар телендә фәнни терминология һ.б. юнәлешләр тикшерелә.

***Төп төшенчәләр:*** югары уку йортлары, ана телендә белем бирү, укыту-методик база, дәреслекләр, фәнни атамалар.

Ана телендә югары белем – татар өлексез мәгариф системасының иң мөһим буыннарыннан берсе булып тора. Галимнәр милли югары мәктәпне булдыру һәм анда ана телендә эш алып барырлык югары квалификацияле белгечләр әзерләү – татар телен аның тарихына һәм асылына туры килгән дөнья югарылыгына күтәрү өчен генә түгел, ә гомумән телебезне саклап калу өчен бердәнбер юл дип саный [18: 51]. XX гасырның 90 елларында татар теленең фән теле буларак үсеше мәҗбүрилеге проблема буларак күтәрелде [24: 3; 8: 32]. Шул ук вакытта галимнәр тарафыннан татар теленең фән, бигрәк тә төгәл фәннәр теле буларак мөмкинлекләре зур булуы [19: 54] («Татар теле гарәп теле кебек алгоритмлы тел. Ул үзенең логикасы буенча бик күп телләрдән өстен тора. Татар теленең математика укыту өчен искиткеч күп байлыгы һәм башка уңай яклары да бар» [9: 9–10]) расланды.

Урта һөнәри белем бирү йортларында предметларны татарча укыту мәсьәләсе (кайбер педагогия колледжларыннан тыш) бу

этапта куелмый[1]. Бу аның кануни базасы эшләнелмәү, укыту-методик әдәбият булмау белән бәйле.

Татар телендә югары белем бирү мәсьәләсен хәл итү юнәлешендә ике юл тәкъдим ителде. Беренчесе – моңарчы булмаган яңа структура булдыру – татар милли югары уку йортын ачу һәм икенчесе – югары уку йортларында татарча белем бирүне торгызу. Төп бурыч буларак каралган беренче юнәлеш төрле сәбәпләр аркасында тормышка ашмады.

Татар телендә югары белем бирүнең кануни нигезләре беренче тапкыр 1993 елда Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе галимнәре тарафыннан эшләнә [21: 38]. Концепция авторлары татар төркемендә белем алу өзлеклелеген тәэмин итү, өч телне дә камил үзләштергән белгечләр әзерләү бурычын куялар. Татар телендә югары белем бирүнең теоретик нигезләре Казан архитектура-төзелеш академиясе галимнәре Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә, Нарбеков А.И. тәкъдим иткән Концепция проектында [13] аеруча тулы чагылыш таба. Концепция татар халкының тулы мәгариф системасын булдыруга, аның иң әһәмиятле буынын – милли югары мәктәпне төзүгә һәм үстерүгә юнәлтелгән. Проект татар телен кеше эшчәнлегенең һәр өлкәсендә куллану зарурлыгына таяна.

Концепция авторлары фикеренчә, татар югары мәктәбе, гомумән югары уку йортларына карата куелган максатлардан тыш, милли яңарышны тәэмин итү, мәдәниятне һәм телне үстерү, дәүләтчелекне, читтә яшәүче милләттәшләр һәм ватандашлар белән элемтәләрне ныгыту белән дә шөгыльләнергә тиеш була. Борынгыдан килгән традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерү югары белемне дә татар мохитендә һәм нигездә татар телендә алып баруны таләп итә [13: 10]. Әмма шул ук вакытта икенче дәүләт теле булган рус телен камил белү, югары белем бирүнең дөньякүләм системасына кушылу, халыкара интеграция, көнкүрештә һәм һөнәри өлкәдә аралашу, мәгълүмати һәм идеяләр белән алмашуны тизләтү өчен тагын бер чит тел өйрәнүне, чит телләрне туган тел нигезендә өйрәтүне максат итеп ала [16: 10].

Концепция авторлары ана телендә югары белем бирмәү, төгәл фәннәрне татарча укытмау телне зәгыйфьләндерә, фәннән аера дип

---

[1] 2004 елгы мәгълүматлар буенча урта һөнәри белем бирү өлкәсендә студентларның 4%ы гына ана телендә белем ала // ИА Татаринформ. 2004. 22 июнь.

саныйлар. Татар телендә югары белем бирү милли алгарышның нигезе генә булып калмыйча, кешелек дөньясы өчен дә зур файда китерергә тиеш, чөнки ул төрле фәннәрне татар теленең фәлсәфи системасы аша яңабаштан тикшереп чыгарга, аларның әһәмиятле өлешләрен сайлап алырга мөмкинлек бирәчәк, фәндә татар теленең фәлсәфи нигезләрен киңрәк кулланырга, үсеш-үзгәреш барган системаларны, хәрәкәт-динамиканы, технологик процессларны төгәлрәк өйрәнергә ярдәм итәчәк [16: 11].

Концепциядә милли мәгариф өлкәсендәге дәүләт сәясәте принциплары да билгеләнә. Болар арасында ТР гражданнарының югары белемгә констуцион хокукларын тәэмин итү һәм яклау, югары белем бирү өлкәсендә физик һәм юридик затларның вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын билгеләү һ.б. бар. Әлеге документны тормышка ашыру чаралары арасында югары белем бирүнең бербөтен системасын төрле һәм күп кимәлдә (фундаменталь, гуманитар, техник, һөнәри, ике һәм күп телдә белемне күтәрү, аспирантура, докторантура һ.б.) формалаштыру да бар.

Бу чорда ана телендә югары белем бирү ике юнәлештә алып барылды – татар телендә белем бирү һәм фән буларак татар телен укыту.

90 елларда республикадагы дәүләти 21 югары уку йортын, татар телендә укыту мәсләгеннән чыгып, ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләре – электән ана телендә белгечләр әзерли торган (педагогия уку йортлары, дәүләт университеты, сәнгать академиясе) һәм җитештерүненең төрле тармакларын өчен белгечләр әзерләүче вузлар (архитертура-төзелеш, авыл хуҗалыгы, Кама политехника институты, техник һәм технология университетлары) [15: 39].

Бу чорда гуманитар циклга караган предметларны, мәсәлән, тарих, фәлсәфә, педагогика, культурология, нәфасәт, этика, психология кебек фәннәрне туган телдә укыту өчен шартлар җитәрлек тудырыла: татар телендә белем бирә алырлык белгечләр бар, терминологик база да нигездә эшләнгән. Югары уку йортларының татар төркемнәрендә, КДУ, КДПУның татар факультетларында фәннәрне татарча укыту тәҗрибәсенең булуы да моңа ярдәм итә (М. Абдрахмановның 1966 елда татар телендә «Диалектик материализм» дәреслеге дөнья күрә һ.б.). Хәзерге шартларда мондый предметларны туган тел һәм милли үзенчәлекләр аша алып бару-

ның дөреслеген белгечләр дә таный [12: 45]. Бу чорда культурология, фәлсәфә, нәфасәт һ.б. фәннәр буенча югары мәктәп дәреслекләре басылып чыга [5: 6]. Әмма аларның күбесе тулы мәгънәсендә уку-укыту процессына барып ирешми.

90 еллар – татар теле, әдәбияты һәм тарихы буенча югары белем бирү юнәлешендә күтәрелеш еллары буларак кереп калды. 1990 елда, татар тарихында беренче тапкыр буларак, КДУда татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре факультеты оештырыла, Башкорт дәүләт педагогия институтында, КДПИ да, Самара, Ижевск педагогия институтында һәм Россиядәге башка югары уку йортларында татар филологиясе бүлекләре ачыла. Татар теле, әдәбияты, татар тарихы белән беррәттән, барлык башка предметлар буенча ана телендә белем алу мөмкинлеге тудырыла.

Бу чорда күп югары уку йортларында татар телендә белем бирү буенча махсус төркемнәр ачыла. Югары уку йортларына керүче һәр абитуриентка имтиханны үз теләге буенча ике дәүләт теленең берсендә тапшыру мөмкинлеге тудырыла. Татар төркемнәрен оештыруның төп максаты – ике дәүләт телендә һөнәри эшчәнлек алып бара ала торган белгечләр әзерләү.

Татар төркемнәре оешу белән аларда белем бирә алырлык педагогик кадрлар һәм укыту-методик базаны булдыру мәсьәләсе күтәрелә, программа, методик әсбаплар, дәреслекләр төзү эшенә керешелә. Казан авиация, төзелеш, авыл хуҗалыгы институтлары галимнәре үз белгечлекләре буенча татар телендә дәрес конспектлары, программалар язалар. Бу проблемаларны яктырткан махсус конференцияләр уздырыла. 1997 елда Казан дәүләт төзелеш-архитектура институты базасында татар телен фән теле буларак торгызуны максат иткән «Фән һәм тел» журналы чыга башлый. Журналда татар телендә югары белем бирүнең төрле аспектларына багышланган мәкаләләр дөнья күрә, төрле фәннәр буенча татар телендә басылып чыккан укыту-методик әсбаплар тәкъдим ителә. Бу басма бер үк вакытта татар теленең фән теле буларак мөмкинлекләрен күрсәтүне максат итә.

Һәрбер уку йортында татар телендә белем бирүнең максат һәм бурычлары, эш юнәлешләре билгеләнә, иң беренче чиратта укытучылар өчен татар теле курслары оештыру хәл ителә, методик һәм терминологик комиссияләр төзелә, татар телендә белем бирә алучы укытучы-галимнәр әзерләнә. Татарча укытуга беренчеләрдән

булып Авыл хуҗалыгы, төзелеш академияләре һәм Кама политехник институтлары алына. Аларда 1993 елдан башлап татар телендә укыту алып барыла. 2000 елның урталарына Кама политехник институтында 70% студент татар телендә белем ала [2: 70]. Педагогик белем бирү йортларында (КДПУ, ЧДПУ һ.б.) татар төркемнәре ачыла.

1997 елда ТР югары уку йортлары каршында вузара фәнниметодик совет төзелә. Бу оешманың төп максаты – татар телендә методик әдәбият булдыру һәм татар телендә фәнни терминнар булдыру юнәлешендә эш алып бару. Татар дәүләт гуманитар-педагогика институты базасында Татар дәүләт университеты булдыру перспективасы ачыла.

Татар югары белем бирү системасын торгызуның беренче чорын (1990 еллар) милли үзаң күтәрелгән, идеаллар чоры буларак тасвирларга мөмкин. Икенче чор (1990 еллар азагы – 2000 еллар башы) булган мөмкинлекләрне күздә тотып, беркадәр нәтиҗәләр ясау, чынбарлыкны күзаллау чоры. Бу елларда мәсьәләнең икенче ягы күтәрелә: барлык фәннәрне дә татар телендә укыту кирәкме һәм барлык уку йортларында да татарча укыту мәҗбүриме? Р. Юсупов фикеренчә, бу очракта төп шартлар искә алынырга тиеш: кадрлар әзерләнә торган белгечлекләр, фәннәр, укытучыларның белем дәрәҗәсе, методик әдәбият белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе. Бу яктан караганда, галим фикеренчә, татар телендә укыту беренче чиратта педагогик уку йортларында алып барылырга тиеш. Шулай ук гуманитар өлкәдә эшләүчеләр (мәдәният, әдәбият, сәхнә сәнгате, музыкаль иҗат белән шөгыльләнүчеләр) ике телдә дә укырга тиеш. Һөнәр эшчәнлеге медицина, почта, транспорт белән бәйле, ягъни күпсанлы халык белән эшләүне күздә тоткан белгечлекләр буенча белем алучыларга шулай ук ике телне дә камил белү мәслихәт [22: 12]. Агросәнәгатьнең нигездә авыл шартларында тормышка ашырылуын исәпкә алганда, анда да татар һәм рус телләрендә белем бирү дөрес булыр [23: 3]. Техник уку йортларына килгәндә, Р. Юсуповның фикере үзгәрәк. Ул һәрбер техник уку йортында да татар телендә белем бирүнең максатка ярашлы булуына шик белдерә. «Техник терминнар русча түгел, нигездә интернациональ, инженер-техникларның эшчәнлеге эре предприятиеләр белән бәйле, аларда сөйләшү рус телендә алып барыла» [23: 3]. Р. Юсупов үз фикерен раслап шундый мәгълүмат

китерә: инглиз телле булмаган күп кенә дәүләтләрдә югары уку йортларында техник фәннәр инглиз телендә укытыла. Ләкин Татарстан шартларында, әгәр дә татар телен яхшы белгән укытучы була икән, техник фәнне дә татарча укыту мөмкин, ә татар мәктәбен тәмамлаучылар күп булган төркемнәрдә гомумән аерым фәннәрне татарча укыту уңышлы.

Кайсы фәннәрне мәҗбүри татар телендә укытуны Р. Юсупов һәрбер вуз үзе хәл итәргә тиеш дип саный. Монда беренче чиратта теге яки бу фәннең белгечлек өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы, нәтиҗәле итеп укыта алырлык милли укытучы-кадрларның булуы, студентларның татар әдәби телен яхшы белүләре һ.б. факторлар искә алынырга тиеш [23: 4].

Н.К. Туктамышов исә дәүләт теленең берсендә белем алучы кеше аның икенчесен дә яхшы белергә тиеш, билингвизм югары уку йортын тәмамлаучының мөмкинлекләрен арттыра гына дип саный [14: 43]. Галим фикеренчә, түбән курсларда татар телендә күбрәк фәннәрне укыту татар балалары өчен адаптация узарга ярдәм итә, туган телдә бирелгән материал яхшырак үзләштерелә.

Билингвизмны тормышка ашыруның төп шарты булып татар телен фән теле буларак дәрәҗәсен күтәрү тора. Бу, беренче чиратта, татар телендә фәнни-тикшеренү эшләре алып барылырга тиеш дигәнне аңлата. Соңгысы татар телендә фәнни терминология булдыруга турыдан-туры бәйле.

Фәнни атамалар булдыру, аларны әйләнешкә кертүдә иң үтемле юлларның берсе – төрле фәннәр буенча телара терминологик сүзлекләр төзү. Татар телендә укыту мөмкинлеге ачылу белән бу эшкә һәрбер уку йортының үз белгечләре дә кушылды. Нәтиҗәдә техника, төгәл фәннәр буенча дистәләрчә сүзлек дөнья күрде. Әмма алардагы төрлелек (бу чорда күп авторлар татарча атама ясау белән мавыга) татар телен фән теле буларак тулы канлы кулланылышына комачаулык итте. Терминнар мәсьәләсе, бер яктан, татар сүзләрен кире кайтару, аларга яңа мәгънә салу, яңа атамалар уйлап чыгару (мәсәлән, *санак* һ.б.), тәрҗемә итү белән барса, икенче яктан гарәп-фарсы атамалары, борынгы төрки сүзләрне кайтару белән билгеләнә. Нәтиҗәдә татар телендә язылган дәреслекләр авыр аңлаешлы булып, уку-укыту барышында куллану мөмкинлекләре чикләнүгә китерде. Шулай итеп, вузда укытыла торган һәрбер фән өлкәсенә карата татар фәнни-техник термино-

логиясен унификацияләү бурычы килеп басты. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак аерым фәнни тармаклар буенча вузара, шулай ук һәбер вузның үз эчендә эчке көчләр ярдәмендә татар телен камил белгән галимнәр катнашында махсус терминологик комиссияләр төзү тәкъдим ителде.

Техник фәннәрне укытучы белгечләр исәпләвенчә, татар телендә терминнар мәсьәләсен хәл итүдә иң беренче чиратта туган телгә карата сак мөнәсәбәт, аның эчке мөмкинлекләрен ача алу, яңа сүзләр төзүдә татар теленең үз закончалыкларыннан һәм сүз байлыгыннан файдалану, чит телдән терминнар керткәндә аларны рус теленнән түгел, ә бәлки төп, оригинал телдәге мәгънәсеннән чыгып эш итү мәҗбүри [1: 33], шул ук вакытта тәрҗемә ителгән атамаларның кыска һәм аңлаешлы булуы шарт [4: 69]. Мәсьәләнең тагын бер ягы – атамалардагы төрлелектән котылу: фәнни термин кулланылышында өзлеклелек сакланырга тиеш (мәктәп, вуз, җитештерү һ.б. өлкәләрдә). Бу яктан караганда, 90 елларда дөнья күргән бик күп дәреслек һәм методик әсбаплар әлеге таләпкә җавап бирә алмый.

Беренче чорда теге яки бу предмет буенча татарча дәреслек язу эшен һәрбер вуз үзе хәл итә. Бу исә әлеге әсбапларның бары тик бер уку йорты кысаларында гына файдаланылуына китерә, гомумкулланышка чыгу юлын тоткарлый. Нәтиҗәдә татар телендә төрле фәннәр буенча дәреслекләр язу эше билгеле бер тәртиптән азат булып, төрлелеккә китерә. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак, гомуми характердагы дәреслекләр төзү һәм бастыруны тәртипкә салу, үзәкләштерү, дәүләти координацион оешма тарафыннан җитәкчелек ителүе күрелә [22: 20]. Ә махсус, бик тар белгечлекләр буенча бу эш вузларның үзләренә калдырыла. Мисал өчен, Казан архитектура һәм төзелеш академиясендә 1991–1998 елларда 70 тән артык төрле дәреслек-кулланмалар, сүзлекләр бастырып чыгарылды һәм аларның күбесенең башка (мәсәлән, педагогик) уку йортларында да куллану мөмкинлеге билгеләнде [7]. Бу елларда техник һәм төгәл фәннәрне укыту буенча дәреслек һәм методик әсбаплар шактый әзерләнде, шулар арасында Р.Б. Сәлимов, Н.К. Туктамышовның «Математика» дәреслеген, С. Миңнулланың «Сызма геометрия»сен һ.б. атарга мөмкин. КДПУда математик анализ, геометрия, информатика, алгебра һәм саннар теориясе, молекуляр физика, квант физикасы, термодинамика, югары математика эле-

ментлары, коллоид химия һ.б. бик күп табигать-математика фәннәре татар телендә укытылды.

Билгеле булганча, 90 еллар башында ике яклы икелеттелек турында сүз алып барыла. Бу иң беренче чиратта, рус һәм татар телләрен бер үк дәрәҗәдә тормыш, яшәешнең төрле өлкәләренә кертү белән бәйле. Аның беренче адымнарын мәгариф системасында, бигрәк тә югары мәктәптә күрергә мөмкин. Татарстанда беренчеләрдән буларак, КДПИ ның барлык факультетларында да 64 сәгатьлек программа нигезендә [20: 40] 1991–92 елларда ике яклы икетеллелек тормышка ашырыла башлый, яки рус теле белән бергә рус һәм башка милләт телләрендә сөйләшүче студентларга татар теле укытыла. Ә үз ана телен белгән татар студентларына татар теле 1988/89 уку елында ук кертелә.

Югары уку йортларында татар телен укытуның төп максаты – студентларны татар әдәби телен практик рәвештә куллануга хәзерләү. 90 еллар урталарында барлык вузларда диярлек татар теле өйрәнелә; вузларда татар теле кафедралары ачыла [3: 84].

Төп проблема – укыту методикасы. Вузларда татар телен предмет буларак укыту өч төрле категория студентларга – татар телен бик яхшы белүчеләргә, начар белүчеләргә һәм бөтенләй белмәүчеләргә белем бирүне күздә тота. Шуңа күрә бу төркемнәрдә укыту өчен өч төрле методика һәм шуның нигезендә программа, дәреслек һәм башка уку әсбаплары эшләнергә тиеш. Югары уку йортларында татар телен өйрәтү киләчәктә татар телендә югары техник белем бирү мәсьәләсен хәл итүгә бер адым булып тора, чөнки һәрбер уку йорты тел мәгълүматларын үз белгечлекләренә карап тәкъдим итәргә тиеш. Бу исә төрле уку йортларында аерым программа һәм дәреслекләр туугa китерде. Бер яктан караганда бу үз-үзен аклый да кебек (һәр вузның үз үзенчәлекләре, терминнар базасы һ.б.). Әмма бердәм система буларак, үзәкләштереп укытуга килсәк, беркадәр кыенлыклар һәм каршылыклар тудыра.

Татар теле дәресләренең төп максаты – студентларны татар сөйләмен дөрес итеп аңларга (тыңлап аңлау), сөйләм процессында катнашырга (кара-каршы сөйләшү), билгеле бер темага сөйләү (монолог), дөрес итеп укырга, язарга һәм укыганны аңларга өйрәтү, күнекмәләр булдыру. Бу елларда дөнья күргән дәреслекләр нигездә шушы принципны истә тотып төзелә.

Татар телен өйрәтүдә иң еш кулланылган методларның берсе – татар телен чит телләргә өйрәтү методикасы нигезендә укыту [10]. Бу нигезгә корылган дәреслекләр (алар арасында электрон дәреслекләр дә бар) соңгы чорда бик күп уку йортларында дөнья күрде [17].

Шулай итеп, бу чорда (1990–2005) татар югары мәктәбен торгызу һәм аның эчтәлеген булдыруга игътибар ителде. Аның коцептуаль нигезләре, бурыч һәм максатлары, үсеш юнәлешләре билгеләнде, берникадәр дәрәҗәдә укыту-методик базасы булдырылды, татар теленең фән теле буларак үсешенә нигез салынды. Әмма төп максатлар (Милли университет төзү, Татар югары мәктәбенең концепциясен тормышка ашыру һ.б.) үтәлмәде. 2000 еллар башында, тел сәясәтендәге һәм, гомумән, мәгариф үсешендәге үзгәрешләр сәбәпле, татар теленә карата мөнәсәбәт үзгәрде. Бу проблемалар югары мәктәп эшчәнлегенә дә йогынты ясады: татар төркемнәре азайды, татар телендә язылган дәреслек һәм башка методик әсбапларның куланылыш даирәсе кимеде. Югары уку йортларында татарча укыту нигездә татар телен укытуга гына кайтып калды.

**Әдәбият**

1. Ахметов Л.Г., Тимербаев Р.М. Из опыта преподавания технических дисциплин в вузе на татарском языке // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 32–34 б.

2. Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае материаллары. Казан: БТК, 2002. 180 б.

3. Вәлиев Р. Татар телен куллану даирәсе киңәя // Мәгариф. 1998. № 4. 84 б.

4. Габбасов Н.С. Математик анализ фәне өлкәсендә татар теле // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 69–70 б.

5. Гыйззәтов К.Т.Философия: Кыскача философия тарихы. Философиянең нигез проблемалары. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 нче китап. Казан: Мәгариф, 2002. 448 б.; Гыйззәтов К.Т. Философия: Социаль философия. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 2 нче китап. Казан: Мәгариф, 2003. 407 б.

6. Гыйззәтов К.Т. Нәфасәт: нәфасәтнең нигез проблемалары. Кыскача нәфасәт тарихы. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 нче китап. Казан: Мәгариф, 2004. 495 б.; Гыйззәтов К.Т. Нәфасәт. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 2 нче китап. Казан: Мәгариф, 2006. 479 б.

7. Даутов Г.Ю., Галимов Д.Г., Тимеркәев Б.А. Физика. Югары техник уку йортлары өчен дәреслек. 3 кисәктә. Казан: Мәгариф, Кис. 1. 1999. 288 б.; Кис. 2. 2001. 344 б.; Кис. 3. 2002. 336 б.

8. Зәкиев М.З. Сүзлек составында терминнар һәм аларны тәртипкә китерү // Мәгариф. 1997. № 6. 32–35 б.

9. Мөбарәкҗанов Г.М. Математика тамгалары һәм терминнары, барлыкка килү тарихы. Казан: Фән, 2004. 245 б.

10. Салехова Н.Х, Максимова А.К., Харисова Ч.М. Интенсивное обучение татарскому языку. Казань: Магариф, 1993. 128 с.

12. Соловьева Е.Г. Язык и национальная культура в духовном становлении будущего педагога // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 44–46 б.

13. Татар телендә югары белем бирү концепциясе // Фән һәм тел. 1999. № 1. 10–15 б.

14. Туктамышов Н. Югары уку йортларында – икетеллелек // Мәгариф. 2001. № 1. 43–44 б.

15. Фәтхуллин В. Техник фәннәрне татарча укыту һәм бердәм терминнар булдыру // Мәгариф. 1997. № 4. 39–40 б.

16. Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И. Татар телендә югары белем бирү концепциясен төзү юлында // Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы. Казань, 1999. 9–12 б.

17. Харисов Ф., Харисова Г., Айдарова С. Татар теле читтелле аудиториядә. 2 кисәктә. Казан, 2009.

18. Шакирҗанов Р.Ә. Татар телендә югары белем бирү концепциясендә «Фән һәм тел» журналының урыны // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 51–52 б.

19. Шакирҗанов Р.Ә. Татар теленең танып-белү алгоритмын фән һәм җәмгыятьне үстерү өчен куллану // Фән һәм тел. 2002. № 3. 53–58 б.

20. Харисов Ф. Икетеллелек: студентлар татарча сөйләшә // Мәгариф. 1998. № 7. 40 б.

21. Юлдашев А.К. Безнең бурычлар // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 38–40 б.

22. Юсупов Р.А. Преподавание на татарском языке в педагогических вузах Республики татарстан // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. Казан, 1998. 12–22 б.

23. Юсупов Р. Югары белемне – ана телендә // Мәгариф. 2002. № 6. 3 б.

24. Ягъфәров Р. Мәктәбе булган халык – мәңгелек // Мәгариф. 1993. № 10. 3 б.

## HIGHER EDUCATION IN THE TATAR LANGUAGE (1990–2005 years)

***Murtazina Lyalya Raisovna,***
*Candidate of pedagogical sciences,*
*Sh. Marjani Institute of History,*
*Tatarstan Academy of Sciences,*
*lyalyamur@mail.ru*

The paper analyzes the problem of education in Tatar language and teaching of Tatar language in higher educational institutions in 1990–2005. A condition of training in Tatar language, conceptual bases of teaching, methodical approaches, educational literature, scientific terminology in Tatar language is especially examined.

***Keywords:*** higher education, mother-tongue education, teaching methods, textbooks, scientific terminology.

УДК 37.01(075)

# НОВЫЕ ВРЕМЕНА, НОВЫЕ ИЗМЕРЕНИЯ РОДНОГО ЯЗЫКА В ВЫСШЕМ ОБРАЗОВАНИИ

***Туктамышов Наил Кадырович,***
*доктор педагогических наук,*
*Казанский государственный*
*архитектурно-строительный университет,*
*nail1954@gmail.com*

В статье проведен анализ перспектив обучения на татарском языке в высших учебных заведениях Татарстана. Делается вывод, что наиболее оптимальным в сложившейся на сегодняшний день ситуации средством сохранения функциональности татарского языка является развитие в РТ полилингвального образования.

***Ключевые слова:*** образование, язык, полилингвальное образование, обучение, образовательное пространство.

Начиная с конца XX века, с переменным успехом идет национальное строительство в Татарстане. Это сложный многоступенчатый процесс, состоящий из множества взаимосвязанных и взаимовлияющих друг на друга компонентов. Без сомнения, сюда стоит включить и построение национальной системы образования, включающей в себя и высшее образование. Ясно, что, находясь в едином образовательном пространстве Российской Федерации, образование на татарском языке должно быть построено таким образом, чтобы создалась возможность не только в получении высшего образования на татарском языке, но и возможность выхода в мировое образовательное пространство. Здесь возникают определенные трудности, связанные с тем, что, во-первых, татарский язык действует как государственный только на территории Татарстана, а гражданам РТ приходится работать и учиться на всей территории РФ. Эта трудность сдерживает развитие татарского языка, снижает его престижность по сравнению с русским языком, государственным языком РФ, открывающим перед молодым

человеком более широкие возможности. Свое отношение к введению государственных языков на территории России выдающийся языковед И.А. Бодуэн де Куртенэ в 1905 г. высказал следующим образом: «Ни один язык не считается государственным и обязательным для всех образованных граждан, но, по соображениям наименьшей траты времени, языком центральных государственных учреждений, языком общегосударственной думы должен быть язык преобладающей численно национальности, язык обоих центров, Петербурга и Москвы, язык великорусский. Тем не менее, в общегосударственной думе не может быть воспрещено употребление других языков. Каждому гражданину предоставляется право сноситься с центральными учреждениями на своем родном языке. Дело этих центральных учреждений – обзавестись переводчиками со всех языков и на все языки, входящие в состав государства».

Вторая трудность, стоящая перед татарским языком, – это широкое распространение английского языка во всем мире. Около 70 % научной информации мира содержится в изданиях на английском языке. Не секрет, что многие русскоязычные предпочитают изучать английский язык, а знания татарского языка (обязательного предмета в школе) оставляют желать лучшего. Как показывают исследования, русскоязычные считают изучение татарского языка полезным, а изучение английского языка – необходимым. Хотя следует указать, что сами татары в подавляющем большинстве своем считают изучение татарского языка и полезным, и необходимым, так как они, благодаря высокому культурному уровню и самосознанию, не потеряли еще своей национальной идентичности. При этом нельзя не заметить, что татарский язык в перспективе имеет мало шансов на выживание, если он будет опираться только на гуманитарную составляющую человеческого существования. Очень важно, чтобы язык был функциональным, т.е. был использован и востребован в сферах высоких технологий, в фундаментальных и прикладных исследованиях, в бизнесе и т.д. Не нужно забывать, что язык является не только символом национальной идентичности, но и является средством постижения мира специальных знаний, благодаря чему он и приобретает престижность. Очевидно, английский язык имеет высокий международный престиж именно благодаря тому, что он является языком науки и технологий.

Таким образом, татарский язык находится на самом деле в весьма сложной ситуации, он «зажат между двумя престижными языками». Следует заметить, что в такой же ситуации находятся все языки Российской Федерации, кроме русского. Снять напряжение в вопросах развития татарского языка могут различные законодательные акты, регулирующие языковое строительство в РФ и РТ. Успешность языкового регулирования зависит во многом от учета исторического опыта в решении данного вопроса. Каждая нация имеет собственную имплицитную концепцию обучения и воспитания. Разработать единую, универсальную для всех этносов теорию невозможно. Представляет интерес выделение тех фундаментальных положений, которые необходимо учитывать при построении национальных образовательных систем. Здесь можно выделить следующие измерения.

1. Концептуальное измерение. Образовательная система этносов складывается в процессе их длительной борьбы за существование, которая требовала накопления как неких теоретических знаний, так и практических навыков, зависящих от географических, климатических и иных условий. Заметим, что накопление теоретических знаний не происходит в отрыве от получения в процессе каждодневной деятельности практических умений. Таким образом, в процессе борьбы за существование у сообщества складываются единые позиции как теоретического, так и практического планов, что формирует в конечном итоге культуру того или иного народа, его традиции, быт, семейные отношения, обряды и т.д.

2. Историческое измерение. Формирование традиций не происходит в изолированном пространстве, а знания, практические навыки возникают и исчезают в процессе динамического развития и взаимодействия народов на той или иной территории. Здесь можно выделить этапы независимого развития этносов и этапы, когда те или иные народы теряли свою независимость и традиционные методы обучения.

3. Познавательное измерение. Что есть мысль, сравнение, классификация, измерение, объяснение, обобщение – вот те только некоторые формы обдумывания настоящего, которые всегда волновали людей. Естественно, что эти понятия были у каждого народа, и они по-своему объяснялись. Познавательный процесс и практическое действие всегда идут вместе. Любая нация, этни-

ческая общность познает окружающий мир и пытается выйти за пределы непосредственно видимого. В народном творчестве формируются представления о пространстве и времени. В соответствии с Мак Нейлом песни и танцы были первыми инновационными шагами человеческого вида [1]. Появление песен отражает временное представление, а танцев – пространственное. Поскольку разные этносы имеют разные танцы и песни, то ясно, что изучение танцев и песен народов мира может очень многое дать в изучении познавательных процессов. Важнейшим аспектом исследования познавательных процессов является языковой аспект. В различных регионах планеты формируются различные языки, отражающие условия жизни и выживания народов. Через свою историю и свое существование этносы создают и развивают инструменты познания для отражения и наблюдения (как материальные, так и интеллектуальные), чтобы объяснить мир, а объединяясь в сообщества, через свой язык создают различное социальное и культурное окружение.

4. Культурное измерение. Эскимосы на севере живут рыбной ловлей, поэтому у них очень смутные представления о сельском хозяйстве, народы экватора плохо себе представляют возможности существования в условиях севера и т.д. Это накладывает определенный отпечаток на складывающуюся культурную традицию народов, что в свою очередь влияет на способы и средства обучения. В условиях урбанизированных ландшафтов и культуры современного общества выживание этносов, национальных школ возможно, если они опираются на традиционную для своего народа социально-общественную и профессиональную нишу, учитывающую культурологические и фольклорно-этнографические аспекты национального воспитания и обучения. Здесь уместно сказать несколько слов о столкновении культур. Оно может происходить в мягкой толерантной либо в жесткой, непримиримой формах, оно зависит от концепции культур, суверенитета народов, соображений удобств, доминирования того или иного народа и их ценностей, навязывания этих ценностей другим. Очевидно, когнитивные способности не могут эволюционировать вне культурного контекста, поэтому познавательные стили могут быть осознаны как в межкультурном, так и в интракультурном контексте.

5. Социально-политическое измерение. Политика самым непосредственным образом влияет на становление либо уничтожение тех или иных народных традиций, методов и форм воспитания. Скажем, 2500 лет назад в Средиземноморье существовали народные традиции, основанные на язычестве, но появление иудаизма с его идеей единобожия перевернуло быт, манеру поведения народов, проживающих вдоль побережья Средиземного моря. Принятие Ислама в Волжской Булгарии, в Золотой Орде существенным образом изменило традиции предков татар. Принятие Ислама потребовало проведения правящими кругами соответствующей политики. Государственная политика в странах, где существуют колонии, часто направлена на уничтожение культурных традиций коренных народов. Например, культура североамериканских индейцев белыми переселенцами была практически сведена на нет. Часто подавляются познавательные силы коренных народов под маской бесперспективности языков коренных народов в области науки и современных технологий. В этнографии и ряде других общественных наук практикуется методологическое разделение, идущее от К. Маркса, «на высокоразвитые народы и народы, отстающие в своем развитии», однако такое разделение на основе технологий, включая письменность, обусловливающих экономические отношения, во многом некорректно, так как не рассматривает адаптационные, экологические достижения народов в целом.

В связи с острыми противоречиями между сторонниками жесткого государственного контроля системы высшего образования и сторонниками либеральных подходов встает фундаментальный вопрос о соотношении между общероссийскими, местными и глобальными ценностями, создания сбалансированной общекультурной миссии вуза с функцией достаточной прикладной специализации. Следует заметить, что усиление роли бюрократии и бюрократических методов управления может привести к выхолащиванию миссии вуза, т.к. она заключается не только в решении государственных задач, но и в выполнении общественных наказов и потребностей, а интересы государства и общества не всегда совпадают. В ст. 10 «Всемирной декларации о высшем образовании для XXI века» подчеркивается необходимость усиления внимания к конкретным национальным и региональным условиям с тем,

чтобы учитывать многообразие и избегать унификации высшего образования, актуальность требования международного измерения высшего образования как одной из неотъемлемых характеристик современного качества.

Успешность реализации национального образования зависит во многом от языковой политики государства. Она на сегодняшний день не представляется вполне определенной. Нет ясности в определении того, какое место должно занимать обучение на татарском языке в рамках системы образования РФ и РТ. Например, в КГАСУ выпускников с двуязычным обучением около 25 человек в год, а русскоязычных – около 400, хотя выпускников национальных общеобразовательных школ Татарстана по официальным данным около 47 %. Этот пример ясно демонстрирует место татарского языка в высшем образовании.

Основной приоритет, который должен преобладать в развитии высшей школы, – соответствие содержания образования и его уровня технологическим, экономическим, социальным вызовам, которые возникают перед нашей цивилизацией в XXI веке.

Высшая школа решает три основные задачи:

1) подготовка элиты общества, т.е. небольшого количества людей, которые со временем будут принимать стратегические решения в различных областях;

2) массовой подготовки специалистов, которая состоит в передаче профессиональных стандартов большому количеству людей;

3) сохранения и передачи «генетического кода» общества, под которым понимается передача поколениям моральных, этических норм, языка, образов, принятых в обществе.

Высшее образование на татарском языке получает очень незначительная часть студенчества Татарстана (это гуманитарное образование в КФУ, оставшееся в наследство от бывшего педагогического института, имеются группы с двуязычным обучением в КГАСУ, КНИТУ). Ясно, что такое количество студентов, использующих родной язык при получении высшего образования, не решает задачу массовой подготовки специалистов, свободно владеющих профессиональным татарским языком. Что касается подготовки элиты, то можно отметить, в частности, что в строительном деле число занимающих в этой отрасли доминирующее

положение специалистов, владеющих татарским языком, увеличивается. Однако эти подвижки незначительны. Передача «генетического кода» татарской нации достаточно эффективно осуществляется Институтом филологии и межкультурных коммуникаций КФУ. Таким образом, можно констатировать, что решение первой и третьей задачи высшей школы каким-то образом осуществляется, но делается это в основном за счет энтузиазма патриотически настроенных преподавателей вузов и держится на их инициативе.

Однако, и в существующей ситуации, когда в обществе мы наблюдаем столкновение идеологий патриотизма, космополитизма и национализма, тесно связанных с языковыми проблемами, есть возможности для развития национальной системы образования. Выход из сложившегося положения видится в создании условий для развития в Татарстане полилингвального образования. В условиях Татарстана имеются все объективные социальные, психолого-педагогические, экстралингвистические предпосылки для перехода к полилингвальному обучению. История развития образования татар, этнопедагогические исследования, двуязычие в системе общего среднего образования, соответствие корпуса языка его статусу создают необходимые условия для создания системы полилингвального образования в РТ. Создание системы полилингвального образования требует решения юридических, организационных, научно-педагогических проблем.

Россия подписала ряд международных документов, обязывающих ее уделять должное внимание развитию образования на языках народов, населяющих РФ. В частности, в «Конвенции о борьбе с дискриминацией в области образования» подчеркивается, что «выражение “дискриминация” охватывает всякое различие, исключение или предпочтение по признаку расы, … языка, … национального или социального происхождения … и, в частности:

а) закрытие для какого-либо лица или группы лиц доступа к образованию любой степени или типа;

б) ограничение образования для какого-либо лица или группы лиц низшим уровнем образования...

В «Конвенции об обеспечении прав лиц, принадлежащих к национальным меньшинствам» (Москва, 21 октября 1994 г.) в ст. 10 утверждается, что «…признавая необходимость изучения государственного языка в соответствии с законодательством Дого-

варивающейся Стороны, создавать с учетом имеющихся потребностей соответствующие условия для изучения национальными меньшинствами родного языка и получения образования на родном языке, включая открытие и поддержание образовательных учреждений различного уровня, финансируемых из различных источников».

Кроме того, согласно пункту 7 статьи 1 Федерального закона «О государственном языке Российской Федерации» обязательность использования государственного языка Российской Федерации не должна толковаться как отрицание или умаление права на пользование государственными языками республик, находящихся в составе Российской Федерации, и языками народов Российской Федерации. Паритетное использование двух государственных языков РТ с точки зрения социолингвистики является оптимальным как с позиции сохранения родного языка, так и полноценного функционирования русского языка. Такой подход позволяет сохранить возможность гарантированных Конституцией РФ принципов равенства прав и свобод человека и гражданина и несения гражданами РФ равных обязанностей на всей ее территории. Сомнения, заключающиеся в том, что широкое использование родного языка (или иностранного) в вузах приведет к сужению пространства русского языка противоречит тому простому факту, что, например, преподавание на английском языке в вузах не только не приносит ущерба русскому языку, но и расширяет возможности выпускника вуза в трудоустройстве, расширяет его культурный горизонт.

В организационном плане система национального образования нуждается в создании специальных органов государственного управления, занимающихся разработкой государственных планов по развитию национального образования РТ, включая высшее, не нарушающих целостности образовательного пространства России.

Определение целей полилингвального образования представляет собой сложную задачу, включающую в себя: овладение предметным знанием на двух или более языках; формирование у обучаемых знаний о сущности культуры как интегрирующего социально-экономического феномена; формирование у учащихся знаний о гражданско-правовых, исторических, этнических особенностях, этнической дифференциации и глобализации; воспитание культуры речи, межнационального общения, толерантности и т.д.

Билингвальное (полилингвальное) образование может в дальнейшем отчасти трансформироваться в успешно функционирующую систему национального образования, позволяющую активно использовать языковую среду, создать условия для этнокультурного самовыражения, интегрироваться в мировое образовательное пространство.

Научные исследования в области полилингвального образования базируются на трех философских традициях [2]. Первой из них можно назвать структурно-функциональной традицией, которая фокусируется на изучении масштабных общественных трендов в использовании языка в социально-неоднородном обществе; сравнительной работе и построении типологий билингвальных сообществ; использовании диглоссии при построении моделей обучения по иерархии престижности языков. Вторая традиция акцентирует свое внимание на изучении смыслов и значений в социальных взаимодействиях в условиях языкового разнообразия. Третья традиция предполагает исследование связей между социально-политическими аспектами полилингвизма и неравным распределением языковых ресурсов.

Построение системы полилингвального образования требует создания различных программ, финансируемых государством: поддерживающие полилингвальное образование программы, так называемые программы погружения, двойные языковые программы и т.д. В нашей республике построены различные билингвальные модели обучения, нашедшие свое применение в образовательной практике в Татарстане (модель перехода к двуязычному образованию в высшей школе, дидактическая модель билингвального обучения математике в высшей школе, концепции национального образования и др.). Следует подчеркнуть, что в Татарстане достигнуты значительные успехи в части обучения на полилингвальной основе: есть высококвалифицированные кадры, создана учебно-методическая база преподавания различных дисциплин на двуязычной основе (имеются учебно-методические комплексы по математике, физике, химии, теоретической механике, строительным материалам и т.д.), увидели свет терминологические словари по математике, химии, строительной механике, геодезии и т.д., разработана солидная научная база (научные работы В.Ф. Габдулхакова, Ф.Ф. Харисова, Л.Л. Салеховой,

Н.К. Туктамышова и др.). Тем не менее, необходимо иметь в виду, что обучение на полилингвальной основе имеет еще множество нерешенных проблем и требует дальнейшей разработки, а формальное обучение на многоязычной основе может привести к отрицательным результатам.

Несколько слов о двуязычном обучении математике. Исследование возможностей использования татарского языка в математике показывает, что этот язык вполне может быть языком математической науки. Этот факт подтверждает вся история математического образования татар, начиная с рукописи «Тафтазани» С. Масгуда (ум. в 1389 г.), работами Мухеддина Мухамади Ахметши. С конца XIX века в России начали складываться так называемые новометодные медресе («Буби», «Касимия», «Мухаммадия» и др.), в которых изучались не только практически ориентированные области арифметики, геометрии и алгебры, но и основы физики и астрономии. Отмеченные учебные заведения вырабатывали свою методологию и методику обучения математике, в частности, можно отметить обучение на основе эвристического метода, базирующегося на беседах, диспутах. Издаются такие учебники по математике на арабском языке, как «Полная арифметика целых чисел» (1898, Г. Давлетъяров), «Практические и теоретические способы геометрии» (1908, Мухаммед-Зыя Бахтияр), «Алгебра» (1910, И. Тахир) и другие. Как видно, уже тогда у татар имелся опыт обучения на нескольких языках. Образование, полученное в этих учебных заведениях, позволяло продолжить обучение во многих высших учебных заведениях Европы и мира. В 1911 году английский журнал «The Muslim World», анализируя учебные планы новометодных медресе, отмечал, что они сходны с учебными планами классических гимназий, в них место латинского и греческого языков занимали арабский и персидский языки. Многие выпускники этих образовательных учреждений продолжали обучение за границей. Например, в 1909 году в Стамбуле обучалось 63 татарина (в том числе в университете 14 человек, в училищах султана 4 человека). Следует отметить, что образование за границей получали не только мужчины, но и женщины. Так, выдающегося успеха добилась С. Шакулова – одна из первых татарских женщин с высшим математическим образованием. В

1913 году она получила диплом факультета точных наук в Сорбонне.

Языковые конструкции на татарском языке вполне адекватно описывают соответствующие математические структуры. Следует также отметить, что принципы образования терминов на татарском языке исследованы, а терминологический аппарат по существу создан. Изданы учебники и учебные пособия по высшей математике на татарском языке.

Большой интерес представляет изучение интеграционного процесса объединения в нечто целое математики и языка. Дело в том, что математика, как и все естественные науки, сама создает свои понятия и категории, которые ей нужны для описания и объяснения, а лингвистика находит свои понятия и категории уже полностью готовыми в своих языках. В определенном смысле языковые понятия образуют интерпретационную сеть, которая «набрасывается» на математику. Это обстоятельство сильно затрудняет выявление закономерностей билингвального обучения математике.

Можно с уверенностью сказать, что полилингвальное образование, как один из вариантов решения проблем высшего образования на татарском языке, имеет большой внутренний потенциал, но для его раскрытия должны быть проведены определенные мероприятия. При АНТ должна быть создана научная лаборатория по комплексному изучению проблем двуязычия (не только татарско-русского), которая могла бы участвовать в разработке, рецензировании, в выпуске дидактической литературы, в оценке учебных результатов, в подготовке и переподготовке национальных кадров. Для реализации билингвального (полилингвального) образования необходима отдельная (не в рамках программы развития языков народов РТ) государственная программа функционирования двуязычия (многоязычия) в системе образования, важно внесение некоторых изменений в Закон РФ «Об образовании» и Федеральный закон «О высшем и послевузовском профессиональном образовании», а также принятие некоторых других законов, касающихся статуса и функционирования государственных языков республик РФ.

**Литература**

1. Mc Neil, William H / «Passing Strange: The Convergence of Evolutionary Science with Scientific History», History and Theory, v. 40, N. 1, February, 2000, pp. 1–15.

2. Martin-Jones, M. (2007) Bilingualism, education and the regulation of access to language resources. Basingstoke, Hampshire: Palgrave.

## NEW TIMES AND NEW DIMENSIONS OF NATIVE LANGUAGE IN HIGHER EDUCATION

***Tuktamyshov Nail Kadyrovich,***
*Doctor of pedagogical sciences,*
*Kazan state university of architecture and engineering,*
*nail1954@gmail.com*

Perspectives of the education in Tatar language in the universities in Tatarstan analyzed in article. Autor came to conclusion that the optimal way for keeping Tatar language today is the development of polylingual education in Tatarstan.

***Keywords:*** education, language, polylingual education, teaching, educational space.

УДК 37:001.12/.18

# О КОГНИТИВНЫХ ИЗДЕРЖКАХ БИЛИНГВАЛЬНОГО ОБУЧЕНИЯ СРЕДСТВАМИ РУССКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОВ

***Салехова Ляйля Леонардовна,***
*доктор педагогических наук,*
*Казанский (Приволжский) федеральный университет,*
*salekhova2009@gmail.com*

При реализации двуязычных образовательных программ неявно предполагается, что знания представляются в виде системы, не зависящей от конкретного языка обучения. В данной статье исследуется возможность возникновения когнитивных издержек и их типы при билингвальном обучении математике. В педагогическом эксперименте участвовало 39 учащихся двуязычных (татарско-русских) школ Республики Татарстан. Результаты показывают, что если язык контроля знаний отличается от языка обучения, учащиеся могут иметь когнитивные издержки, которые проявляются в снижении точности и скорости обработки информации.

***Ключевые слова:*** билингвальное обучение, когнитивные издержки, язык обучения, язык извлечения знаний, переключение языков.

***Введение.*** Нет сомнений, что билингвизм имеет большие преимущества, способность человека общаться на другом языке является одной из ключевых компетенций, которая становится все более актуальной на фоне растущей мировой глобализации. Учеными доказано и жизненная практика показывает, что билингвальное обучение развивает основные когнитивные функции мозга, а именно способность человека понимать, познавать, изучать, осознавать, воспринимать и перерабатывать внешнюю информацию, улучшает способность контроля исполнительских функций, которые задействованы при появлении новых, ранее не встречавшихся стимулов, тем самым обеспечивая когнитивную гибкость мозга [1–3].

Однако билингвальное обучение может иметь и отрицательные последствия, поскольку нельзя ожидать, что информация, полученная учащимся на одном языке, может быть переработана им на другом языке так же хорошо, как на родном языке [4].

Целью статьи является исследование когнитивных издержек, возникающих при билингвальном обучении, в тех ситуациях, когда языки обучения и переработки информации у обучающихся различаются.

По нашему мнению, эта проблема носит фундаментальный характер, как в общероссийском, так и в международном масштабе. Например, в российских школах с нерусским (якутским, татарским, северо-осетинским, адыгейским и т.д.) языком обучения предметное обучение в старших классах ведется на билингвальной основе средствами русского и национального языков, поскольку Единый государственный экзамен проводится в РФ на русском языке. Если говорить о высшей школе, то сейчас во многих развитых странах (Нидерландах, Финляндии, Дании и т.д.), в том числе и в России, актуальным является вопрос привлечения в университеты и обучения иностранных студентов. В основном образовательные программы для иностранных студентов преподаются на языке международного общения – английском. Ясно, что для многих студентов-иностранцев он не является родным, поэтому они, по определению, находятся в ситуации билингвального обучения.

Анализ исследований зарубежных ученых по выявлению и изучению когнитивных издержек, проявляющихся в процессе билингвального обучения, например, математике, показал, что они обнаруживаются в тех случаях, когда при реализации двуязычных образовательных программ неявно предполагается, что знания представляются в виде системы, не зависящей от конкретного языка обучения учащегося.

Научные исследования, проведенные учеными Gentner D., Goldin-Meadow S. [5], Gumperz J.J., Levinson S.C. [6], Malt B.C., Wolff P. [7], свидетельствуют о том, что представление знаний тесно связано с языком обучения и родным языком обучающегося.

Например, было установлено, что родной язык в области математики влияет на количественные представления и на правильность вычислений. Так, Gordon P. [8] изучал индейцев племени

Пираха (Pirahã) – небольшой народности около 420 человек, проживающей в Бразилии, язык которых характеризуется очень ограниченным словарным запасом в отношении общих понятий, отсутствием местоимений и числительных. Аборигены используют для числительных только слова "один", "два" и "много". Gordon P. обнаружил, что индейцам не удается справиться с такой простой задачей, как копирование линий, начерченных на листе бумаги, когда их больше двух или трех.

Межкультурные исследования показали, что различия в языковых структурах, например, для языкового выражения систем счисления, отражаются в трудноуловимых кросс-лингвистических различиях в математическом познании и в развитых сообществах. Так, Miller, K.F., Smith, C.M., Zhu, J., & Zhang, H. [9] и Miller, K.F., & Stigler, J.W. [10], обнаружили, что на начальном этапе обучения счету и арифметическим операциям китайские дети, разговаривающие на языке мандарин, обладают преимуществом по сравнению с англоговорящими сверстниками.

Таким образом, представление знаний зависит от конкретного языка обучения, следовательно, могут возникнуть негативные последствия при их переносе из одной репрезентативной системы человека, то есть из системы, посредством которой человек воспринимает и использует информацию, поступающую из внешнего мира, в другую. Следовательно, негативные последствия могут проявляться в тех случаях, когда языки обучения и извлечения знаний отличаются. Наличие данного эффекта было подтверждено в масштабных исследованиях, проведенных Spelke E.S., Tsivkin S. [11]. Они наблюдали за взрослыми сбалансированными русско-английскими билингвами в процессе решения ими различных математических задач на двух языках (русском и английском). Все задачи были сформулированы в виде текстовых, с использованием количественных числительных. Например, «Найти сумму пятидесяти четырех и сорока восьми» («What is the sum of fifty-four and forty-eight?»). Основной целью ученых было выявление наличия или отсутствия когнитивных издержек в случае, когда язык обучения отличается от языка проверки знаний. Взрослые билингвы решали четыре типа математических задач. В двух типах требовалось обрабатывать точные факты, например, прибавлять число 54 к различным двузначным числам или производить

операцию сложения в системе исчисления с основанием 6. Такого типа задачи назывались “точные задачи”. В двух других типах задач требовалось обработать большое количество иррациональных и трансцендентных чисел. Например, вычисление корней третьей степени из числа или логарифма от числа, то есть решались “задачи аппроксимации”.

Тест, проведенный после тренировочного обучения, проводился на двух языках – английском и русском. Он показал, что участникам эксперимента понадобилось больше времени на решение “точных задач”, когда язык обучения отличался от языка тестирования, чем когда оба языка были одинаковые, независимо от того, были это знакомые задачи или нет. При решении участниками эксперимента “задач аппроксимации” когнитивных издержек обнаружено не было. В дополнительно проведенных экспериментах негативные эффекты от переключения языков, обнаруженные при решении “точных задач” по математике, были выявлены вновь. Spelke E.S., Tsivkin S. [11] выяснили, что эффекты от переключения языков также сохраняются при решении “точных задач” на обработку числовой информации из нематематических контекстов, например, при запоминании исторических дат, решении химических уравнений или физических и биологических задач.

Результаты исследований Spelke E.S. и Tsivkin S. о негативных последствиях от переключения кодов (языков) при решении “точных задач” коррелируют с известной моделью тройного кода Dehaene S., Cohen L. [12], которые выдвигают гипотезу о существовании трех различных видов представлений чисел в человеческом мозгу:

1. представление о величине, независимое от языка;
2. аудио-вербальный код;
3. визуальное представление, записанное арабскими цифрами.

Они пришли к выводу, что решение “приближенных задач преимущественно связано с представлением о величине, не зависимым от языка. Решение “точных задач” связано, в основном, с аудио-вербальным кодом.

Marian V., Fausey C.M. [13] также пришли к заключению о возникновении негативных последствий от переключения языковых кодов при билингвальном обучении. Они наблюдали за взрослыми испано-английскими билингвами, которые изучали

некоторые разделы химии, биологии и истории на одном из двух языков. После завершения обучения участники должны были ответить на вопросы по изученному материалу. Marian, V., & Fausey, C.M. обнаружили, что участники эксперимента давали ответы на вопросы быстрее тогда, когда язык тестирования совпадал с языком обучения.

Таким образом, если язык тестирования отличается от языка обучения студентов или взрослых, тогда могут иметь место когнитивные издержки, **состоящие в снижении точности и скорости обработки информации**. Но можно ли делать из проведенного анализа литературы глобальные выводы, которые имеют практическое значение для реализации и оценки двуязычных программ обучения? Существует несколько причин, чтобы поставить под сомнение обобщения из предыдущих выводов:

– во-первых, участники данных исследований были специально отобранные студенты университетов или взрослые люди, а не учащиеся средних школ, обучающиеся по двуязычным программам;

– во-вторых, эффекты от переключения языков в основном наблюдались у "сбалансированных билингвов", то есть билингвов, которые в равной степени хорошо владели обоими языками;

– в-третьих, экспериментальные периоды обучения, представленные в предыдущих исследованиях, были краткосрочными, и тестирование проходило сразу же после обучения. В реальной школе учебные темы изучаются, по крайней мере, несколько дней.

Эти ограничения предыдущих исследований оправдывают необходимость их проверки и расширения исследований на контексты, которые ближе к реальной образовательной практике. Нами были сформулированы теоретические гипотезы, правильность которых необходимо было проверить эмпирически.

***Гипотезы исследования.***

Необходимо было выяснить, имеют ли учащиеся старших классов, обучающиеся в школах Республики Татарстан на двуязычной татарско-русской основе, те же когнитивные издержки от переключения языков при решении математических задач, которые наблюдались у взрослых билингвов в обсужденных выше исследованиях? Двуязычный метод обучения математике в школах с татарским языком обучения РТ выбирается учителями старших

классов в связи с тем, что ЕГЭ по математике является обязательным для всех учащихся РФ, и он проводится на русском языке.

Целенаправленное и систематическое посещение билингвальных уроков по математике, интервью с учителями, реализующими билингвальные образовательные программы, и с учащимися, обучающимися на двуязычной основе, результаты анализа предыдущих теоретико-эмпирических исследований позволили выдвинуть следующие гипотезы, подлежащие проверке.

Гипотеза 1а состояла в том, что когнитивные издержки от переключения языков в процессе решения математических задач, по которым прошло тренировочное обучение, будут проявляться в обеих группах участников эксперимента: и у тех, кто прошел обучение на татарском языке, и у тех, кто на русском языке. Гипотеза 1б состояла в том, что при решении новых, неподготовленных математических задач, отрицательных эффектов от переключения языков наблюдаться не будет ни в одной из групп.

Исследовался также вопрос о том, зависит ли проявление когнитивных издержек при переключении языков с русского на татарский и наоборот от типа решаемых математических задач (т.е. будут ли наблюдаться различия при решении задач на умножение и на вычитание)? Было выдвинуто предположение, что степень их проявления должна быть сильнее в задачах на умножение, чем на вычитание (гипотеза 2).

Наконец, мы предположили, что когнитивные издержки проявляются сильнее, когда обучающиеся переключаются с доминантного (татарского) языка на второй (русский) язык (гипотеза 3).

***Методы исследования.***

В педагогическом эксперименте участвовало 39 учащихся (из них 19 девочек) из двух классов (9-ого и 11-ого) двуязычных школ Республики Татарстан. Родным языком учащихся был татарский язык, и до поступления в школу они не говорили на русском языке. Возраст учащихся колебался от 15 до 17 лет. Школа, в которой проходил эксперимент, реализовывала в старших классах билингвальное обучение математике средствами татарского и русского языков.

На момент проведения педагогического эксперимента его участники хорошо говорили на русском языке, так как изучали

русский язык как школьный предмет с 1 класса, кроме того, подспудно они находились в двуязычной татарско-русской среде, благодаря телевидению, радио, интернету и т.д. Однако использование русского языка ограничивалось школьным контекстом.

Участники педагогического эксперимента прошли три тренировочных обучения в течение четырех дней. Первое обучение прошло в школе под наблюдением экспериментаторов сразу после уроков. Последнее – было проведено в школе также под наблюдением экспериментаторов. Что касается второго обучения, то учащиеся могли самостоятельно выбрать день (третий или четвертый) и место (дома или в школе). На школьных компьютерах учащиеся могли тренироваться в свободное время. Данные о результатах тренинга были отправлены экспериментаторам по электронной почте. Компьютерная программа для тренинга была написана в программе Maple.

Язык обучения был сбалансирован между участниками эксперимента, учащиеся 9 и 11 классов были одинаковым образом распределены по языкам обучения (татарскому или русскому). Каждый тренинг начинался с чтения числительных, далее учащимся предлагалось 5 тренировочных модулей. Каждый тренинг продолжался примерно 20 минут. Тренинг состоял из решения 14 задач на вычитание и 14 задач на умножение, половина задач была сформулирована на татарском языке, половина – на русском языке.

В итоговый тест кроме задач, по которым прошло тренировочное обучение, дополнительно было включено 14 новых задач на вычитание и 14 задач на умножение. Они были добавлены для того, чтобы изучить, как участники эксперимента справляются с решением новых задач.

В процессе анализа результатов тестирования по двум критериям “время получения правильных ответов” и “точность вычислений” использовался многофакторный регрессионный анализ. В качестве независимых переменных были взяты следующие: “обучение” (то есть “старые” и “новые” задачи), “переключение языков” (то есть оно присутствовало или нет), “операции” (то есть умножение или вычитание). В качестве зависимой переменной выступал “язык обучения” (татарский или русский).

***Результаты и их обсуждение.***

Как и предполагалось (гипотеза 1а), негативные эффекты от переключения языков проявились в виде задержки по времени и ухудшения точности решения задач на умножение и вычитание, по которым учащиеся проходили тренинги до начала контрольного испытания. В случае неподготовленных “новых” задач, был обнаружен единственный негативный эффект от переключения языков – это увеличение среднего времени на выполнение задания (гипотеза 1b).

Было установлено, что вид операции (умножение или вычитание) влияет на латентность (время между началом действия раздражителя и возникновением ответной реакции) и точность результатов при решении задачи, но, как ожидалось, это не связано с переключением языков (гипотеза 2).

Кроме того, в соответствии с нашей гипотезой 3, эффект от переключения языков проявился больше для доминантного языка (татарского), чем для второго (русского) языка.

Исследование расширило понимание когнитивных издержек билингвального обучения следующим образом. Во-первых, издержки от переключения языков проявляются не только у взрослых, но и у обычных учащихся средних школ, которые обучаются на двуязычной основе. Во-вторых, было имитировано реальное изучение некоторой темы в школе, которое длилось несколько дней, и после проводилось контрольное испытание вместо обучения и тестирования в течение одного дня, как это было в предыдущих исследованиях.

Наконец, издержки от переключения языков проявляются не только у “сбалансированных” билингвов, но и у “несбалансированных”, которые хуже владеют неродным языком и используют неродной язык только в ограниченных учебных контекстах. Этот эффект, однако, зависит от направления переключения языка обучения (гипотеза 3). Переключение от доминантного языка обучения ко второму языку приводит к большему увеличению времени выполнения заданий, чем когда переключение происходит в противоположном направлении. Соответственно, несбалансированные билингвы не полагались лишь на второй язык при кодировании информации во время обучения, но также использовали свой родной язык. Таким образом, переход на доминантный язык влечет

меньшие когнитивные издержки. Сбалансированные билингвы, наоборот, полагаются при кодировании информации исключительно на актуальный язык обучения.

В целом результаты показывают, что извлечение и представление знаний в процессе изучения того или иного предмета в школе связано с языком обучения, если язык контроля знаний и тестирования отличается от языка обучения, учащиеся и студенты могут иметь когнитивные издержки, которые проявляются в снижении точности и скорости обработки информации.

*Исследование выполнено при финансовой поддержке гранта РГНФ № 14-06-00325*

**Литература**

1. Салехова Л.Л., Зарипова Р.Р. К вопросу о взаимосвязи билингвального обучения и интеллектуального развития личности (по материалам зарубежной педагогической литературы) // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 1 (27). С. 246–250.

2. Салехова Л.Л., Каримова А.А. Развитие мышления на втором языке в процессе составления учащимися текстовых задач по математике // Филология и культура. Philology and Culture. 2011. № 2 (24). С. 275–280.

3. Туктамышов Н.К., Салехова Л.Л., Зарипова Р.Р. Определение уровня сформированности коммуникативных качеств математической речи у студентов, обучающихся на двуязычной основе // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 4 (34). С. 307–314.

4. Петрова А.И., Старостина Л.Д. Показатели мыслительной деятельности: сравнительное исследование в условиях билингвизма // Петрова Антонина Ивановна: биобиблиографический указатель / Министерство образования и науки, Сев.-Вост. федер. ун-т им. М.К. Аммосова. Якутск: Издательский дом СВФУ, 2014. С. 147–154.

5. Gentner D., & Goldin-Meadow S. Language in mind: Advances in the study of language and thought. Cambridge, MA: MIT Press, 2003. pp. 195–235.

6. Gumperz J.J., & Levinson S.C. Rethinking linguistic relativity. Cambridge: Cambridge University Press, 1996. pp. 21–36.

7. Malt B.C., & Wolff P. Words in the mind: How words capture human experience. New York: Oxford University Press, 2010. 362 p.

8. Gordon P. Numerical cognition without words: evidence from Amazonia. Science. 2004. № 306. pp. 496–498. DOI: 10.1126/science.1094492.

9. Miller K.F., Smith C.M., Zhu J., & Zhang, H. Preschool origins of cross-national differences in mathematical competence: the role of number naming system. Psychological Science. 1995. № 6. pp. 831–843.

10.Miller K.F., & Stigler J.W. Counting in Chinese: cultural variation in a basic cognitive skill. Cognitive Development, 1987. 236 p.

11.Spelke E.S., & Tsivkin S. Language and number: a bilingual training study. Cognition. 2001. № 78 (1). pp. 45–88.

12.Dehaene, S., & Cohen, L. Cerebral pathways for calculation: double dissociation between rote verbal and quantitative knowledge of arithmetic. Cortex. 1997. № 33 (2). pp. 219–250.

13.Marian V., & Fausey, C.M. Language dependent memory in bilingual learning. Cognitive Psychology Applied, 2006. 268 p.

## ABOUT COGNITIVE SIDE EFFECTS OF BILINGUAL (TATAR - RUSSIAN ) EDUCATION

***Salekhova Leila Leonardovna,***
*Doctor of pedagogical sciences,*
*Kazan (Volga region) Federal University,*
*salekhova2009@gmail.com*

Bilingual education implicitly assumed that the acquired knowledge is presented in a language-independent way. The present study aims to examine whether the cognitive side effects appear during bilingual mathematics learning. The results of pedagogical experiment which includes 39 students of bilingual (Tatar-Russian) schools in the Republic of Tatarstan show that if the language of knowledge assessment is different from the language of instruction, students may have the cognitive side effects which result in lower accuracy and information processing speed.

***Keywords:*** bilingual learning, cognitive side effects, language of instruction, language of retrieving knowledge, code switching.

УДК 37; 372.83; 37.02

# XX ГАСЫРНЫҢ 20–30 ЕЛЛАРЫНДА ТАТАРСТАНДА ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ТОРЫШЫ

***Садыйков Шамил Фәнис улы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*mergen777@mail.ru*

Мәкаләдә XX гасырның 20–30 елларында матбугат битләрендә басылган материаллар нигезендә татар телендә югары белем бирү мәсьәләләренә анализ ясала. Мәгарифкә, югары белем бирү системасына совет власте алып килгән үзгәрешләр һәм яңалыклар күрсәтелә.

***Төп төшенчәләр:*** югары белем бирү, татар теле, милли кадрлар.

XX гасырның 20–30 елларында Татарстанда дөнья күргән матбугат чараларында югары белемгә багышланган мәкаләләрнең күп булуы әлеге елларда бу мәсьләгә шактый зур игътибар бирелүе турында сөйли. 1923 елга кадәр татар матбугатында югары уку йортларын гали мәктәпләр дип атау күзәтелсә, соңрак аны югары мәктәпләр дип йөртә башлыйлар.

Берничә үсеш этабын узган татар милли белем бирү системасы XX гасыр башларына бер төзек система буларак төзелә. Әмма совет власте урнашу белән татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләре зур үзгәрешләр кичерә. Алар яңа хөкүмәтнең декретлары нигезендә эшли башлыйлар. Иң беренче карарларның берсе нигезендә дини һәм дөньяви белем бирүне бергә алып бару тыела. Шул вакыттан алып татар мәгариф системасы үзенең мөстәкыйль эшчәнлегеннән мәхрүм ителә, моңа кадәр нигездә шәхси кешеләрнең акчаларына яшәп килгән мәктәп тулаем дәүләт карамагына күчерелә.

1918 елда РСФСР Наркомпросының дәүләт комиссиясе барлык халыкларга (милләтләргә) ике баскычта һәм югары мәктәптә ана телендә укытуны оештыру мөмкинлеген тудыра [3: 120, 123].

Үзәк Башкарма комитеты һәм ТАССРның Халык комиссарларының «Татарстан җөмһүриятендә татар телен гамәлгә кую

турындагы» декреты нигезендә (1921 елның 25 июне) татар телен барлык хөкүмәт учреждениеләренә мәҗбүри рәвештә кертү, тиз арада татар теленә өйрәтү курсларын ачу карала. Татар теле рус теле белән беррәттән дәүләт теле дип игълан ителә. Бу үз чиратында ана телен барлык мәктәпләрдә, урта һөнәри-техник һәм югары уку йортларында рәсми рәвештә укыта башлау мөмкинлеге тууны аңлата иде.

Совет властенең беренче елларында югары белем бирү системасы бик авыр хәлдә кала. Гражданнар сугышы вакытында дәүләт икътисады шактый көчсезләнә (ярлылана) һәм барлык финанс көчләре илне саклап калуга юнәлтелә. Шунлыктан югары белем иң соңгы ихтыяҗларның берсенә әверелә. Шул ук вакытта патша Россиясеннән калган югары белем бирү системасын тамырдан үзгәртеп кору идеясе дә күтәрелә. Ләкин формаль рәвештә университетларны ябу куркынычы тормышка ашмый. Шул ук вакытта күп кенә яңалыклар (вузларга яңача кабул итү кагыйдәләре; юридик һәм тарих факультетларын ябу; студентларның һәм хезмәткәрләрнең вуз идарәсендә рольләренең артуы) югары белемнең сыйфатын шактый төшерә.

Югары белемнең сыйфаты төшү белән бергә аның матди яктан тәэмин ителеше дә кими. Вузларны яңа китаплар, җиһазлар белән тәэмин итү бетерелә. Укытучылар авыр хәлдә кала. Бары тик 1919 елның азагында гына профессорларга һәм доцентларга азык паеклары билгеләнә. Әлбәттә, әлеге авырлыклар һәм үзгәрешләр вуз укытучыларының совет властена каршы позициясен билгели.

НЭПка күчү (1920 ел ахырында) югары белемнең тәмам бетүен беркадәр туктатып кала. Финанс ягыннан иң авыр булган 1921–1922 еллардан соң югары белемгә күбрәк матди ярдәм күрсәтелә башлый. Әмма вузларның эчке тормышы революциягә кадәргә караганда күпкә начарлана. Университетларның автономиясе турында сүз дә булмый. Элеккеге профессорлар һәм коммунистлар тарафыннан билгеләп куелган кадрлар арасында каршылыклар арта. 1921 елның 19 сентябрендә кабул ителгән «Югары уку йортлары турында»гы положение әлеге каршылыкларны тагын да көчәйтә, нәтиҗәдә күп укытучылар илне ташлап китәргә (куылырга) мәҗбүр булалар. Шулай итеп, революция тарафыннан куелган ике төп максат – эшче-крестьяннар арасыннан зыялылар

сыйныфын булдыру һәм гали мәктәпне пролетариатка якынайту эше тормышка ашырыла башлый.

1923 елда «Мәгариф» журналында басылган «Гали мәктәпләр» дигән мәкаләсендә Ә. Гомәров гали мәктәпләрдә укучыларның 75%ының эшче-крестьян яшьләре булуын Октябрь революциясенең һәм пролетариат сыйныфының җиңүен билгеләүче төп факторлар буларак билгели. Авторның фикеренчә, әлеге гали мәктәпләр көндәлек тормышта социализм төзелеше алып барырлык аңлы эшчеләр җитештерергә тиеш.

Әхәт Гомәров гали мәктәпләрне пролетариат сыйныфы кулына алып бару юлында без нәрсә эшләдек дигән сорау куя һәм аңа түбәндәгечә җавап бирә:

1) «гали мәктәп укучыларын пролетариат һәм үз көче белән көн итүче крестьяннарга, иҗтимагый һәм сәяси җәһәтләрдән якын торган элементлардан җыюыбыз;

2) гали мәктәпнең идарә итү эшен яңадан төзүебез булды. Бу юлда безгә байтак каршылыкларга очрарга туры килде, ләкин үз фикеребезне үткәрер өчен тиешле чаралар һәм адымнар кыла белдек;

3) гали мәктәпләрнең уку-укыту планнарын һәм программаларын яңадан басып төзүебез булды. Аның нигезендә универсализм һәм күп фәнлелек бетерелә. Программаларның тарих кисемнәре кыскартылып бөтен укыту саф ихтисасый хәзерлек (специальная подготовка) бабына күченә». Авторның фикеренчә, гали мәктәпләрдәге укытуның мөндәриҗәсе (эчтәлеге) пролетариат сыйныфының максатларына җавап бирерлек иттереп куелырга тиеш [2].

Туган телдә югары белем бирү мәсьәләләренә Гаяз Максудов зур игътибар бирә. Үзенең 1921 елда «Мәгариф» журналында басылып чыккан «Ана телендә гали мәктәпләр» исемле мәкаләсендә автор югары белем бирү өлкәсендәге нечкәлекләр белән таныштыра һәм әлеге теманы дискуссия рәвешендә алып барырга тәкъдим итә. Мәкаләнең башында галим үзе һәм җәмәгатьчелек алдына аерым сөальләр (сораулар) куя. Алар түбәндәгеләр: «Ана телендә гали мәктәпләр ачуга ихтыяҗ бармы? Ихтыяҗ булганда да матди, мәгънәви яктан мөмкинлек бармы? Нindиләрне ачарга?»

Автор иң төп проблеманы икенче баскыч мәктәпләре өчен укытучылар әзерләүдә күрә һәм «әлеге мәктәпләргә укытучыларны кайдан көтәргә, гали мәгариф институтларыннанмы; яисә универ-

ситет факультетларыннанмы?» дигән сорауны куя һәм аларга җавап табарга тырыша.

Г. Максудов фикеренчә, «тормышка яраклы һәр төрле мәктәпләр булганда гына рухларны изүче, коллыкка тартучы тәэсирләрдән котылырга мөмкин. Ул төрле дәрәҗәдәге мәктәпләр тәртипле бер план белән эзлекле рәвештә дәвам итеп эшләргә, ана телендәге мәктәпләр һәр дәрәҗәдә урын алырга тиеш, дип саный. Ләкин була алу һәм бар арасында аерма зур. Дәрелфөнун (университет) ачу хыялларын без бер дә какмыйбыз». Галим фикеренчә, иң әүвәл ачарга тиешле гали мәктәпнең беренче чиратта икенче баскыч мәктәпләр өчен укытучы кадрлар хәзерләрлек гали мәктәп институты булуы зарури. Монда ул берничә сәбәп күрә:

1) «мондый гали институтыбыз булганда билгеле микъдарда укытучылар чыгаруны тәэмин иткән булабыз. Әлегә кайсы фәннәр өчен ни кадәр укытучыбыз булуы хакында хисап юк;

2) укытучы булу өчен ялгыз укытучылык фәне генә җитми, аларны балаларның белем ихтыяҗларын үти алырлык күпкырлы белгеч итеп әзерләү мөһим;

3) югары уку йортларына керүдә иң зур киртә булып тел мәсьәләсе тора. Татар мәктәбе турыдан-туры гали мәктәпләргә керә алырлык укучылар әзерли алмый. Ә әлеге гали институт аерым кешеләр өчен мөрәҗәгать итү урыны булыр».

Г. Максудов гали институтны киләчәк гали мәктәпләр өчен бер нигез ташы итеп күрә. Укыту теле татарча булып, мөмкин булмаган дәресләрдә хәзергә рус телен кулланырга тәкъдим итә. «Бу галине кечерәйтү дип әйтүчеләр булыр, ләкин алай әйткәндә, без үзебез галиләшергә тырышыйк!» – ди. Ул бары бер милләтнең, сыйныфның гына гали булып калуында риза түгел икәнлеген ассызыклый.

Шулай ук Г. Максудовның Шәрык академиясе турындагы фикере дә кызыклы. Әлеге академиянең кирәклегендә һич шикләнмичә, ул шул ук вакытта урта мәктәпләр өчен укытучылар әзерләү өчен институт ачуны беренче урындагы бурычларның берсе итеп күрә. Үзенең әлеге академиянең бер профессоры белән полемикага керүе турында әйтә. «Укытучылар кайдан чыксын?» – дигән сорауга профессор: «Менә шул академиядән», – дип җавап кайтара. Ләкин Г. Максудов фикеренчә, әгәр академия укытучы чыгара икән, ул академия булмый – институт була. Тарихтан

билгеле булганча, озакламый әлеге академия Көнчыгыш педагогия институты итеп үзгәртеп корыла (1922).

Автор түбәндәге сүзләре белән «балаларны рус мәктәпләренә бирмәсәк тә булыр» шикелле мәгънәсез бер нәтиҗә чыгармаска чакыра. «Рус мәктәпләре безнең өчен бик зур нигъмәт. Аннан файдаланырга кирәк. Моннан тыш укучыларны Аурупа мәктәпләренә җибәрергә тиешбез», – ди. Гомумән әйткәндә, автор мәсьәләне шулайрак күрә: «Ана телендә беренче һәм икенче баскыч мәктәпләребез бар. Моның табигый дәвамы – ана телендәге гали мәктәпләр. Ана телендәге гали мәктәпкә каршы килү ана телендә урта һәм ибтидаи мәктәпләрне инкарь итү дигән сүз. Әгәр ана телендә гали мәктәп төзү юлын тәкъдим итмибез икән, ана телендәге мәктәпләрне барысын да ябып, рус мәктәпләренә укучы хәзерләрлек шәкелдә мәктәп төзергә тиешбез» [8].

20 нче елларда Татарстан мәгариф халык комиссариатының иң алда торган вазыйфаларның берсе булып урта, һөнәри-техник һәм гали мәктәпләрдә эшче-крестьяннарның һәм татарларның саннарын арттыру тора. Рабфакларга һәм югары мәктәпләргә шәкертләр җыйганда кантон мәгариф бүлекләре бу турыда халык арасында өндәү тарату һәм шәкертләрне сайлау эшенә нык игътибар итәргә тиеш булалар. Моннан тыш, хакимиятне иң борчыган мәсьәләләрнең берсе булып советка каршы тартышып килгән гали мәктәп укытучылары һәм профессорлары тора. Шунлыктан 20 нче еллар башында матбугат битләрендә еш бирелә торган сорауларның берсе – «Ник татар яшьләренең укыйсылары килми?» дигән сорау. Нур Сәйфи фикеренчә, 1921 елда 4 югары уку йортында 70 ләп кенә татар укучысы белем ала. Бу хәлне ул хәзерлек төркемнәре булмауда күрә, чөнки татарлар рус телен белмәү аркасында турыдан-туры төп классларга керә алмыйлар. Моннан тыш, ул уку йортларының татар үзәкләреннән ерак урнашканлыгын һәм татар яшьләре арасында агитация булмавын ассызыклый. Әлеге ситуацияне уңай хәл итү өчен автор барлык югары уку йортларында рабфаклар үрнәгендә хәзерлек класслары ачу һәм укучыларның матди хәлләрен яхшырту мәсьәләсенә игътибарны арттырырга тәкъдим итә [11: 32–33]. Н. Мөхетдинов та студентлар арасында татарларның аз булуын һәм артта калуларын рус телен начар белүләре һәм матди яктан начар тәэмин ителүләре, еш кына параллель рәвештә эшләүләре белән аңлата [9: 8].

Югары уку йортларында укучы студентларның милли составларын бәяләүгә багышланган мәкаләләрдә шулай ук татарларның аз булуларына игътибар ителә. Шулай ук аларның башка милләт вәкилләре белән чагыштырганда, уку дәверендә еш кына төшеп калулары мәсьәләсе дә күтәрелә [4; 5; 7]. Бигрәк тә 1926 ел күрсәткечләре моңа ачык дәлил булып тора. Бу елда икенче баскыч һәм техникум бетереп килүче татарлар саны шактый кими. Бу иң беренче чиратта әлеге елдан барлык милләт вәкилләре өчен югару уку йортларына кабул итү таләпләре бертигез булу белән аңлатыла (рабфак тәмамлаучылардан тыш). М. Ляхов фикеренчә, вузларның татар яшьләрен җәлеп итүе сәясәтенә карамастан, югары уку йортларын тәмамлаучыларның саны бик аз һәм моның чыгу юлын ул милли урта мәктәпләргә игътибарны арттуруда күрә [7: 104]. Чыннан да, 20 елларда институтларда милли бүлекләрне ныгытуга ныклы адымнар ясыла. Бу мәсьәләгә Көнчыгыш педагогия институты да игътибарсыз калмый. Институт идарәсе милли кадрларны булдыру юлында түбәндәге чараларны күрүне планлаштыра:

1) икенче баскыч мәктәпләргә, техникумнарга, крестьян-яшьләр мәктәпләренә ана теле, әдәбият, җәмгыятьне өйрәнү дәресләре алып барырлык укытучылар әзерләү. Алар ана телен һәм әдәбиятны рус материаллары белән бергә бәйләп үтәргә, ә үз телендә әдәбият материаллары аз булуын истә тотып, татар әдәбияты дәресләрен җәмгыятне өйрәнү дәресләре белән бәйләп алып барырга тәкъдим итәләр;

2) барлык бүлекләрдә милли төркемнәр төзеп, иң элек гомуми фәннәрдән ана телендә эшне алып бару карала. Чөнки рус телен начар белүләре сәбәпле студентлар гомуми фәннәрдән бик нык артта калалар;

3) институт янында гыйльми эшләр өчен аспирантураларда яхшы өлгергән студентларны калдыру. Безнең җөмһүрият шартларында бу беренче һәм иң кирәкле шарт;

4) методика эшләрен көчәйтергә. Профессорлар һәм укытучыларны милли бүлекләрдә эшләүгә кызыксындыру;

5) татарлар һәм аерым милләтләр өчен махсус рабфак ачу. Практика өчен институт каршында тәҗрибә мәктәпләре булдыру;

6) педагогия институтында татар һәм азчылык милләтләрнең санын арттыру [9: 7–8].

Н. Никольский фикеренчә, әгәр милли өлкәләрнең һәм республикаларның милли бүлекләр тормышында актив катнашуы дәвам иттерелсә һәм үссә, киләчәктә аларның аерым мөстәкыйль Милли педагогия институтына әверелүе дә мөмкин [10: 66].

Казан вузлары арасында татарча укыту эшенә беренчеләрдән булып Политехник институт алына (1922 елда төзелеш фәннәре ике телдә укытыла башлый). Шулай ук анда керү имтиханнарын туган телдә тапшыру мөмкинлеге бирелә. 1931 елда Коммуналь институтның төзелеш факультетында 10 нчы (татар) төркеме ачыла. 30 еллар ахырына кадәр татар телендә шактый гына уку әсбаплары дөнья күрә, күп кенә фәннәр буенча терминнар булдырыла (М. Әлмөхәммәтов (сызма геометрия), И. Алексеев (Математика дәреслекләре), Г. Максудов (Туры сызыклы тригонометрия), С. Корбангалиев (Химия дәреслеге), Н. Максудов (Авыл хуҗалыгы машиналары) һ.б.).

20–30 елларда тел мәсьәләсенә, милли сәясәткә кагылышлы күп кенә карарлар кабул ителә. Бу, әлбәттә, әлеге мәсьәләнең дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителүе, каралуы һәм зур игътибар бирелүе турында сөйли. Моның ачык мисалы булып ОБКОМның 1930 елгы ноябрь пленумы тора. Анда югары уку йортларында һәм техникумнарда милли сәясәтне тормышка ашыру мәсьәләләрен көчәйтү мәсьәләсе карала. Әлеге документта татар студентларының һәм укытучыларның саны артуы турында әйтелә һәм шул ук вакытта кайбер кимчелекләргә дә игътибар юнәлтелә:

1) мөмкинлекләре булган вузларда татар студентларына лекцияләр рус телендә укытыла (күпчелек татар укытучылары рус телендә укыта);

2) студентлар өчен татар телендә дәреслекләр булмавы. Ана телендә рус уку әсбаплары кулланып укытуның методлары эшләнмәве;

3) барлык вузларда татар теленә җитәрлек сәгатьләр саны бирелмәве һәм уку өчен мөмкинлекләр тудырылмавы (кабинетлар, җиһазлар);

4) күп кенә вузларда ана теле һәм әдәбияты укытылмавы. Бу үз чиратында ана телендә үз милләтенең эшчеләр массасы ихтыяҗларын канәгатьләндерергә сәләтсез булып чыгуларына китерә.

Моннан чыгып Татобком барлык югары уку йортларында параллель рәвештә махсус татар төркемнәре оештырырга һәм,

хосусән, ТКУда, Көнчыгыш педагогия институтында, Совет хокукы һәм Совет төзелеше институтында татарлар өчен татар телендә укытуны кертүне һәм барлык фәннәр буенча коренизацияне 1933 елга тулысынча тәмамлануны тәкъдим итә. Шулай ук Татиздатка һәм терминология комиссиясенә билгеләнгән кимчелекләрне хәл итәргә йөкләнелә [6: 239–240].

Аерым бер кимчелек булып кайбер студентларның һәм фәнни хезмәткәрләрнең латин алфавитларын белмәве күрсәтелә. Мисал өчен, төзелеш институтында укучы студентларның өчтән бер өлешенең яңалифтә укый-яза белмәве хурлыклы хәл буларак ассызыклана [1: 88].

ТАССР хөкүмәте тарафыннан үткәрелгән әлеге чаралар үз нәтиҗәсен бирде. Татар кадрларын әзерләү мәсьәләсе аерым контрольдә тотыла. Ел саен барлык уку йортларының милли составы билгеләнеп һәм анализланып барыла. Кызганычка каршы, әлеге статистика 30 еллар ахырында бетерелә һәм хәзерге көндә дә алып барылмый. Югары уку йортларында татар телендә укытуны өлешчә кертү, әлбәттә, татарларның әлеге уку йортларын тәмамлау санына уңай тәэсир итә һәм аларның саны елдан-ел арта. Әмма 30 еллар ахырында башланган үзгәртеп корулар, массакүләм репрессияләр югары уку йортларында татарча белем бирүгә тискәре йогынты ясый, дәреслекләр чыгару туктатыла, күп педагоглар эшләреннән читләштерелә, коренизация процессы туктатылып, кире руслаштыру белән тәмамлана.

**Әдәбият**

1. Аеров В. Подготовка национальных кадров (в Татарии) // Социальное хозяйство Татарии. 1931. № 3–4. С. 86–88.

2. Гомәров Ә. Гали мәктәпләр // Мәгариф. 1923. № 7–8. 7–10 б.

3. Директивы ВКП (б) и постановления Советского правительства о народном образовании: Сборник документов за 1917–1948 гг. Вып. 1–2. М.; Л.: Изд. АПН РСФСР, 1947. 304 с.

4. Ермолаев В. Высшие учебные заведения // Труд и хозяйство. 1926. № 4. С. 85–92.

5. Җәләй Ш. Татарстанда югары һәм урта мәктәпләр вә андагы студентлар // Безнең юл. 1925. № 6. 237–240 б.

6. Корбут М., Федорович Н. Коренизация высших учебных заведений // Советское государство и революция права. 1931. № 10/12. С. 239–242.

7. Ляхов М. Казанское студенчество в национальном разрезе // Труд и хозяйство. 1928. № 7. С. 82–106.

8. Максудов Г. Ана телендә гали мәктәпләр // Мәгариф. 1921. № 1–2. 74–78 б.

9. Мөхетдинов Н. Көнчыгыш педагогия институтының милли бүлекләрен ныгыту турында // Мәгариф. 1926. № 8. 6–9 б.

10. Новый педагог. Организация работы Восточного педагогического института в Казани. Казань, 1927. 117 с.

11. Сайфи Н. Среди студентов-татар // Вестник просвещения. 1921. № 3. С. 31–36.

## THE HIGHER EDUCATION IN TATARSTAN IN 1920'S – 1930'S

***Sadykov Shamil' Fanisovich,***
*Candidate of pedagogical sciences,*
*Sh. Marjani Institute of History,*
*Tatarstan Academy of Sciences,*
*mergen777@mail.ru*

This article examines periodicals materials about the higher education in Tatar language during of the 1920's – 1930's. Author analyzed the innovations and changes in the field of the higher education during the early Soviet time.

***Keywords:*** higher education, Tatar language, Minority Ethnic Staff.

# III. АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ ПРЕПОДАВАНИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ОБРАЗОВАНИЯ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

# ТАТАРЧА БЕЛЕМ БИРҮ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

УДК 373.167.16811.5126145 (366)

## ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ НӘТИҖӘЛЕ ЧАРА

***Харисова Чулпан Мөхәррәм кызы,***
*педагогика фәннәре докторы,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*c.harisova@yandex.ru*

Мәкаләдә тел дәресләрендә төрле темаларны өйрәнгәндә, чагыштыру алымыннан файдалануның нәтиҗәле чара булуы турында сөйләнә. Автор тел белеменең төрле бүлекләрен (фонетика, сүз төзелешен һәм морфологияне) укытканда, әлеге алымны файдалануның өстенлекле яклары булуын мисаллар ярдәмендә исбатлый.

***Төп төшенчәләр*: чагыштыру, логика, уртаклык, аерма, методика, сурәт, троп, сүз төркеме.**

Чагыштыру чынбарлыктагы теге яки бу предметларның, төшенчәләрнең охшашлыгы яки аермасы турында фикер йөртүнең нигезен тәшкил итә. Ул төрле әйберләрнең микъдары һәм сыйфаты ягыннан аерыла торган яки охшаш булган билгеләрен ачыкларга булыша [1]. Шуның белән беррәттән, предмет яки төшенчәләрнең аерым билгеләре генә чагыштырыла ала. Мәсәлән, телебездә

чагыштыру дәрәҗәсе (предмет билгесен гадәти норма белән чагыштыру) барлык сыйфатларда да очрамый: предметларның үзенә хас булган билгесен белдерә торган асыл сыйфатларның шушы үзенчәлеге бар, ә инде урынга яки вакытка бәйле булган билгеләрне белдереп килгән нисби сыйфатлар чагыштыра алу үзлегеннән мәхрүм.

Чагыштыру – төрле фәннәргә карый торган төшенчә. Мәсәлән, логика фәнендә ул, гадәттә, фикерләү нәтиҗәсендә барлыкка килә дип аңлатыла, бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән нинди дә булса ике (яки берничә) төшенчәне чагыштырып, аларның уртак һәм аермалы якларын табу истә тотыла.

Чагыштыру – ул ике яки берничә төшенчә, күренеш һәм предметны чагыштырып, аларның охшаш яки аермалы билгеләрен табу дигән сүз (С.И. Ожегов, Н.Ю. Шведова). Тел белемендә чагыштыру дигән төшенчә беренче чиратта билге төшенчәсенең чагыштырмача төрле дәрәҗәдә килүен күрсәтә һәм аерым сүз төркемнәренең (сыйфатларның, рәвешләрнең һ.б.) дәрәҗә формаларында килүендә чагылыш таба (Д.Э. Розенталь, М.А. Теленкова).

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә чагыштыруларга хас булган түбәндәге билгеләр санала:

1. Күренешләрнең, предметларның һ.б. охшашлыкларын яки аермаларын, яисә берсенең икенчесеннән өстенлеген билгеләү, ачыклау өчен тикшерү.

2. Кем яки нәрсә белән булса да тиңләү, кемгә яки нәрсәгә булса да охшату.

3. Бер предметны икенче предметка охшатуны эченә алган фраза, тәгъбир, тезмә [2: 645].

Әдәбият белемендә чагыштыру сурәт ясау өчен сүзләрне күчерелмә мәгънәдә файдалануның, ягъни тропларның иң гади һәм киң таралган төрләреннән берсе, нинди дә булса күренешне аңа охшаш үзенчәлеге булган икенче күренеш белән чагыштыру дип карала (А.Г. Әхмәдуллин).

Тел укыту методикасында да чагыштыру фикерләүгә бәйле рәвештә искә алына, предмет һәм күренешләрнең үзенчәлекләрендәге охшаш һәм аермалы якларны чагыштырып табу юлларын билгели. Бөек педагог К.Д. Ушинский укучының танып-белү эшчәнлеге тулысынча диярлек элек белгәннәр белән яңаны чагыштыруга таяна дип саный һәм икенче бер телне өйрәнгәндә, аны

укучының туган теле белән чагыштыру уңай нәтиҗәләргә китерә дип ассызыклый. Лингвометодистлар Л.З. Шакирова [3], Ф.Ф. Харисов [4] һ.б. икенче телне өйрәнүдә чагыштырма грамматиканың әһәмияте зур булуын даими рәвештә күрсәтеп киләләр. Монда, билгеле, психологик үзенчәлек тә зур роль уйный. Тәҗрибә шуны күрсәтә: укучы икенче (өченче) телнең кайсы гына ярусын (фонетика, лексикология, грамматика) өйрәнсә дә, башта аларны үзенең туган теле белән чагыштырып карый, иң элек аермалы якларына игътибар итә, ә охшаш билгеләрен тотып алу кыенрак була. Дәрестә төрле темаларны үткәндә, аларны чагыштыруга укытучы тарафыннан тиешле игътибар бирелсә, эшнең нәтиҗәсе дә шактый югары була, яңа материал балалар хәтерендә озаграк саклана, аның гамәли яктан кулланылышы да активрак була.

Югарыда әйтелгән фикерләрне раслау өчен, түбәндәге мисаллар ярдәмендә фонетика, сүз төзелеше һәм морфология буенча кайбер темаларны чагыштырып өйрәнү үрнәкләрен китерәбез. Күренә ки: чагыштыру аерым сүз төркеме эчендә яки төрле сүз төркемнәре арасында булырга мөмкин.

Фонетика буенча өйрәнелә торган темалар арасында сузык авазлар турындагы материал телебездә аларның сингармонизм законы нигезендә икегә бүленүен, шуңа бәйле рәвештә сүз ясалышында да, сүз төркемнәренең формалары үзгәргәндә дә кушымчаларның төрле-төрле булуын күрсәтә. Сузыкларның икегә – алгы һәм арткы рәтләргә бүленүе дә телнең горизонталь хәрәкәтенә бәйле. Орфоэпик яктан аларны чагыштырып әйтеп карау, бу вакытта телнең хәрәкәтен күзәтү отышлы эш алымнарыннан берсе санала [5].

Билгеле булганча, рус мәктәпләрендә укучы татар балалары гамәлдәге татар теле программасы буенча V сыйныфта сүз төзелешенә караган темалардан тамыр һәм нигез турында мәгълүмат алалар. Сүзнең тамыры белән нигезе турындагы кагыйдәләр, беренче карашка бик охшаш кебек: икесенә дә лексик мәгънәне белдерү яки аны саклау хас, сөйләмдә алар аерым да кулланыла ала, кайсы да булса сүз төркеменә керә ала торган кисәкләр [6]. Әмма аерым сүзләр мисалында чагыштыру алар арасындагы үзенчәлекне дә ачык күрсәтә: сүзнең тамыры белән нигезе ясалма булмаган сүзләрдә бер-берсенә туры килә *(мәктәпне, мәктәпкә),*

тәңгәл була; ясалма нигезле сүздә исә ясагыч кушымча була (тамыр+ясагыч кушымча: *күңелле*).

Икенче бер мисал. VI сыйныфта асыл һәм нисби сыйфатлар өйрәнелә. Бу – укучылар өчен яңарак тема һәм аны тиешенчә үзләштерү әлеге төркемчәләрне чагыштырып аңлатуга бәйле. Монда укытучы балаларның игътибарын әлеге төркемчәләрнең түбәндәге аермалы билгеләргә юнәлтә.

Асыл сыйфатлар предметның саф яки үзенә хас булган билгесен: *түгәрәк* (күл), ә нисби сыйфатлар бер предметның башка предметка мөнәсәбәтеннән (нисбәтеннән) килеп чыккан билгене *өстәлдәге* (китап) белдерә.

Дәрәҗә формалары асыл сыйфатларда гына була: *кызылрак, кып-кызыл, кызгылт.*

Исемләшү дә асыл сыйфатларның күбесендә очрый: *Белемле* меңне егар (мәкаль). Гадәттә, нисби сыйфатларның *-да+гы, -дә+ге; -та+гы, -тә+ге* кушымчалары белән ясалганнары исемләшә: *Басудагылар* бүген иртә кайтты (Г. Бәширов).

Җөмләдә үтәгән функцияләре буенча карасак та, асыл сыйфатлар күп төрле җөмлә кисәкләре булып килpoints: аергыч (*Зәңгәр* күктән кар сибелә. Г. Ибраһимов.), хәл (Татарча да *яхшы* бел. Ш. Маннур), хәбәр булып килә (Көн *болытлы* иде).

Нисби сыйфатлар, гадәттә, аергыч (Безгә *өлгергәнлек* аттестаты тапшырдылар), ә кайберләре сирәк кенә хәбәр булып килергә мөмкин (Тәрәзә *ачык*).

Соңгы елларда аваз ияртемнәре дә мөстәкыйль сүз төркемнәре буларак өйрәнелә башлады. Моның объектив сәбәпләре бар һәм алар, әлеге сүз төркемнәрен чагыштырганда, тагын да ачыграк күренә.

Билгеле булганча, мөстәкыйль сүз төркемнәре чынбарлыкта безнең аңыбыздан башка яши торган күренеш һәм төшенчәләрне (предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтне һәм аның билгесен яки билгенең билгесен һ.б.) белдерә. Аваз ияртемнәренең дә лексик эчтәлекләре бар. Бу сүзләр ярдәмендә аларны барлыкка китергән предмет яки төшенчә күзаллана ала: *шалтыр-шолтыр* (буш чиләк яки савыт), *җилфер-җилфер* (юка тукыманың җилдә җилфердәгән тавышы), *зыр-зыр* (нәзек озынча предмет әйләнгән тавыш, мәсәлән, орчык) һ.б [7: 101].

Татар телендә мөстәкыйль сүз төркемнәреннән сыйфатлар, саннар һәм рәвешләр, кайбер алмашлыклар төрләнмиләр. Болар арасына аваз ияртемнәрен дә кертеп карарга кирәк, телебездә алар да төрләнми.

Синтаксик яктан караганда, бу сүз төркемнәре барысы да төрле җөмлә кисәкләре булып килә. Без монда аваз ияртемнәренең аергыч (*Кыйгак* казлар безнең якларга кайтты), хәл (Малай *тыз-быз* йөренә), хәбәр (Балалар урамда *гөж* килә) булып килүенә мисаллар белән чикләнәбез.

Сүз ясалышы системасында тоткан урыны буенча караганда, башка мөстәкыйль сүз төркемнәре кебек аваз ияртемнәреннән дә исемнәр (*гөрләвек, карга, бытбылдык, шау-шу, чатыр-чотыр*), фигыльләр (*шапылдау, дөбердәү, ду килү, гөж итү)* ясала.

VI сыйныфта сыйфат фигыльләрне өйрәнгәндә, укучылар инде хикәя фигыльләрне үткән булалар. Еш кына балалар әлеге ике фигыльне ялгыштыралар, чөнки һәр икесенең заманнары бар, үткән һәм киләчәк заман формалары бер-берсенә охшаш та. Бу вакытта укытучыга (укучыларга да) ул фигыльләрне чагыштырып аңлату ярдәмгә килә.

Әйтик, балаларга «Кеше *килгән*» җөмләсе белән *«килгән* кеше» сүзтезмәсе тәкъдим ителә. Тел белемендә сүзләрне төркемләүнең өч принцибын истә тотып фикер йөртсәк, мәгънәсе буенча беренче очракта хикәя фигыль зат яки предмет үтәгән эшне белдерә, ә икенче очракта сыйфат фигыль затның эшен аның билгесе итеп белдерә; морфологик яктан хикәя фигыль затланышлы, III зат берлек санда, билгесез үткән заманда, сыйфат фигыль – затланышсыз һәм үткән заман формасында килгән; синтаксик яктан караганда, хикәя фигыль җөмләдә хәбәр, ә сыйфат фигыль, исемне ачыклап, аергыч вазыйфасын үти.

Башка затланышсыз фигыльләрдән хәл фигыльләрне һәм исем фигыльләрне аңлап үзләштерү өчен, аларның атамаларына игътибар итәргә кирәк. Ни өчен хәл фигыль рәвеш фигыль дип тә атала? Анда рәвешләргә хас булган нинди билгеләр бар? Ни өчен исем фигыль затланышсыз булса да килеш һәм тартым белән төрләнә? Әлеге һәм башка бик күп сорауларга җавап биргәндә дә, укытучыга чагыштыру алымы ярдәмгә килә.

Гамәлдәге программа буенча бәйлек белән теркәгечләр уку елы ахырында өйрәнелә. Фәнни әдәбиятта алар бәйләгеч сүз

төркемнәре дип йөртелә, чөнки аларның төп вазыйфасы – сүзләрне һәм җөмләләрне бер-берсенә бәйләү. Бу ике сүз төркемен чагыштырып карау да укучыларга аларны тиешенчә үзләштерергә ярдәм итә, киләчәктә өйрәнәсе синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрне аңлап, сөйләмдә дөрес кулланырга булыша.

Бәйлекләр белән теркәгечләр арасындагы уртак билгеләр: икесе дә сүзләр (мәктәпкә *таба* бару), (Укучы дәрестә укый *һәм* яза) һәм җөмләләр арасында (Кояш чыгу *белән* көн җылынды. Көн җылынды, *чөнки* кояш чыкты) ияртүле бәйләнеш барлыкка китерә; һәр ике сүз төркеменең ярдәмче сүзләре (бәйлек сүзләр, теркәгеч сүзләр) бар.

Аермаларыннан түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин:

1. Бәйлекләр сүзләр һәм җөмләләр арасында ияртүле бәйләнеш (көрәк *белән* казу; Көн җылынганнан *соң*, без экскурсиягә киттек), теркәгечләр исә тезүле (Балалар су коена *һәм* җиләк җыя. Көз җитте *һәм* кошлар җылы якларга китте) һәм ияртүле (*Әгәр* тырышып укысаң, акыллы кеше булачаксың) бәйләнеш булдыралар.

2. Бәйлекләр җөмлә кисәге составында киләләр (Балалар елгага *хәтле* йөгерде) – монда бәйлек урын хәлен формалаштыра, ә теркәгечләр, гадәттә, җөмлә кисәге булмыйлар.

3. Сөйләмдә бәйлекләрне төшереп калдырырга ярамый. Алар үзләре бәйли торган сүзләр һәм җөмләләр белән бик тыгыз бәйләнгән була. Теркәгечләр исә җөмләдә еш кына кулланылмаска да мөмкин. Бу вакытта сөйләмдә аларны интонация, ә язуда төрле тыныш билгеләре – өтер яки сызык алыштыра (*Без килдек – ярыш башланмады*).

Шулай итеп, тәҗрибә күрсәткәнчә, тел дәресләрендә аерым темаларны чагыштырып өйрәтү укытучының эшен нәтиҗәле итеп оештырырга булыша: укучыларга аларны ачыграк итеп күзалларга ярдәм итә, әлеге темаларны аңлап, яхшырак итеп үзләштерергә җирлек тудыра.

**Әдәбият**

1. Новоселов М.М. О некоторых понятиях теории отношений // Кибернетика и современное научное познание. М.: Наука, 1976.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2005. 645 б.

3. Шакирова Л.З. Основы методики преподавания русского языка в татарской школе. Казань: Магариф, 1999. 351 с.

4. Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному [Текст] / Под ред. проф. Л.З.Шакировой. СПб.: филиал изд-ва «Просвещение», 2001. 431 с.

5. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Минимизация произносительного материала – основа формирования устойчивых знаний и навыков учащихся // Вестник Казанского государственного университета культуры. 2013. № 3. С. 122–126.

6. Харисова Ч.М., Харисов Ф.Ф. Особенности морфемного строя слов в татарском языке: лингводидактический аспект // Филология и культура. 2013. № 2. С. 310–313.

7. Харисова Ч.М. Татар теле. Морфология. Казан: Мәгариф, 2010. 128 б.

## EFFECTIVE METHODS ON LANGUAGE LESSONS

***Kharisova Chulpan Mukharramovna,***
*Doctor of pedagogical sciences,*
*Kazan (Volga region) Federal University,*
*c.harisova@yandex.ru*

Comparative method is the most effective way in teaching languages. Author gives many examples of using this method in teaching of phonetics, words structure and morphology of Tatar language.

***Keywords:*** teaching languages, comparative method, trope, parts of speech, phonetic, words structure, morphology.

УДК 811.512.145'27

# УЧЕБНИКИ ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ ДЛЯ РУССКОЯЗЫЧНЫХ УЧАЩИХСЯ КАК СРЕДСТВО ФОРМИРОВАНИЯ БИЛИНГВАЛЬНОЙ ЛИЧНОСТИ

***Исхакова Зайтуна Асхатовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы*
*и искусства им. Г.Ибрагимова АН РТ,*
*iyali.anrt@mail.ru*

Статья посвящена анализу учебников по татарскому языку для русскоязычных учащихся и их роли в формировании билингвальной личности.

***Ключевые слова:*** учебник, татарский язык, билингвальная личность, русскоязычные учащиеся.

Главная цель обучения татарскому языку – научить учащихся говорить, использовать язык в повседневной жизни. Говорение подразумевает как умение выражать свои мысли, так и способность воспринимать чужие. Поэтому при обучении русскоязычных учащихся татарскому языку подразумевается формирование билингвальной личности.

Но насколько это удается, и с какими проблемами сталкиваются наши учителя татарского языка?

Например, в ходе исследования вопросов преподавания и изучения татарского языка в системе среднего образования Республики Татарстан [10] были выявлены как степень владения татарским языком русскоязычных учащихся школ, так и «трудности», которые вынуждены решать наши преподаватели.

Что касается степени владения татарским языком учащимися, то самооценка совершенного владения языком у учащихся оказалась выше, чем в представлениях их преподавателей [4: 81]. Если, скажем, 10,9 % учащихся русской национальности указали на

свободное владение татарским языком (говорю, читаю, пишу), то, по мнению учителей, только 1,6 % учащихся умеют в совершенстве читать, писать и говорить по-татарски. Но вместе с тем учителя отметили, что по окончании школы 41,5 % детей умеют неплохо писать, читать и говорить по-татарски, а еще 9,6 % детей, хотя не умеют читать и писать, однако владеют устной формой, то есть умеют говорить. Таким образом, одностороннее двуязычие благодаря юному поколению стало обретать реальные черты.

Но, как было отмечено выше, в деле преподавания и обучения русскоязычных учащихся татарскому языку существуют определенные «трудности».

В число «трудностей» вошли:

– неразработанность программ;

– отсутствие интереса со стороны детей;

– отсутствие понимания со стороны родителей;

– отношение со стороны других предметников;

– непомерно высокие требования к преподавателям татарского языка, постоянные проверки;

– отсутствие хороших учебников (учебно-методических комплектов);

– отсутствие личного опыта и знаний.

Большая часть учителей (73 %) указали на отсутствие хороших учебников и неразработанность программ (51 %).

В связи с этим возникает вопрос: «Каким же должен быть учебник татарского языка и литературы?»

Д.М. Мустафин (первый заместитель министра образования и науки РТ в 2004–2014 гг.) считает, «главное требование – учебный материал должен соответствовать государственному образовательному стандарту» [1: 10–11]. Но как показало исследование, соответствие государственному образовательному стандарту не решает всех проблем.

Следует отметить, что отношение к процессу, к методике преподавания татарского языка русскоязычным учащимся неоднозначное. Одни считают, что татарский язык для русскоязычных учеников является иностранным и преподавать его необходимо как иностранный. Например, автор многочисленных трудов по языкознанию, учебников, пособий Ф.С. Сафиуллина пишет, что

татарский язык в русской школе изучается не как родной язык, а как незнакомый ребенку иностранный язык [11: 306].

Другой известный автор учебников и пособий по татарскому языку И.Л. Литвинов в своей статье «Рус телле укучылар өчен татар теле дәреслеге: ул нинди булырга тиеш?» («Учебник по татарскому языку для русскоязычных учащихся: каким он должен быть?») [6: 93] отмечает, что, как правило, эти учебники с лингвистической стороны написаны хорошо. Но с точки зрения методики многие из них не соответствуют современным представлениям методики преподавания иностранных языков. Они больше напоминают учебники по родному языку, нежели учебники по обучению иностранным языкам. Его идеи нашли поддержку и у других преподавателей. Например, Р.Ф. Низамиева в своей статье «Текстлар аһәңле булсын» («Тексты должны быть благозвучными») [9: 92] пишет, что современные учебники не способствуют развитию и пониманию татарской речи, умению вести беседы, общаться на бытовые темы и т.д.

Но среди методистов есть и другое мнение о методике преподавания татарского языка русскоязычным учащимся. Например, по мнению Р. Нигматуллиной, преподавание татарского языка русскоязычным учащимся по-новому в корне отличается от преподавания иностранных языков, так как навыки говорения, общения на татарском языке ребенок приобретает в реальной языковой обстановке [8: 24]. Как видим, относительно методики преподавания татарского языка русскоязычным учащимся нет единого мнения.

Несмотря на то, что материалы исследования свидетельствуют о необходимости создания более совершенных учебников, но оказывается, что до сих пор обозначенные выше недостатки, высказанные преподавателями татарского языка в ходе исследования, так и не были устранены. Например, Эльза Набиуллина в своей статье «Дәреслек – яңа, эчтәлек – иске» («Учебник – новый, содержание старое») [7: 22] пишет, что разница между прежними и сегодняшними учебниками заключается разве что в рисунках, которые даны на обложке. Они несколько более современные, поярче, да и бумага, кажется, более добротная. Но содержание прежнее. Каждые пять лет учебники переиздаются, однако, как отмечает

автор, в них нет особых изменений: те же упражнения, рисунки, тот же изучаемый материал, структура учебника – все по-старому.

В качестве примера автор приводит учебники по-английскому языку, изданные за рубежом. Она отмечает, что их также постоянно обновляют, но в них много дополнений, изменений, оформление книги – фото, рисунки, тексты – все претерпевает изменения. Например, в новых учебниках по английскому языку пишут о более современных певцах, актерах. Если в учебниках, изданных в 2008 году, были размещены рисунки сотовых телефонов старого образца, то в новых книгах в руках у молодежи видим смартфоны, у них и внешний вид, и одежда более современные. Если речь идет о профессиях, то это не только повар, продавец и строитель, а спелеолог, кинорежиссер, программист и представители других профессий.

Э. Набиуллина в своей статье обратила внимание и на то, что составители учебников по татарскому языку часто не учитывают возрастные особенности учащихся; написаны они сложным языком, объем материала завышенный, нет логической связи между темами и т.д.

Таким образом, автор статьи перечислила те же замечания, что были выявлены в ходе исследования, проведенного по проекту «Государственные языки в школьном образовании Республики Татарстан». К сожалению, Э. Набиуллина не указала авторов учебников по татарскому языку, а это позволило бы говорить о них более предметно.

Материалы исследования свидетельствуют о том, что учебно-методическая база преподавания татарского языка не выдерживает сравнения с методиками других языковых предметов [5: 107], например, с английским языком.

Неоднозначная оценка учебно-методической базы татарского и иностранных языков нашла отражение на страницах республиканской печати. Например, директор школы № 165 Ново-Савиновского района г. Казани Айдар Шамсетдинов в интервью газете «Мәгърифәт» откровенно говорит о том, что он, будучи специалистом по английскому языку, жалеет преподавателей татарского языка и литературы, так как у них нет таких пособий и учебников, которые бы способствовали достижению положительных результатов. А используя только имеющиеся книги,

невозможно добиться успеха и пробудить интерес к изучению языка [2].

А. Хакимова, учительница татарского языка школы № 165, придерживается того же мнения и говорит о том, что учителя татарского языка и литературы хотели бы, чтобы учебники были не хуже учебников по английскому и немецкому языкам [2].

В то же время Ф. Вафин, преподаватель татарского языка высшей категории школы-интерната Арского района Республики Татарстан в своей статье «Без әйтмәсәк, кем әйтер...» («Если мы не скажем, то кто скажет…») пишет, что он просмотрел и изучил учебники по английскому языку и сделал для себя вывод, что в них нет ничего нового и удивительного. Поэтому, считает он, дело не в учебнике и не в учителе. Главная причина – отсутствие потребности изучать язык (татарский) [3].

В отношении учебников по татарскому языку существуют разные мнения [5: 104–124], возможно, в них присутствует и доля субъективизма. Но следует подчеркнуть, что преподаватели не назвали ни одного учебника по татарскому языку, который бы их полностью устраивал по всем параметрам.

Например, положительно оценивая учебники Р.З. Хайдаровой и И.Л. Литвинова, преподаватели хотели бы видеть в них больше материала, способствующего развитию умений и навыков говорения у учащихся.

В формировании и воспитании билингвальной личности большую роль играет семья, родители.

По данным нашего исследования, большая часть родителей хотели бы видеть своих детей, владеющими обоими государственными языками РТ. Например, 23,8 % родителей русской национальности хотели бы видеть своих детей, владеющими татарским языком, и еще 43,8 % ответили, что хотели бы, чтобы их ребенок в какой-то мере владел татарским языком. Это позволяет предположить, что около 70,0 % русских семей Татарстана дают положительную установку на изучение татарского языка.

Родители в данном случае выступают заинтересованной стороной. Их желание видеть своего ребенка, владеющим тем или иным языком, понимание и поддержка являются важным стимулом для учащихся, так как именно в семье чаще всего дается установка на изучение того или иного языка.

Однако и родители высказали недовольство в адрес учебников по татарскому языку. Главную проблему родители видят в том, что в учебниках недостаточно уделяется внимание развитию разговорного языка.

Но следует напомнить, что даже самый совершенный учебник не научит говорить и, как пишет И.Л. Литвинов, он (учебник) «способен создать только базу для свободного говорения».

Введение обязательного преподавания татарского языка в русскоязычных школах произвело определенные изменения в знании языка титульного этноса республики, и имеющиеся зачатки пассивного двуязычия стали приобретать масштабное явление. Общий процент свободно говорящих, читающих и пишущих на татарском языке, а также в той или иной степени знающих этот язык, среди старшеклассников русской национальности сегодня ощутимо больше, нежели среди их родителей. Поэтому хочется верить, что при создании соответствующих условий (в том числе и более качественной учебно-методической базы) будет достигнут желаемый уровень знаний обоих государственных языков республики.

**Литература**

1. Әхмәтҗанова С. Боз кузгалырга тора... // Мәгариф. 2005. № 6. 10–11 б.

2. Бәдретдинов Х. Канәгатьсезлек хисе сагалый // Мәгърифәт. 2009. 7 февраль.

3. Вафин Ф. Без әйтмәсәк, кем әйтер... // Мәгърифәт. 2009. 28 февраль.

4. Габдрахманова Г.Ф. Учительский корпус и учебно-методический комплекс по татарскому языку и литературе для средней школы: оценки участников образовательного процесса // Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования / [Р.Н. Мусина и др.]. Казань: Татар.кн.из-во, 2011. С. 81.

5. Исхакова З.А. Современный учебник татарского языка: состояние, проблемы, перспективы // Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования / [Р.Н. Мусина и др.]. Казань: Татар.кн.изд-во, 2011. С. 107.

6. Литвинов И.Л. Рус телле укучылар өчен татар теле дәреслеге: ул нинди булырга тиеш? // Мәгариф. 1998. № 4. 93 б.

7. Нәбиуллина Э. Дәреслек – яңа, эчтәлек – иске // Мәгариф. 2014. № 10. 22 б.

8. Нигъмәтуллина Р. Сынап карау: татар телен яңача укыту // Мәгариф. 2006. № 11. 24 б.

9. Низамиева Р. Текстлар аһәңле булсын // Мәгариф. 1998. № 9. 92 б.

10.Проект «Государственные языки в школьном образовании Республики Татарстан» (рук. Р.Н. Мусина) // Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования / [Р.Н. Мусина и др.]. Казань: Татар.кн.изд-во, 2011. 158 с.

11.Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан, 2011. 306 б.

## TATAR LANGUAGE TEXTBOOKS FOR RUSSIAN-SPEAKING PUPILS, AS MEANS OF FORMATION OF THE BILINGUAL PERSONALITY

***Iskhakova Zaytuna Askhatovna,***
*Candidate of Philology,*
*G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,*
*Tatarstan Academy of Sciences,*
*iyali.anrt@mail.ru*

This article is examined the Tatar language textbooks for Russian-speaking pupils and their impact in formation of the bilingual personality.

***Keywords:*** textbooks, Tatar language, bilingual personality, teaching language to non-native speakers.

УДК 372. 8

# СӨЙЛӘМ КАЛЫБЫ УЛ –
# СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮНЕҢ НИГЕЗЕ

***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*Nikolaj.Maksimov@kpfu.ru*

Мәкаләдә татар телен белмәүчеләргә телне өйрәтү технологиясе карала. Синтаксик нигездә укытуның нәтиҗәлелеге раслана. Чит телгә өйрәтүнең нигезе итеп сөйләмнең синтагматик моделен алу телне өйрәнүченең игътибарын сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү алгогритмына юнәлдерергә мөмкинлек бирә. Алгоритмнарга таяну текст – диалог төзү процессында тотрыклы синтаксик конструкцияләрдән (сөйләм калыпларыннан) файдалану мөмкинлеген тудыра.

***Төп төшенчәләр:*** сүзтезмә, җөмлә, сөйләм моделе, монолог, диалог.

Ана телен белмәгән татар яки рус баласына татар телен өйрәтүдә тупланган эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: баланы ана телендә яки чит телдә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү процессы сөйләм калыпларын үзләштерүгә нигезләнеп оештырылганда гына көтелгән нәтиҗәләргә ирешеп була. Телгә өйрәтү ул – технологик процесс: телгә өйрәтүдә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүне күз алдында тотып, өч этапта эзлекле оештырылган эш тәртибе.

Әдәби сөйләм теленә өйрәтүне мәктәп укучысына кайсы да булса бер телнең (безнең очракта, татар теленең) сүз байлыгын, фонетикасын, орфоэпиясен, орфографиясен, морфологиясен һәм синтаксисын класстан класска эзлекле рәвештә кагыйдәләрне өйрәтү белән бутарга ярамый.

Сөйләм теле – теләсә кайсы телдә – сөйләм калыпларына нигезләнеп өйрәтелергә тиеш. Сөйләм калыбы, телдә булган барлык кагыйдәләргә нигезләнеп, дөрес әдәби сөйләм нормаларын өйрәтү өчен төзелә. Мәсәлән, рус баласын татар теленә өйрүтү барышында, без, нигездә, 30 сөйләм калыбын кулланабыз.

Сөйләм калыбы барлык халыкларда да, гадәттә, ата-бабадан элеккедән килгән сөйләм кагыйдәләренә таянып, билгеле бер тема (темалар) буенча кара-каршы сөйләшү өчен, диалог формасына яраклаштырып төзелә.

**Сөйләүче (мин)** – сөйләшүне оештыручы, сөйләшүдә башлап сүз әйтүче, сөйләшүнең нәтиҗәсе өчен җавап бирүче үзен тыңлаучыга яки тыңлаучыларына, күпчелекнең игътибарын җәлеп итәрлек сөйләшү темасын формалаштырып, башкарылган эшнең яки хәлнең үтәлү урыны, вакыты, сәбәбе, максаты, шарты, рәвеше, күләме турында хәбәр итеп, ***башлангыч текстны*** үзе теләгәнчә һәм үзе уйлаганча тәкъдим итә.

Аралашу, сөйләм, гадәттә, эндәш һәм кереш сүзләрдән, ымлыклардан башлана. Сөйләшү барышында, сөйләүче кеше һәрвакыт кайсы да булса затка нәрсә дә булса сорап яки хәбәр итеп, яки эш кушып мөрәҗәгать итә – эндәшә. Һәр телдә, шул исәптән, татар телендә дә, таныш яки таныш булмаган кешегә олыларны – олылап, яшьләрне һәм балаларны тиң күреп, матур итеп мөрәҗәгать итү өчен, әдәпне белдерүче сүзләр бар: *бабай, әби, әти, әни, абый, абзый, апа, сеңелем, егет, энем*; *якташ, авылдаш, классташ, дустым, кадерлем, күрше* һ.б.ш.

Эндәш сүз, нигездә, 2 нче затка – **син** яки **сез** зат алмашлыгына бәйләнештә кулланыла. Исемен әйтеп эндәшсәләр, эш кушсалар, кемгә дә ошый. Исемнәрне әйтеп аралашканда, сөйләшү, гадәттә, тыныч уза, уңай нәтиҗәле була.

Сөйләүче, максатына ирешү, әйтәсе фикерен төгәлрәк чагылдыру, сөйләменең ышандыру көчен тагын да арттыру өчен, калыпта синонимга әйләнерлек сүзләрне – азрак, антонимга әйләнерлек сүзләрне ешрак куллана; сөйләменең эмоциональ яңгырашын, аһәңен баету, тәэсир көчен үстерү өчен, риторик сорау, риторик мөрәҗәгать, риторик өндәү эчтәлеген бирүче тойгылы җөмләләрдән файдалана ала.

Танышу ул – бер-береңнән сорашып, үзара сөйләшеп, кемнең исеме ничек икәнлеген, кемнең кайчан туганлыгын, кемгә ничә яшь булуын һәм башкаларны үзара белешү, икенче төрле әйткәндә, үзеңне кызыксындырган берәр нәрсә турында чит кешедән кирәкле мәгълүмат алу юлы.

Сөйләшү, гадәттә, танышудан башлана. Танышырга теләгән кеше, кагыйдә буларак һәм сөйләм этикеты таләп иткәнчә, башта

үзе белән таныштыра – исемен әйтә, аннан соң әңгәмәдәшенең исемен сорый, шулай танышалар. Мисал өчен:

– *Минем исемем Марат. Әйт әле, синең исемең ничек*?

Таныш булмаган кешегә «***син***» дип эндәшергә ярыймы? Әгәр ул сүзнең алдында, яратып һәм якын итеп, *бабай, әби, абый, апа, дустым* кебек – эндәш яки *гафу ит, әйт әле* кебек кереш сүзләрне куллансаң, **син** дип эндәшү дә ярый. Болай эндәшү сөйләм этикетын бозмый. Бу очракта, хикмәт кайсы сүзне әйтүдә түгел, сүзне әйтә белүдә.

Сөйләшү ул – сөйләүче (1 нче зат) тарафыннан алдан уйланылып, билгеле бер максатка (максатларга) корылган яшерен уйлар, шул максатка бару юлында башкарылган үзенчәлекле уен төре. Сөйләшә башлау белән, кулланган сүзләренә һәм ике якка да ошарлык уңай эмоциональ халәт тудыра алу мөмкинлегенә карап, кемнең кем икәнен – акыл дәрәҗәсен, рухи мөмкинлекләрен (Кто есть кто?!) аңларга мөмкин. Сөйләмдә катнашучы зат (2 нче зат) актив әңгәмәдәш булырга, ягъни, беренчедән, сорауга сорау белән җавап бирергә; икенчедән, сорау җөмләдә бирелгән сүзләрнең мәгънәсен конкретлаштыруны таләп итә белергә тиеш. Мәсәлән, ***Синең исемең ничек***? җөмләсе актив әңгәмәдәшләр тарафыннан гап-гади генә өстәмә сүзләр кертелеп, сүзләрне кабатлау юлы белән, тыныш билгеләре – сөйләмгә эмоциональ бизәк һәм аһәңле яңгыраш бирүче билгеләр ярдәмендә болай үзгәртелергә мөмкин:

– *Синең исемең ничек*?
– *Минемме?!*
– *Әйе, әйе, синең.*
– *Минем исемемме?!*
– *Әйе, синең, синең исемең!*
– *Беләсең киләме?!*
– *Әйе, бик-бик беләсем килә!*
– *Бик беләсең килсә – әйтәм: минем исемем – Марат.*
– *Син – Маратмы?! О, Марат бик матур исем. Миңа ошый!*
– *Сиңа минем исемем ошыймы? Чынлапмы?! Рәхмәт!*

Чит телдә сөйләшергә өйрәнергә теләгән кеше (бала, укучы, олы кеше) үзе белән сөйләшүче кешене тыңлый һәм, сөйләшү барышында, аңа «ияреп бара» белергә, ягъни, беренчедән, әңгәмәдәше биргән сорауны (мәсәлән, *Син кайда яшисең*? соравын)

хәтерендә сакларга; икенчедән, үзенә бирелгән сорауга җавап биргәч, шул ук сорауны сорау биргән кешенең үзенә бирергә тиеш:

– ***Син кайда яшисең***?

– *Мин Казанда яшим.*

– *Ә син үзең* ***кайда яшисең***?

«Танышу» («Кемнең исеме ничек?») сөйләм калыбы, башка сөйләм калыплары төзелгән кебек, өч этапта формалаша:

***Кемнең исеме ничек***?

<table>
<tr><td>Лексик материалны туплау<br>Концентрация<br>лексического материала</td><td>Грамматик материалны туплау<br>Концентрация<br>грамматического материала</td></tr>
<tr><td>Керешмәләр<br><br>гафу ит<br>әйт әле<br>беләсем килә<br>беләсең килсә<br>чынлап<br>чынлап та<br>әйе<br>юк<br><br>Ничек? | Как?<br><br>кемнең?<br>1<br>минем<br><br>әниемнең<br>әтиемнең<br>әбиемнең<br>бабамның<br>абыемның<br>апамның<br>энемнең<br>сеңлемнең<br>дустымның<br>күршемнең</td><td>Сөйләм оештыру өчен,<br>үрнәк җөмлә калыплары<br><br>1 нче этап<br><br>Кемнең исеме ничек?<br>У кого имя как?*<br><br>1<br>Минем исемем ничекме?<br>Моё имя как?<br><br>Минем исемем Ренат.<br>Моё имя Ренат.<br><br>Әйе, минем исемем Ренат.<br>Да, моё имя Ренат.<br>Юк, минем исемем Ренат түгел.<br>Нет, моё имя не Ренат.<br><br>* * *<br>Минем әниемнең исеме Роза.<br>У моей. мамы имя Роза.</td></tr>
</table>

| **сорау кушымчалары**<br>вопросительные окончания | | | |
|---|---|---|---|
| -мы?<br>-ме? | -мы?!<br>-ме?! | -мыни?!<br>-мени?! | |

**Беренче этапта** сөйләүче (1 нче зат – мин) үзе, туганнары, якыннары турында гына сөйли, алар белән исемнәрен әйтеп таныштыра:

*Минем исемем – Роза. Мин – бәхетле кеше: минем бабам һәм әбием, әнием һәм әтием бар. Бабамның исеме – Ренат, әбиемнең исеме – Рената. Бабам да, әбием дә эш сөючән, яхшы күңелле кешеләр. Әтиемнең исеме – Тимур. Минемчә, ул тәртипле һәм акыллы әти. Әниемнең исеме – Лилия. Әнием кешелекле, ярдәмчел һәм яхшы күңелле кеше. Мин шулай уйлыйм.*

*Минем тагын абыем һәм сеңелем бар. Абыем да, сеңелем дә мәктәптә укый. Абыем – 10 нчы класста, сеңелем 3 нче класста укый. Абыемның исеме – Саша. Саша яхшы укый, тәртипле. Сеңелемнең исеме – Алия. Алия дә яхшы укый. Ул тәртипле һәм пөхтә кыз.*

*Без укыган мәктәп өч катлы, зур, якты һәм җылы.*

**Икенче этапта** 1 нче һәм 2 нче зат арасында сөйләшү, якыннанрак танышу барлыкка килә. **Диалог** һәрвакыт, башлангыч текстка (мин – беренче зат әйткәннәргә, сөйләгәннәргә) нигезләнеп, *сөйләүче – тыңлаучы – сөйләүче* арасында *сорау – җавап + сорау* формуласына яраклаштырылып оештырыла; затларның каракаршы сөйләшүе (аралашу) барышында, теманың эчтәлеге, алдагы дәресләрдә өйрәнелгән сүзләрне һәм җөмләләрне** катнаштырып, тагын да баетыла, конкретлаша, сөйләшүдә катнашучыларның башкарылган эшкә яки хәлгә карата мөнәсәбәте ачыклана. Диалогта катнашучылар, максатларына яраштырып, өч төрле синтаксик конструкцияне – хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмлә калыпларын куллана. Диалогта сөйләмне җыйнак һәм җиңел аңлаешлы итә торган ким җөмләләр дә, мәгънә ачыклыгы һәм төгәллеге өчен әһәмияте зур булган синтаксик берәмлекләр – эндәш сүз, кереш сүз, кереш җөмләләр; модаль кисәкләрдән сөйләүченең сөйләмдәге фикерне раславын яки инкарь итүен белдерүче, кайбер очракларда хәтта тулы бер җөмләне алмаштыра ала торган сүз – җөмләләр дә (*әйе* яки *юк*), 3–4 сүздән торган кушма җөмләләр дә бик еш кулланыла.

***Кемнең исеме ничек**?*

| **Лексик материалны туплау**<br>Концентрация<br>лексического материала | **Грамматик материалны туплау**<br>Концентрация<br>грамматического материала |
|---|---|
| **Керешмәләр**<br><br>гафу ит, рәхмәт<br>әйт әле<br>беләсем килә<br>беләсең киләме<br>беләсең килсә әйтәм<br>кит аннан, минемчә<br>чынлап, синеңчә<br>чынлап та<br><br>**кемнең**?<br>**2**<br>**синең**<br><br>әниең**нең**<br>әтиең**нең**<br>әбиең**нең**<br>бабаң**ның**<br>абыең**ның**<br>апаң**ның**<br>энең**нең**<br>сеңелең**нең**<br>дустың**ның**<br>күршең**нең** | **Сөйләм оештыру өчен,<br>үрнәк җөмлә калыплары**<br><br>**2 нче этап**<br>**2**<br>Миша, син**ең** әниең**нең** исеме ничек?<br>*Миша, у твоей. мамы имя как*?<br><br>Син**ең** әниең**нең** исеме Марина**мы**?<br>*У твоей мамы имя Марина*?<br><br>Син**ең** әниең**нең** исеме Нина **түгелме**?<br>*У твоей мамы имя **не** Нина*?<br><br>Син**ең** әниең**нең** исеме Нина **түгелмени**?!<br>*У твоей мамы имя **не** Нина разве*?! |

**Өченче этапта**, мәсәлән, кемнең дә булса – таныш булмаган малай яки кызның, кемнеңдер әнисенең яки әтисенең исемен белү өчен, беренчедән, 1 нче зат турыдан-туры таныш булмаган кешенең үзенә мөрәҗәгать итә ала. Бу очракта аңа, мөрәҗәгать формасы буларак, сөйләм этикеты таләп иткән *гафу ит, әйт әле, рәхмәт, бабай, әби, абый, апа, дустым* кебек сүзләрне куллану отышлы. Икенчедән, 1 нче зат таныш булмаган кеше турында 2 нче заттан сорашып белешергә мөмкин. Бу очракта ул «син» гә исемен әйтеп эндәшә һәм *кара әле, әйт әле, синеңчә, беләсем килә* кебек

сүзләрдән мөрәҗәгать формасы буларак файдалана: «*Әйт әле, Марат, Гүзәлнең энисенең исеме ничек*?»

***Кемнең исеме ничек*?**

| **Лексик материалны туплау**<br>Концентрация<br>лексического материала | **Грамматик материалны туплау**<br>Концентрация<br>грамматического материала |
|---|---|
| **кем**? | **Сөйләм оештыру өчен,**<br>**үрнәк җөмлә калыплары** |
| **3** | **3 нче этап** |
| апа | **3 2** |
| абый | Апа, син**ең** исем**ең** ничек? |
| бабай | *Апа, твоё имя как*? |
| әби | Апа, син**ең** исем**ең** Роза**мы**? |
| абый | *Апа, твоё имя Роза*? |
| эн**ем** | Апа, син**ең** исем**ең** Роза **түгелме**? |
| сеңел**ем** | *Апа, твоё имя **не** Роза*? |
| дуст**ым** | |
| матур**ым** | |
| күрше | |
| | |
| **кемнең**? | |
| **3** | **3 3** |
| Саша**ның**<br>Гәзәл**нең**<br>**аның**<br>**аларның** | Миша, Саша**ның** энисе**нең** исеме ничек?<br>*Миша, у Саши мамы имя как*? |
| | |
| энисе**нең** | Аның энисе**нең** исеме Анна**мы**? |
| этисе**нең** | *У его мамы имя Анна*? |
| әбисе**нең** | Аның энисе**нең** исеме Анна **бугай**? |
| бабасы**ның** | *У его мамы имя Анна, **кажется***? |
| абые**ның** | |
| апасы**ның** | |
| энесе**нең** | |
| сеңлесе**нең** | |
| дусты**ның** | |
| күршесе**нең** | |

<table>
<tr><td colspan="3">кемнең?</td><td rowspan="13">* * *<br>3 3<br>Бу малайның исеме ничек?<br>У этого мальчика имя как?<br><br>Бу кызның исеме ничек?<br>У этой девочки имя как?</td></tr>
<tr><td colspan="3">3</td></tr>
<tr><td rowspan="11">бу<br>менә бу<br>менә шул<br><br>әнә ул<br>әнә шул</td><td>бала</td><td rowspan="8">-ның</td></tr>
<tr><td>малай</td></tr>
<tr><td>кыз, апа</td></tr>
<tr><td>укучы</td></tr>
<tr><td>укытучы</td></tr>
<tr><td>хатын-кыз</td></tr>
<tr><td>бабай, абый</td></tr>
<tr><td>абый</td></tr>
<tr><td>ир кеше</td><td rowspan="3">-нең</td></tr>
<tr><td>егет, әби</td></tr>
<tr><td>чибәркәй</td></tr>
</table>

Без тәкъдим иткән сөйләм калыбына нигезләнеп, башка кеше ярдәм итмәсә дә, татарча бер вакытта да сөйләшмәгән кеше тема кысаларында кем белән дә булса, рәхәтләнеп, татарча сөйләшергә мөмкин.

* В переводе, чтобы сохранить основное значение или форму, применен прямой перевод.
** Бу темага кадәр, гадәттә, «Минем ... бар» дигән тема үтелә. (..., ягъни *энием, этием, әбием, бабам, апам, сеңелем, абыем, энем, дустым*)

## THE MODEL SPEECH – THE BASIS FOR SPEAKING TRAINING

***Maksimov Nikolaj Valentinovich,***
*Candidate of Philology,*
*Kazan (Volga region) Federal Univercity,*
*Nikolaj.Maksimov@kpfu.ru*

This paper examined method of teaching Tatar language to beginners. Simple word sentences as a base for understanding of the syntactic model of language can help students successfully use algorithms of creating sentences in communicative learning. Using of patterns helps student to vary the syntactic structures, making up simple text or dialogues.

***Keywords:*** simple word sentences, the speaking models, monologue, dialogue, studying spoken language, language patterns and algorithms.

УДК 372.8

# ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ – ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕНӘ УҢЫШЛЫ ӘЗЕРЛЕК ЧАРАСЫ

***Айдарова Светлана Ханип кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*aydarova-sh@rambler.ru*

Мәкаләдә рус телле укучыларны татар теленә өйрәтүдә яңа технологияләр карала. Автор укытучылар тарафыннан дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек вакытында кулланыла торган метод һәм эш формаларына анализ ясый. Аеруча игътибар коммуникатив технологиягә бирелә.

***Төп төшенчәләр:*** татар теле, рус телле укучылар, аттестация, укыту, яңа технологияләр.

Гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандарты (ФГОС) заманча мәгълүмати белем бирү шартларында дәрескә карата яңача якын килүне күзаллый. Шул сәбәпле укытучыга дәрескә әзерләнүнең тиешле технологияләрен белү, куллану мөһим.

Татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтүнең, аны үзләштерүне тиешле дәрәҗәгә күтәрүнең, укучыларны нәтиҗәле итеп дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләүнең төп юлы – рус мәктәпләрендә укучыларга татар телен һәм әдәбиятын сыйфатлы, нәтиҗәле итеп укыту.

Әлеге мәсьәләгә бүген галимнәр дә, укытучылар да зур игътибар бирә: ТР Мәгариф министрлыгы җитәкчелегендә төрле киңәшмә-утырышлар уздырыла, альтернатив программа, дәреслекләр, дәүләт йомгаклау аттестациясенә (ДЙАга) әзерлек өчен кулланмалар төзелә, алар гамәлдә сынап карала. Дәреслектәге материаллар укучының аңын, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерү максатын күздә тотып төзелгән. Күнегүләр укучыларны аваз, иҗек, сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтүдән тыш, дәрестән-дәрескә балалар-

ның тыңлап аңлау, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерүгә дә юнәлтелә.

Татар телен чит тел буларак өйрәтү буенча «Мәгариф», «Фән һәм мәктәп» журналларында да күп кенә файдалы һәм кызыклы язмалар дөнья күрә. Аларда татар теленә өйрәтүнең тарихы, белем бирүдә заманча технологияләр куллану мәсьәләсе, программадагы үзгәрешләр, татарча сөйләмне ишетеп аңларга өйрәтү, диалогик сөйләмне үстерү алымнары, аларның әһәмияте, татар теленә өйрәтү методлары һ.б. мәсьәләләр күтәрелә.

Гомумән, татар телен чит аудиториядә укытуны мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк итү – бүгенге көн педагогикасының мөһим бурычларыннан берсе. Ә уңай нәтиҗәләргә ирешүдә заманча технологияләргә таяну ярдәм итә ала.

Укытучылар укучыларын татар теленә нәтиҗәле итеп өйрәтү максатыннан, әлеге өлкәдә күп эзләнәләр, төрле технологияләрне үз эшчәнлекләрендә сынап карага тырышалар. Кайсылары укучылары өчен уңайлы, кайсылары катлаулы булуыннан чыгып, үзләре өчен файдалы һәм нәтиҗәле булганнарын сайлап алалар. Бер-берсенең дәресләренә йөреп, башкаларның эш-тәҗрибәләрен сынап карап, аларга карата үз фикерләрен булдырырга тырышалар. Максатлары – телне аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, логик фикерләргә өйрәтү барышында укыту методларының иң отышлыларын сайлап алу.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар.

1980 еллардан башланган мәктәп реформасы уку-укыту барышына гамәли үзгәрешләр кертүне күздә тота. Барыннан да бигрәк, сыйныф-дәрес рамкаларын күздә тотып әйтелә торган «традицион укыту» белән янәшә мәктәпкә яңа технологияләр, инновацион дәресләр күбрәк үтеп керә. Яңалык яклылар традицион дәреснең фәлсәфи нигезен мәҗбүр итү педагогикасы тәшкил иткәнлеккә, аның мәгълүмат бирүгә йөз тотуына, балага якын килү ягыннан авторитар (таләп итү педагогикасы) булуына, өстенлек алган ысул буларак аңлату-күрсәтүгә мөрәҗәгать итүенә басым ясыйлар [1: 27].

Инновацион технология буенча татар теленә өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә – укучының актив коммуникатив эшчән-

леккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интелектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләрне саныйбыз:

– укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

– укучының танып белү активлыгын арттыру;

– тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

– укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, инициативасын тагын да үстерү.

Үзебезгә килгәндә, дәресләребездә күбесенчә *коммуникатив технологияне* кулланабыз. Чөнки коммуникатив белем бирү, ягъни аралашу нигезендә өйрәтү технологиясе укучыга татар теле дәресләрендә белем һәм күнекмәләрне урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә гамәлдәге программа таләбе күләмендә аралашуны җитәрлек дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкинлек бирә.

Татар телен чит тел буларак укытканда, Е.И. Пассов, Ф.Ф. Харисов һ.б.лар билгеләгән белем бирүнең эчтәлегенә караган түбәндәге принципларны истә тотабыз:

1. *Сөйләмгә өйрәтү юнәлеше* аралашу аша укытуны аңлата. Бу исә, иң беренче чиратта, диалогик һәм монологик сөйләм телләрен үстерү.

2. *Функциональлек* өйрәнелә торган телнең сүзләре һәм грамматик формалары уку эшчәнлеге процессында берьюлы үзләштерелә. Бу принцип, безнең фикеребезчә, телне гомуми система буларак өйрәнүгә юл ача. Укучы сөйләм, аралашу барышында, лексик берәмлекләр белән беррәттән, төрле грамматик формаларны да өйрәнә ала.

3. *Яңалык* принцибы сөйләм ситуациясенең яңалыгын аңлата. Әлбәттә, һәр дәрестә яңа ситуацияләргә нигезләнү төрле тел бермәлекләрен өйрәнү мөмкинлеге бирә. Бу, бердән, уку-укыту процессын кызыклы, мавыктыргыч итә, икенчедән, укучыларның белемнәрен тирәнәйтә.

4. *Ситуативлык* уку процессын рольле оештыруга нигезләнә. Бу вакытта дәрес материалы көндәлек тормышта еш очрый торган ситуацияләрне торгыза. Болай укыту балаларны татар телен гамәли кулланырга өйрәтүгә этәргеч булып тора.

5. *Коллективара бәйләнеш* принцибы балалар бер-берсе белән актив аралашуын аңлата. Бу технологиянең нигезендә нәкъ менә укучы – укытучы һәм укучы – укучы аралашуы иң мөһим фактор булып тора. Шулай булгач, әлеге технология тәрбияви максатка да хезмәт итә, шул ягы белән ул аеруча әһәмияткә ия.

6. *Аралашуның шәхси юнәлеше* принцибы сөйләм үзенчәлеген аңлата. Әлеге принцип сөйләмгә куелган таләпләрне балаларга җиткерүне дә, шул ук вакытта һәр баланың сөйләм үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итүне белдерә [6].

Бу технология буенча укытканда, балаларга тәкъдим ителгән барлык күнегүләр аралашу өчен билгеләнгән сөйләм күнегүләрен тәшкил итәргә тиеш. Сөйләм күнегүләре шартлы сөйләм (лексик берәмлекләр кабатланган күнекмәләрне формалаштыру максатында вакытның чикләнмәгән булуы) һәм сөйләм (предметларны, рәсемнәрне тасвирлау, текстның эчтәлеген сөйләү һ.б.) күнегүләренә бүленә.

Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләрнең иң мөһим шарты – мәгълүмат чыганагы булу (китаплар, дидактик материаллар, техник чаралар, компьютер һ.б.) [2: 7].

Шулай итеп, коммуникатив технологияләр кулланып үткәрелгән дәресләр телне аралашу, дөньяны һәм үзен танып белү, мәдәниятне өйрәнү, иҗади һәм актив, дөрес, матур итеп аралашырга өйрәтү чарасы буларак күздә тота.

Рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессы коммуникатив технология нигезендә циклылыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик яктан катлаулылыгына, текстның күләменә, укучыларның фикерләү сәләтләре дәрәҗәсенә бәйле.

Текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст алды, текст һәм тексттан соңгы этаплар. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнергә тиешләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр лексик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛКФ) һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛГФ) дип атала. Әгәр тел өйрәтү процессын тел һәм әдәбият дәресләренә бүлеп укыту планына кертелгән икән, без аларны татар теле

дәресләре, ягъни татар теленең лексикасына, грамматикасына өйрәтү дәресләре дип атый алабыз. Укучылар, текстны лингвистик яктан беркадәр кабул итәргә әзерләнгәч, текстны үзен укырга күчәргә мөмкин. Бу дәресләрдә, нигездә, турыдан-туры текстны уку, текст буенча эш күнегүләре өстенлек итә. Шуңа күрә аны уку дәресләре дип атарга мөмкин. Дәрес тибы ягыннан алар лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре (ЛГКК) була. Бу тип дәрес тә, текстның катлаулылыгына карап, бер яки берничә дәрес булырга мөмкин. Мондый дәресләрдә алда өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә.

Тексттан соңгы этапта текст эчтәлеге һәм аңа салынган әхлакый проблема буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла. Дәрес типлары да диалогик-монологик сөйләм дәресләре дип атала. Бу дәресләрдә тексттагы лексик-грамматик материал сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелә, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм этабына чыгалар. Аңлашылганча, тел өйрәтү процессында татар теле һәм әдәбият дәресләре үзара шартлы бәйләнештә булалар. Циклда әдәби әсәрне өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр санына татар теле дәресләре саны да, әдәбият дәресләре саны да керә.

Коммуникатив технологияләр нигезендә дәресләрнең төрләре:

– иҗат һәм фантазиягә таянучы дәресләр: лекция, семинар, сыйныф алдында булган белемнәреңне яклау, зачет-дәрес, укучылар конференциясе һ.б.;

– иҗат һәм фантазиягә таянучы дәресләр: спектакль, коллектив инша, концерт, дәрес-бәхәс;

– нинди дә булса бер шөгыльне имитацияләү: экскурция, ярминкә, сәүдә йорты;

– дәрес-уен: дидактик, рольле, ярыш-уеннар;

– сюжетлы рәсемнәр буенча, бирелгән текст буенча, шәхси тәэсирләргә нигезләнгән иншага әзерләнү дәресләре;

– текстны анализлау, аның белән иҗади эшләү, үзеңнең текстыңны уйлау дәресләре [7: 97].

Укытучы дәрескә әзерләнгәндә барлык диалог бәйләнешләренең шатларын уйлап эшләгәндә, уку процессының билгеле бер

моделен ясый ала һәм шуның буенча дәресләр бер-берсе белән үрелеп бара.

Бу ысулның структурасы 4 технологик этаптан тора:

1) коммуникатив ситуация структурасын эшләү;
2) укучы белән укытучының бергә эшләвен проектлаштыру;
3) диалогларда катнашу;
4) бәйләнешле сөйләм буенча рефлексия.

Коммуникатив ситуация куеп, без укучыдан дәресләрдә актив катнашуын сорыйбыз. Бу тормышчан вакыйга булып, аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт була ала:

– проблемаларны актуальләштерү;
– кичереш һәм фикерләү шартлары;
– карарлар кабул итү, альтернатив нигездә үз гамәлләрен сайлау, өстәмә материал эзләү, аларны анализлау.

Эш барышында укытучылар *проблемалы укыту технологиясен* дә файдаланалар. Проблемалы укыту – укытучының укучылар белән берлектә проблемалы ситуацияне хәл итү юлларын эзләү процессы. Бу вакытта балаларның фикерләү сәләте камилләштерелә, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша. Укучыларда интеллектуаль көч яңа вакыйга, төшенчәләрне аңларга һәм фикер аша үткәрергә тырышкан вакытта кыенлыкларга очраганда барлыкка килә һәм ул проблемалы ситуациянең тудырылуын, тема белән тирәнтен кызыксынуны, аны хисси кабул итүне һәм укучының ихтыяр көченә ия булуын таләп итә. Бу технология татар телен чит тел буларак укытуда югары белем бирү уку йортлары дәреслекләрендә дә тәкъдим ителә [5].

Шунысы да әһәмиятле: әгәр укытучы дәрестә уңай психологик халәт тудыра алса, уңышка китерәчәк ситуация уйлап таба алса, үз эшен яратса, укучыларны хөрмәт итсә, ул һичшиксез зур уңышларга ирешәчәк. Балалар үзләренә булган игътибарны күреп үзләрен яратуларын, үзләренә ышануларын тоеп яшәргә тиеш.

Татар телен чит тел буларак өйрәтүдә *уен технологиясен* файдалану да отышлы. Ул укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Үткәрү максатыннан чыгып, уеннарны берничә төркемгә бүленә:

– дидактик уеннар;
– тәрбияви уеннар;
– үстерешле уеннар;

– социальләштерүче уеннар.

Дидактик уеннарны укучыларның белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген камилләштерү өчен кулланабыз. Тәрбияви уеннарны әхлак тәрбиясе бирү, рухи сыйфатлар, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү максатыннан үткәрәбез.

Укучыларның сөйләм телен үстерүдә, эзлекле фикер йөртү сәләтләрен формалаштыруда үстерешле уеннар ярдәм итә.

Укучылар бигрәк тә рольле уеннарны яраталар. Рольле уеннар укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыра, үзара ярдәмләшү теләге тудыра.

Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәтү өлкәсендә дә актив эш алып бару зарури: татар мәктәбендә – рус телен, рус мәктәбендә татар телен укытуда бәйләнеш булдыру укучыларның белемнәрне үзләштерүенә өстәмә ярдәм бирәчәк.

Гомумән, бүгенге дәрес төзелеше, эчтәлеге, оештырылуы зур үзгәрешләр кичерә. Без бүген дәреснең, беренче чиратта, коммуникатив юнәлешен көчәйтергә тиешбез: дәрестә хезмәттәшлек мохите булдыру, эшлекле партнерлар аралашуы, үзара контроль, үзбәя, төркемдә үзара ярдәмләшү кебек гамәлләр формалаштыруга игътибар бирергә кирәк. Укучы мәгълүматны утырып, тыңлап кабул итүчедән бу мәгълүматны табу, үзләштерүдә актив катнашучыга, партнерга әйләнергә тиеш. Уку мәсьәләләрен чишүдә төрле ысулларда ориентлашырга, уку эшчәнлеген оештыруның башка формаларын булдыруга ирешергә кирәк. Яңа алымнар куллану укытучының оештыру сәләтен үстерүне дә таләп итә: бүген укытучы төркемдә кулланылучы коллектив эш формалары белән идарә итә белергә тиеш. Укытучының роле дә үзгәрә: ул – белем бирүче түгел, ә белемне үзләштерүдә укучылар эшчәнлеген оештыручы. Бу максатны тормышка ашыруда соңгы вакытта актуаль булган *Сингапур методикасын* куллану да уңышлы нәтиҗәләр бирә. Әлеге система буенча төркемнәрдә эшләү – укучыларның үзара ярдәмләшүенә юнәлтелгән эш формасы. Бу вакытта балалар үзләре мәгълүмат чыганагына әйләнә. Укучылар, бер-берсенең фикерен тыңлап, үзүсешкә ирешә ала. Укытучының максаты – билгеле бер белемнәр җыелмасын тапшыру түгел, ә баланың индивидуаль үсешен, аның кызыксынуын, сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру. Хезмәттәшлеккә корылган Сингапур укыту струк-

туралары дәресне уен формалары, интерактив эш алымнары белән баетырга ярдәм итә һәм укучыларда тел өйрәнүгә кызыксыну уята.

Гомумән, бүген дәресләрдә заманча технологияләр куллану белем бирү дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итә. Ул укыту-тәрбия эшен гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Аны бары тик урынлы һәм нәтиҗәле кулланырга гына кирәк. Мәктәпләрдә компьютерлар өчен эшләнгән гамәли укыту программалары бар. Татар теле дәресләрендә куллану өчен «Минем беренче сүзлегем» һәм «Татар теле – 2002», «Татар телле Заман», «Татар теле 5–11» (2009) һ.б. компакт-дисклар чыкты [8; 9; 10]. Хәзер һәр укытучыда ноутбуклар бар, бу программаларны куллану өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Укучыларның белемнәрен тикшергәндә, өстәмә мәгълүмат биргәндә, бу дисклар бик уңай. Укучылар белән бергәләп компьютер программаларын файдаланып, укытучылар дәрес өчен төрле иҗади эшләр үтиләр, Excel программасында тестлар төзиләр. Бу программа укучыларның белемнәрен тикшерү өчен бик җайлы, чөнки анда җаваплар да кертелә, укучыларның белемнәрен дә компьютер бәяли. Укучыларга өй эше итеп тест төзеп килергә кушсаң, укучылар моны зур теләк белән эшлиләр.

Заманча дәреснең мәгълүмати белем бирү мохите түбәндәге дидактик характеристикаларны үз эченә ала: ачыклык, интерактивлык, визуальлек, вариативлык, күпфункциональлек [11: 6]. Алда әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: рус телләргә татар телен укытуда укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый һәм алар саналып киткән дидактик характеристикаларга тулысынча туры килә диярлек. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Татар теле дәресләрендә заманча технологияләр куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек алар – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив. Алар тел өйрәнүдә шактый күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

**Әдәбият**

1. Агапова Н.В. Перспективы развития новых технологий обучения. М.: ТК Велби, 2005. 247 с.

2. Айдарова С.Х., Гиниятуллина Л.М. Использование современных технологий при обучении татарскому языку // Теория и практика преподавания родных языков в системе среднего и высшего образования: современное состояние, проблемы и перспективы: материалы межрегиональной научно-практической конференции. Казань, 2014. 42–47.

3. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. Казан: Мәгариф, 1998. 151 б.

4. ТР халыклары телләре турындагы РТ законы. ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы. Казан: ТР-сы Дәүләт Советы басмасы, 1996. 42 б.

5. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. Ике кисәктә. Беренче кисәк. Казан: Мәгариф, 2009. 231 б.

6. Харисов Ф.Ф. Рус телендә сөйләшүче балаларны татарчага өйрәтүнең башлангыч чоры. Казан: Мәгариф, 1996. 43 б.

7. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К. Нотфуллина тәрҗемәсе. Казан: Мәгариф, 2002. 367 б.

8. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч. Татар теле. Кагыйдәләр, күнегүләр. Казан: Мәгариф, 2007. 184 б.

9. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч., Сулейманов Д. Минем беренче сүзлегем: Компакт-диск. «Мин татар телен өйрәнәм» сериясеннән. Казан, 2001.

10. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч. Татар телле заман: Компакт-диск «Мин татар телен өйрәнәм» сериясеннән. Казан, 2001.

11. Чернобай Е.В. Технология подготовки урока в современной информационной образовательной среде: пособие для учителей общеобразовательных учреждений. 2-е изд. М.: Просвещение, 2013. 56 с.

# USING OF MODERN TECHNOLOGIES FOR THE SUCCESSFUL PREPARATION FOR THE STATE CERTIFICATION

***Aydarova Svetlana Khanipovna,***
*Candidate of pedagogical sciences,*
*Kazan (Volga region) Federal University,*
*aydarova-sh@rambler.ru*

The article analyzed the new technology of teaching Tatar language to Russian-speaking students. Author examine the teaching methods used by teachers during the preparation for the final examinations for graduates. Special attention is paid to communication technologies used in training.

***Keywords:*** Tatar for non-native speakers, language education, training, new educational technologies, final examinations for graduates.

УДК 371.21

# РОССИЯ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКУ ӘСБАПЛАРЫ ӘЗЕРЛӘҮ ЮЛЛАРЫ

***Лотфуллин Марат Вазыйх улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*maratlv50@gmail.com*

Федераль дәүләт белем стандартлары шартларында Россия халыклары телләрендә укыту-методик әсбаплар белән тәэмин ителешнең торышына анализ ясала. Европа Советы тәкъдимнәренә туры китереп, туган тел буенча белем компетенциясен Россия белем компетенцияләре исәбенә кертү, Россия халыкларын туган телләрендә укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү вәкаләтләрен мәгариф белән идарә итү буенча федераль органнарга бирү тәкъдим ителә.

***Төп төшенчәләр:*** Федераль дәүләт белем стандартлары, Россия халыклары телләрендә укыту-методик әсбаплар, туган тел буенча белем компетенциясе.

2008 елдан Россия кануннары нигезендә мәктәпләрдә Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслекләрне генә кулланырга мөмкин. Методик әсбаплар да Россия мәгариф министрлыгы лицензиясе булган нәшриятларда гына бастырылган булырга тиеш. Бу шартларны үтәү буенча җаваплылык мәктәп директорларына йөкләнгән. Дәреслекләрне мәктәптә куллану өчен рөхсәт алу өчен нәшриятлар һәр дәреслеккә Россия фәннәр академиясеннән, Россия педагогия академиясеннән һәм Россия мәгариф һәм фән министрлыгы билгеләгән иҗтимагый оешмадан бәяләмә аларга тиеш. Һәр дәреслек тулы тезмә тәшкил итәргә тиеш (ягъни 1–4 класс башлангыч мәктәп өчен, яки 5–11 класс өчен), шул ук вакытта һәр дәреслекнең электрон версиясе булырга тиеш. Бу эшләр нәшриятлардан бик зур чыгымнар сорый. Әгәр дә милли мәктәпләрне укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү эше Россия регионнарына тапшырылуын исәпкә алсак, регионнар һәм Россия

составындагы республикалар бюджетларына бик зур өстәмә чыгымнар өстәлә. Шулай ук дәреслекләрнең кулланышка керү вакыты да арта. Чөнки Россия мәгариф министрлыгы рөхсәтен алу өчен таләп ителгән гамәлләрне узу өчен кимендә 3 ел вакыт кирәк. Нәтиҗәдә республикаларның һәм халыкларның мәгариф системасына тәэсире минималь дәрәҗәгә калдырылды. Телләрен һәм мәдәниятләрен саклау мөмкинлекләре бетерелде. Мәсәлән, Россия регионнарында татар теле фән буларак мәктәпләрдә укытылмый диярлек, чөнки мәктәпнең укыту программасына кертү өчен рөхсәт ителгән «рәсми» дәреслек юк. Татарстан әле узган ел гына башлангыч мәктәп дәреслекләренә рөхсәт ала алды. Бу уку елында Рособрнадзор Татарстан һәм Башкортстанга Россия мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте булмаган дәреслекләрне мәктәпләрдән алу турында күрсәтмә бирде. Бу хәлдән ничек чыгарга соң?

2009 елдан бирле белем бирүнең федераль дәүләт стандартларын эшләү бара. Стандарт белем үзләштерүгә, уку-укыту шартларына, тәрбия нәтиҗәләренә таләпләр булып кабул ителә. Элек эшләнгән стандартлардан аермалы буларак, яңа стандартлар Европага ияреп, һәр белем циклы буенча компетенцияләр формасында бирелә. Бу компетенцияләр «Европа Советы һәм Парламенты тәкъдимнәрендә» (2006 ел, 18 декабрь, № 2006/692/ЕС) аңлатып бирелә. Аларны 2 төркемгә бүлеп була: гомуми (универсаль, төп, профессиядән тыш) һәм махсус (профессиональ). Гомуми төркемгә 8 төп компетенция керә, шулар арасында беренче урында туган тел белү компетенциясе. Еврокомиссия тәкъдимнәре буенча, Болонья процессына катнашучы илләрдә балалар бакчасыннан алып, югары белемнән соң укуга кадәр туган телдә аралаша алу иң мөһим һәм беренчел компетенция булып санала. Россиянең Болонья процессына катнашуына карамастан, яңа стандартларда туган тел белү компетенциясе дәүләт теле буларак рус телен белү компетенциясенә алыштырылган.

Әлбәттә, Россия Конституциясе, халыкара документлар нигезендә туган тел белү төп компетенция булырга тиеш. Туган телен белмәгән кешеләр белемле, укымышлы дип саналмаска һәм белем турында документ алмаска тиеш. Бу очракта Россия мәгариф һәм фән министрлыгы үзе туган телләрне укытуны тәэмин итәргә тиеш. Бу проблеманы хәл итү – үзен укымышлы кеше дип санаган һәр кешенең бурычы.

Шулай ук татар телендәге укыту-методик әсбапларны бөтен Россия күләмендә мәктәпләргә оператив рәвештә җиткерү өчен дәреслекләр әзерләүне «Просвещение» гомумроссия нәшрияте базасында оештырырга кирәк. 1990 елга кадәр СССРда милли мәктәпләрне укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү шул нигездә алып барыла иде.

## PREPARING OF TEACHING MATERIALS IN TATAR LANGUAGE IN RUSSIA

***Lotfullin Marat Vazykhovich,***
*Candidate of physics and mathematics,*
*Sh. Marjani Institute of History,*
*Tatarstan Academy of Sciences,*
*maratlv50@gmail.com*

The system of providing possibilities to produce educational materials in the native languages of the minorities in Russia within the framework of the Federal State Educational Standards is analysed. In accordance with the recommendations of the Council of Europe it is proposed to implement the native languages educational competencies in Russia. Author suggest to oblige the federal educational authorities to provide ethnic minorities groups with the textbooks in native languages.

***Keywords:*** Federal State Educational Standards, textbooks, teaching manuals in the native languages, educational competence in native languages.

УДК 372.8

# РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ

***Яруллина Флёра Миннәтула кызы,***
*ТР Чүпрәле муниципаль районы*
*Иске Чүпрәле 1 нче номерлы урта гомумбелем*
*бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Мәкаләдә рус телле укучыларга татар теле һәм әдәбияты укытканда мәдәни компетенциянең әһәмияте турында сүз бара. Татар теленә өйрәтү процессында мәдәниятара компетенциянең максат һәм бурычлары күрсәтелә. Укучыларда үз халкының һәм башка халыкларның мәдәниятенә хөрмәт хисе тәрбияләүдә дәреслекләрнең роле ассызыклана.

***Төп төшенчәләр:*** мәдәни компетенция, тел һәм әдәбият дәресләре, мәдәниятара, аралашу компетенциясе.

Телне тиешенчә өйрәтү, укучыларда мәдәниятара компетенция формалаштыру – заман таләбе. Тел ярдәмендә генә кешенең һәм иҗтимагый төркемнәрнең уй-фикерләре формалаша. Ихтыяҗ булмаганда, кеше икенче телдә сөйләшми дә, чөнки, аралашу коралы булган туган теле бар. Әмма бер милләт тә үз мәдәнияте кысаларында гына бикләнеп кала алмый. Күпмилләтле дәүләттә яшәүчеләргә башка телләрне үзләштерү дә кирәк.

Татарстан республикасында дәүләт теле булып рус һәм татар телләре санала. Татар телен өйрәтү программасында әйтелгәнчә, республикада яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү мөһим. Татар халкы белән бер җирдә яшәгән, хезмәт иткән һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга хаклы.

Татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче укучыларга телне өйрәтүдә нинди максатлар куела һәм ул ничек башкарыла соң?

Телгә өйрәтү процессы үз эченә берничә этапны ала. Башлангыч сыйныфларда укучылар татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, аралашу өчен кирәкле иң актив сүзләрне кулланып сөйләшергә бурычлы. Танып белү максатының төп эчтәлеген балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру тәшкил итә. Урта сыйныфларда Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстан символикасы, башкалабыз Казанның тарихы, бүгенге йөзе, Татарстанның территориясе, географик урыны, икътисади бәйләнешләре, татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча билгеле булган шәхесләр, бөек җиңүгә Татарстанның өлеше турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

Югары сыйныф укучылары, нигездә, I–IX сыйныфта алган белемнәрен киңәйтәләр, тулыландыралар. Аларның алда аталган темалар һәм Татарстанның югары уку йортлары, икътисади үсеш дәрәҗәсе, дөньякүләм аренада бүгенге урыны, бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше, Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре турында иркен аралашуга чыгулары максат итеп куела.

Рус телле укучыларга татар теленә өйрәтүнең максатын укучыларда лингвистик, коммуникатив, этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру тәшкил итә. Лингвистик программа телне иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак өйрәнүне, татар әдәби тел нормаларын үзләштерүне, укучыларның сүз байлыгын арттыруны бурыч итеп куя.

Аралашу компетенциясе – сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үзләштерүне, телне төрле ситуацияләрдә файдаланырлык итеп өйрәтүне, шуңа бәйле рәвештә укучыларның кызыксыну даирәсен һәм психологик үзенчәлекләрен искә алуны күздә тота.

Этнокультура компетенциясе телне милли мәдәниятнең чыганагы буларак күзаллауны, тел белән тарих бәйләнешен аңлауны, татар телен аның милли-мәдәни үзенчәлегенә төшенеп өйрәнүне, татарча сөйләмгә хас булган нормаларны үтәүне күздә тота.

Укучыларда мәдәниятара компетенция формалаштыру татар теленә өйрәтү процессында төп максатларның берсе булып тора. Мәдәни компетенция түбәндәге бурычларны һәм юнәлешләрне ала:

– телне саклау һәм үстерү, башка милләт халкында телгә, мәдәнияткә карата кызыксыну һәм хөрмәт уяту, халыклар арасында толерантлык тәрбияләү;

– белем бирүдә заманча технологияләрдән нәтиҗәле файдалану;

– укучыларның фән белән кызыксынуын арттыру, дөрес юнәлеш сайлау;

– укытуның һәр этабына уңышлы вариантлар табу;

– балаларны рухи һәм физик яктан сәламәт үстерүгә өлеш кертү:

– «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон нигезендә рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәтү.

Әлеге бурычларны үтәү өчен дәресләрдә төрле педагогик технологияләр кулланыла: шәхескә юнәлтелгән технология, үстерелешле укыту технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, коммуникатив технология, концентрик технология, мәгълүмати технология, проект технологиясе, уен технологиясе, сәламәтлекне ныгыту технологиясе һ.б.

Мәдәниятара компетенция белем, күнекмә, фикерләү, мөнәсәбәт аркылы гына формалаша ала. Дәресләрдә яңа белемнәр алу белән бергә, элек алган күнекмәләр ныгытыла, укучының фикерләү сәләте үсә бара.

Рус телендә сөйләшүче балалар татар теле һәм әдәбияты аша мәдәни компетенциягә ия булсыннар өчен, дәресләрдә түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителә:

– өйрәнелә торган телдә сөйләшүчеләрнең милли-мәдәни үзенчәлекләрен күз алдына китерергә мөмкинлек бирә торган татар әдәбияты үрнәкләре – әдәби текстлардан алынган өзекләр белән танышу;

– татар халкының мәдәни казанышлары, күренекле шәхесләре турындагы текстларны уку;

– татар исемнәренең этимологиясе турында кыскача белешмә бирү;

– җанлы сөйләшү үрнәкләре аша укучыларны татар телендә кабул ителгән сөйләм этикеты калыплары белән таныштыру, икенче яктан, аларны гамәли үзләштерергә һәм аралашуда куллануга этәрү;

– халык авыз иҗаты үрнәкләрен тәрҗемә итү һәм алар нигезендә тел күнегүләрен эшләү.

Бу төр күнегүләр укучыларны татар мәдәнияте белән таныштыра, яңа лексик берәмлекләрне үзләштерергә, тәрҗемә итү күнегүләрен дөрес башкарырга күнектерә.

Рус телле укучылар өчен бастырылган дәреслекләрдә милли гореф-гадәтләрне, мәдәниятны чагыштырып өйрәтү өчен биремнәр бик күп. Аларның һәрберсен санап та тормабыз. Мәсәлән, Р.Р. Нигъмәтуллина авторлыгындагы дәреслекләрдән милләтләрнең дуслыгы турында язылган шигырьләр белән танышкач, төрле милләт кешеләренең дус яшәве турында укучыларның монологик һәм диалогик сөйләме үстерелә, башка милләрләргә карата хөрмәт тәрбияләнә. Төркемнәрдә эшләү өчен өстәмә сораулар биреп яисә дәрестә башка төрле эш алымнары кулланып теге яки бу милләтнең мәдәнияте, бер-берсенә хөрмәте, үзара аңлашып, дус яшәүләре турында укучыларның уй-фикерләрен тирәнәйтергә, баетырга мөмкин. Дәресләрдә мәдәниятне, гореф-гадәтләрне чагыштырып өйрәнүне бик отышлы алым дип саныйбыз, чөнки ул укучыларда толерантлык тәрбияли. Теләсә кайсы милләт язмышы аның башка халыкларга булган мөнәсәбәтендә, карашында ачык чагыла.

Укучыларда толерантлык сыйфатларын тәрбияләүнең иң матур үрнәге рус һәм татар әдәбиятын интеграцияләп укытканда күренә. Әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларын, әсәрләрен һәм анда күтәрелгән проблемаларны төрле милләт әдәбиятын янәшә куеп анализлауны укучылар кызыксынып кабул итәләр. Бөек татар шагыйре Г. Тукай иҗатын өйрәнгәндә, рус телле укучыларга аның «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» шигыреннән өзек китерелә:

Рус белән тормыш кичердек, сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык, вакытлар алмашып.

Ф. Әмирханның «Хәят» повестеннан өзекне укыганнан соң да, укучылар рус һәм татар милләтләре арасындагы татулык, рухи һәм физик матурлык, ихтирамлылык хисләрен тоялар.

Татар әдәбияты дәресләрендә Г. Тукай белән А.С. Пушкинның, М.Ю. Лермонтов белән Дәрдмәнднең кайбер әсәрләрен чагыштырып өйрәнү, алардагы уртак, аермалы якларны билгеләү дә

укучыларда зур кызыксыну уята. Моннан тыш, бер милли әдәбият кысаларында да ике дөнья, ике мәдәният тормышын, аның асылын ачып бирергә мөмкин. Рус һәм татар халкының фольклоры – авыз иҗаты мисалында да кешелекнең дөньяны күзаллавы, танып белүе, мәдәни һәм кешелеклелек кыйммәтләрен таптыру билингваль, толерантлы шәхес формалаштыруга этәргеч бирә. Әдәбият дәресләрендә төрле әсәрләр, шигырьләр уку, анализлау аша укучыларда уңай сыйфатлар тәрбияләнә, төрле милләт халыкларының әдәбиятына, мәдәниятенә, сәнгатенә хөрмәт тәрбияләнә.

Мәдәниара компетенция дәрестән тыш чараларда да формалаша. Татар милләтеннән булмаган укучылар да Туган тел бәйрәмендә, Г. Тукай туган көнендә яисә башка шагыйрьләргә, язучыларга багышланган чараларда татар телендә шигырьләр сөйлиләр, фәнни конференцияләрдә чыгыш ясыйлар. Сәләтле укучылар республика күләмендә үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты олимпиадаларында катнашалар, призлы урыннарга ия булалар.

Соңгы вакытта татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую юнәлешендә республикабызда шактый зур эшләр башкарылды: федераль дәүләт стандартларына нигезләнгән укыту программалары төзелде һәм алар нигезендә башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәбе өчен укыту-методик комплектлары яңартылды; укучыларның белемнәрен тикшерү системасы халыкара стандартларга нигезләнеп үзгәртелә башлады. Заман таләпләренең берсе – мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне куллануга да зур игътибар бирелде. 2013 елның 1 гыйнварыннан «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе эшли башлавы моның ачык мисалы. Әлеге онлайн-мәктәп аша тел өйрәнүчеләр, тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу күнекмәләренә ия булып, җанлы аралашуга чыга алалар. Онлайн дәресләрдә урын алган күпсанлы диалоглар, сөйләм күнегүләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре, татар җырлары, танылган татар шагыйрьләренең шигырьләреннән алынган өзекләр, татар театры артистлары катнашкан видеоязмалар татар халкының мәдәнияты белән тулырак танышырга ярдәм итә, укучыларда телне өйрәнүгә кызыксыну уята.

Мәдәниятара компетенция татар теле һәм әдәбият дәресләрендә руслар, башка милләтләр һәм татарларның милли мәдәниятләре арасында тыгыз бәйләнешне күрсәтү, татар мәдәнияте турында белешмәләр белән бергә, рус, башка халыклар мәдәнияте турында да белемнәрне үстерү, сөйләм булдыру закончалыкларын

саклау нәтиҗәсендә формалаша. Республикабызда яшәүче башка милләтләрнең туган теле татар, рус телләре белән үзара бәйләнештә тору телне өйрәнүдә аерым функцияләрне үти:

– укучыларның туган тел дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрен күчерүдә мөһим шарт булып тора;

– татар һәм рус, башка телләрне чагыштыру юлы белән (гомуми һәм охшаш тел күренешләрен) белем алуны тотрыклырак итә, алар укучылар хәтерендә тизрәк ныгып урнаша һәм туган телне дә яхшырак үзләштерергә булыша;

– укучыларның хәтерен, фикерләвен, игътибарын үстерү өчен тиешле шартлар тудыра, сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләрен камилләштерергә ярдәм итә;

– әлеге телләрнең мөмкинлекләрен аларны өйрәнүпроцессында тулырак һәм нәтиҗәлерәк файдаланырга ярдәм итә.

Йомгак ясап, тел дисциплиналары дәресләрендә һәм класстан тыш эшләрдә укучыларның мәдәниятара компетенциясен үстерүнең гаять зур әһәмияткә ия булуын ассызыкларга тиешбез. Шуңа да, мәдәниятле, гомумкешелек һәм гомуммәдәният кыйммәтләрен үзләштергән җәмгыятьтә үз халкының һәм башка халыклар мәдәниятен хөрмәт итә белгән, илгә файдалы шәхес тәрбияләү – һәр педагогның изге бурычы.

**Әдәбият**

1. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен): 1–11 нче сыйныфлар / Төз.-авт.: К.С. Фәтхуллова, Ф.Х. Җәүһәрова. Казан: Мәгариф, 2010. 79 б.

2. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан: Мәгариф, 2010. 223 б.

3. Фәтхуллова К.С. Татар телен заманча өйрәтәбез! // Мәгариф. 2014. № 10. 19 б.

4. Ахмерова С. Развитие межкультурной коммуникации // Мәгариф. 2014. № 2. 67 б.

# FORMATION OF CULTURAL COMPETENCE OF RUSSIAN-SPEAKING STUDENTS AT THE TATAR LANGUAGE AND LITERATURE CLASSES

***Yarullina Fleura Minnatullovna****,*
*the teacher of the Tatar language and literature*
*of Iske Chuprele Secondary school № 1*
*of the Republic of Tatarstan*

The article deals with the importance of cultural competence for the teaching Tatar language and literature to Russian-speaking students. Author define the aims and tasks of cross-cultural competence in the context of teaching of Tatar language. The article also emphasizes the importance of promoting mutual understanding and intercultural dialogue through the education.

***Keywords:*** cultural competence, teaching of Tatar language and literature, cross-cultural communication competence.

УДК 372.8

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУНЫҢ СЫЙФАТЫН ҺӘМ НӘТИҖӘЛЕГЕН ҮСТЕРҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

***Нәбиуллина Тәслимә Гыйният кызы,***
*Казан шәһәре 7 нче гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*nabiullina.t@yandex.ru*

Мәкаләдә татар теленә өйрәтүдәге заманча методлар турында сөйләнә. Яңа технологияләр куллану укыту барышының нәтиҗәлелеген, укучыларның кызыксынучанлыкларын арттырырга мөмкинлек бирә. Эшчәнлекнең бу төре укучыларның үзара аралашу сәләтләрен үстерүгә ярдәм итә.

***Төп төшенчәләр:*** заманча технологияләр, коммуникатив компетенция, педагогик осталык, хәзерге дәрес, инновацион методлар.

К.Д. Ушинскийның: «Укытучы һәрдаим укыганда гына укытучы булып кала», – дигән сүзләре бүген дә бик мөһим. Чөнки дөнья, аның таләпләре туктаусыз үзгәреп тора, тормыштан артта калмас өчен, педагог үзлегеннән даими укырга, инновацион технологияләрне үзләштереп барырга тиеш.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә заманча технологияләр кулланып, укыту процессының сыйфатын һәм нәтиҗәлеген үстерү» дигән методик тема өстендә эшлим. Методик темамның максаты: татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирүнең эчтәлеген яңартуга һәм сыйфатын үстерүгә юнәлдерелгән методик система булдыру.

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны куйдым:

– фәнни-методик әдәбият, башка укытучыларның тәҗрибәсе белән танышу;

– заманча технологияләрне куллану мөмкинлекләрен ачыклау;

– белем бирү процессын кызыклы, нәтиҗәле итү.

Сыйфатлы белем бирү һәм алган белем-күнекмәләрне камилләштерү өчен, заманча технологияләрне дәрестә системалы һәм урынлы файдалану зур әһәмияткә ия. Технология инновацион процессларда тулысынча яңартыла. Ул исә укыту процессы субъектларын – укытучының да, укучының да тирәнтен әзерлекле булуын таләп итә. Бу хәзерге заман дәресен оештыру өчен зарури. Практика дәресләрдә компьютер куллануның белем бирүдә традицион методлардан өстен булуын раслый, укучы дәресләрдә актив катнашучы була. Шуны да истә тотарга кирәк: укытуның традицион системасында булган иң яхшы алым, методларны куллана, үстерә барып эшләгәндә генә, инновацион технология яхшы нәтиҗәгә ирешүгә ярдәм итә ала. Компьютер технологияләре белем бирүнең эчтәлеген, методларын, оештыру формаларын сыйфатлы итеп үзгәртә, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен, танып белү сәләтен үстерүгә ярдәм итә, ә аның көче, интеллектуаль базасы, күрсәтмәлелек белән ярашуы вакыйгаларда турыдан-туры катнашучы булырга мөмкинлек бирә, үсеше белән идарә итәргә этәрә. Компьютер программалары укытуны индивидуальләштерүгә ярдәм итә, укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен оештырырга мөмкинлек бирә.

Заманча технологияләр укытучыга:

– мультимедиа һәм интернет аша зур күләмле мәгълүмат алырга өйрәтүдә;

– укыту процессында кирәк булган материалларны тупларга өйрәтүдә;

– мәгълүматны каталоглар һәм белешмәләр кулланып эшкәртергә өйрәтүдә;

– индивидуаль белем бирүдә;

– эзмә-эзлекле процессның барышын күзәтү мөмкинчелегенә;

– үзаллы эшне булдыруда ярдәм итә.

Дәресне заман таләпләренә җавап бирә торган компьютерлар белән тәэмин итү – мәгълүмати технологияләрне гамәлгә куюда беренче шарт. Укыту-тәрбия эшендә мәгълүмати технологияләрне максатчан файдалану өчен укытучының фәнни-методик яктан югары әзерлекле булуы белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белү осталыгы да таләп ителә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Казан шәһәрендәге 7 нче гимназия коллективы укытучылары белем бирүдә түбәндәге формуланы кулланып эшлиләр:

*Нәтиҗәлелек = шартлар + укыту процессы.*

Югары нәтиҗәләргә ирешү максатыннан, укытучы, барлык мөмкинлекләрне кулланып, укыту процессын җитәкли. Укытучы укытуның сыйфаты, укучыларның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе өчен җавап бирә. 7 нче гимназиядә, инновацион технологияләр кулланып, дәресләр бирү өчен барлык шартлар да тудырылган (җиһазландырылган компьютер сыйныфлары, интерактив такталы сыйныф бүлмәләре, медиа-үзәк, 3D форматтагы кинозал һ.б.).

Дәресләрдә компьютер, интерактив такта, документ-камера кебек техник чаралар аша һәрдаим информацион белешмә (сүзлек, энциклопедия), күргәзмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар) кулланыла. Презентация слайдлары яңа материалны аңлатканда да, белемнәрне актуальләштерү этабында да, белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру этапларында да уңышлы кулланыла. Материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайлана. Яңа теманы аңлатканда, презентациянең әһәмияте зур. Слайдларда рәсемнәр, схемалар, даталар, терминнарга аңлатмалар, кыскача тезислар язылырга мөмкин. Дәрес барышында башка эш төрләре дә: дәреслек белән эш, тактага язу, сүзлекләр белән эшләү һ.б. актив кулланыла. Компьютер технологиясе күнегүләр системасын тормышка ашыруны тәэмин итә. Бу исә үз чиратында уку процессын камилләштерергә, сөйләм материалын үзләштерүне җиңеләйтергә тиеш. Интерактив эшчәнлек барышында укучы үзенең җавапларының дөреслеген дә тикшереп бара. Укучылар Интернет челтәрендә үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнашалар, яшьтәшләре белән аралашалар. Дәреснең төрле этапларында урынлы, уйлап кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барыла.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә электрон тестлар уздыру, укучыга компьютер тарафыннан куелган билге алу бик отышлы алым. Дәресләр өчен электрон тестлар берникадәр дәрәҗәдә (татар теленнән «Затланышлы фигыльләр», татар әдәбиятыннан 7–8 нче сыйныф укучылары өчен тулаем) төзелгән.

Татар теле һәм әдәбияты дәресендә лингвистик компетенцияләргә нигезләнеп, мәгълүмати-коммуникатив, үстерелешле укыту технологияләрен кулланып эшләү, укыту процессының сыйфатын үстерүгә ярдәм итә.

Бүгенге көнгә рус балалары өчен татар әдәбиятыннан барлык сыйныфларга да дәреслекләр нәшер ителмәгән. Әдәбият дәресләре кызыклы һәм сыйфатлы үтсен өчен, укучылар белән берлектә электрон дәреслекләр төзелә. Моның өчен сыйныфтагы һәрбер бала бер яки берничә язучы, композитор, шагыйрь, рәссам турында мәгълүмат туплый, әсәрләрен эзли-таба, презентация ясый. Проект методын куллану укучыларда эзләнү, информация таба белү, презентацияләү, коммуникативлык күнекмәләрен формалаштыруга ярдәм итә, фәнни-тикшеренү эшендә дә катнашуга этәргеч булып тора.

Укучылар белән төрле күренекле шәхесләргә багышланган проектлар, видео-фильмнар төшерү, лексик темалар буенча презентацияләр төзү эше алып барыла. Күп кенә мультимедиа, аудио- һәм видеоматериаллар тупланган. Мультимедия технологиясе слайд-иллюстрацияләр күрсәтергә, читтән торып экскурсия үткәрергә мөмкинлек бирә. Дәресләрдә укучылар тарафыннан да әзерләнгән видео-экскурсияләр карау бик отышлы. Бүгенге көндә М. Җәлил, К. Насыйри, Г. Тукай музейларына видео-экскурсияләр әзерләнгән. Әдәбият дәресләрендә мультимедия технологиясе куллану чагыштырмача анализ ясарга да ярдәм итә. Алар белем бирү процессын кызыклырак итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Дәресләрдә электрон дәреслекләр куллану укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә юнәлдерелә. 2010 елда Bars-media нәшриятында 2–9 сыйныф укучылары өчен «Татар теле дәресләре» дип исемләнгән электрон методик кулланма төзеп чыгардым. Фәнни редакторы – профессор Ф.Ф. Харисов, диск Татарстан республикасы мәгарифне үстерү институты тарафыннан расланган. Бу диск, беренчедән, татар теле укытучылары өчен электрон методик кулланма, икенчедән, укучыларга үзөйрәткеч буларак тәкъдим ителә. Телне өйрәнү гади җөмлә синтаксисына нигезләнгән. Үзөйрәткечтә башта җыйнак, аннары җәенке җөмләләр өйрәнелә. Һәр тема үзләштерелгәннән соң, белемнәрен тикшерү өчен күнекмәләр, тестлар бирелә. Бу тестлар компьютер ярдәмендә тикшерелеп,

билге куела. Үзәйрәткечтә татарча-русча сүзлек, сөйләмдә еш кулланыла торган репликалар бирелә. Шулай ук рәсемле фразеологизмнар сүзлекчәсе дә тәкъдим ителә.

ФГОС таләпләренә туры килгән яңа дәреслекләр төзү буенча иҗади төркемдә эшлим. КФУ галимнәре Айдарова С.Х., Гарипова В.А. белән бергә 7 нче сыйныф өчен татар теле (татар балалары өчен) дәреслеге һәм методик әсбап төзелде. Бүгенге көндә шул ук сыйныфка электрон дәреслек эшләнелә. Бу эшчәнлекне «галим – укытучы» иҗади лабораториясе дип атап үтәргә мөмкин.

Татар теле һәм әдәбият дәресләре өчен *edu.tatar.ru, belem.ru, топ.татар.ру* сайтларында берникадәр дәрәҗәдә материал бирелгән. Бу сайтларга һәрдаим мөрәҗәгать итеп, кирәкле ресурслар кулланыла. Мәсәлән: балалар өчен мультфильм, видео-фильмнар карау, төрле шәхесләр турында мәгълүмат алу, электрон дәреслекләр куллану. Шулай ук *edu.tatar.ru* сайты ярдәмендә татар теленнән факультатив дәресләре үткәрелә. «Ана теле» проектында катнашу оештырылган. Укучылар, проектта катнашып, үзләренең белемнәрен камилләштереп, кирәкле дәрәҗәгә җитәләр. Иң мөһиме, һәрбер дәрәҗәне үткәннән соң тест эшләнелә.

Он-лайн режимында төрле чаралар оештырыла:

– татар диаспоралары белән видео-конференцияләр, вебинарлар, он-лайн дәресләр (Германия һәм Украинада яшәүче татарлар белән элемтәдә торабыз);

– скайп программасы ярдәмендә дистанцион укыту.

Рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүдә рольле уеннар актив кулланыла торган ысул булып торалар. Аларның өйрәтү мөмкинлекләре зур һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар аның белән иркен эш итәләр. Методик яктан дөрес уйланылган уен, бер яктан караганда, укучыда өйрәнелә торган телгә карата мәхәббәт тәрбияли, сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләм эшчәнлеген табигый нормаларга якынайта, икенче яктан – тел материалы өстендә нәтиҗәле эшкә ярдәм итә һәм белем бирүнең коммуникатив юнәлеше таләпләренә җавап бирә. Татар теле дәресләрендәге уен ситуацияләре яңа тел материалын презентацияләүдә, үтелгән лексик һәм грамматик материалны ныгыту һәм активлаштыруда аерым урын тота. Алар шулай ук укучыларның татар телендә сөйләм эшчәнлеген оештыру функциясен дә үтиләр. Уеннар вакытында укучыларның белем һәм күнекмәләре камилләшә.

Аларда бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге туа. Балалар уен вакытында шатланалар, эшләгән эшләреннән риза, канәгать калалар.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә заманча информацион технологияләр куллану уңышлы нәтиҗәләргә китерә. Чирек, еллык нәтиҗәләре буенча өлгереш һәм сыйфат мониторингы алып барам. Уку эшчәнлегенең нәтиҗәләре буенча вакытында алынган мәгълүмат тиз арада авырлыкларны табарга, кирәкле ярдәмне күрсәтергә һәм белем бирү эшчәнлеген көйләргә булыша.

Татар халкының күренекле фикер иясе, мәгърифәтчесе Ризаэддин Фәхреддинов әйткәнчә, «...бары тик эш дәвамлы булганда гына нәтиҗәсе була». Шуны истә тотып, мин дәресләремне сыйныфтан тыш эшләр белән үреп алып барырга тырышам. Программа буенча өйрәнелгән темалар сыйныфтан тыш эшләр белән дәвам ителә. Татар теле һәм әдәбиятыннан электив курслар: «Татар телен тирәнтен өйрәнү», «Татар әдәбиятын өйрәнүдә проект эшчәнлеге» алып барам. Дәрестән тыш эшләрне әзерләгәндә укучыларның иҗади сәләтен һәм логик фикерләвен үстерүгә, тәрбияви, гамәли, гомуми белем бирү мәсьәләләрен чишүгә игътибар ителә. Аларның формасы һәм ысулы әхлакый тәрбиягә, милли үзаң үсешенә юнәлдерелгән. Әлеге чараларда укучыларның белемнәрен гамәли куллануга, татар теленә һәм әдәбиятка, милли мәдәнияткә мәхәббәт уятуга омтылам. Бу эш алымы өйрәнелгән материалны гомумиләштерә, тулыландыра, укучыларның телне өйрәнү нәтиҗәсен күрсәтә һәм күнекмәләргә әйләндерергә ярдәм итә.

Уңышларга ирешү өчен, укытучы эш дәверендә төрле педагогик технологияләр, дәрес формалары, метод-алымнарны үзләштереп, замана белән бергә алга атларга тиеш. Шул очракта, тормышка һәр яктан әзерлекле, камил, үз милләтенең матди һәм рухи байлыкларын арттыручы, туган халкының киләчәген кайгыртучы зыялы шәхес тәрбияләнәчәк.

**Әдәбият**

1. Әсәдуллин А.Ш, Фәтхуллова К. Сөйләшергә тел булсын // Мәгариф. 2001. № 9. 10–12 б.

2. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. Казан: Мәгариф, 1998. 151 б.

3. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татарский язык. Интенсивный курс. Казан: «Хәтер» нәшр., 1998; 1999.

4. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: «Хәтер» нәшр., 2001. 432 б.

5. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. Казань: Изд-во ТаРИХ, 2000. 479 с.

6. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрҗемәсе. Казан: Мәгариф, 2002. 367 б.

7. Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. СПб.: филиал издательства «Просвещение», 2001. 431 с.

## MODERN TECHNOLOGY AS A MEANS OF IMPROVING THE QUALITY AND EFFECTIVENESS OF TEACHING TATAR LANGUAGE AND LITERATURE

***Nabiullina Taslima Giniyatovna,***
*the teacher of the Tatar language and literature*
*of Gymnasium № 7 of the Kazan,*
*nabiullina.t@yandex.ru*

This article presents the modern methods of teaching of Tatar language. Applied methods and technologies help to improve the efficiency of the learning process, to develop students interest in learning. Author paid special attention to the developing of communicative competence of students.

***Keywords:*** modern educational technologies, communicative competence, pedagogical skills, modern lesson, innovative methods.

УДК 37(470.41) (09):376

# МАХСУС (КОРРЕКЦИОН) МӘКТӘПТӘ КАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ

***Шәйхетдинова Гөлфия Сахибетдин кызы,***
*Казан шәһәре 4 нче махсус коррекция интернат-мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*gsalina75@bk.ru*

Мәкаләдә махсус (коррекцион) мәктәптә галим-лингвист, педагог, энциклопедист һәм язучы К. Насыйри иҗатын өйрәнү үзенчәлеге хакында сүз бара. К. Насыйри шәхесенә багышланган дәресләрнең төзелеш-корылышы коррекцион мәктәптә укучы балаларның психо-моторик һәм физиологик үзенчәлекләренә турыдан-туры бәйле булуы ассызыклана. Хезмәттә балаларның дәрес материалын үзләштерүе аларның коммуникатив сыйфатларын үстерү, фикер йөртүен активлаштыру белән янәшә барырга тиешлегенә басым ясала. Мәкаләдә шулай ук К.Насыйри шәхесе үрнәгендә укучыларда максатчанлык, тырышлык, иҗадилык кебек сыйфатлар тәрбияләү проблемасы да урын ала.

***Төп төшенчәләр:*** махсус (коррекцион) мәктәп, К. Насыйри, балаларның психо-моторик һәм физиологик үзенчәлекләре, коммуникатив сыйфатлар.

Татар дөньясында мәрҗәндәй балкучы мондый бөек шәхесләребезнең исемнәрен буыннан-буынга түкми-чәчми тапшыру – безнең изге бурычыбыз. Яшь буын, һичшиксез, әлеге шәхесләрне белеп үсәргә тиеш. Татар әдәби-мәдәни фикер үсешенә өлеш керткән шундый шәхесләрнең берсе – мәгърифәтче Каюм Насыйри.

К. Насыйриның тәрҗемәи хәле, аның әсәрләреннән өзекләр мәктәп дәреслекләрендә урын ала. Махсус (коррекцион) мәктәптә укучы татар һәм рус балаларына да К. Насыйри шәхесе хакында мәгълүмат бирү, аның иҗади мирасы турында билгеле бер күзаллаулар тудыру мөһим. Һичшиксез, әлеге эш мондый төр мәктәптә укучы балаларның психо-моторик һәм физиологик үзенчәлекләрен истә тотып эш итүне таләп итә. Балаларның дәрес

материалын үзләштерүе аларның коммуникатив сыйфатларын үстерү, эмоциональ тәҗрибәсен баету, фикер йөртүен активлаштыру, иҗтимагый бәйләнешләрен үстерү белән янәшә барырга тиеш.

К. Насыйрига багышланган дәресләрдә, иң беренче чиратта, язучының тәрҗемәи хәле турында мәгълүмат бирелә. Бу нисбәттән, махсус (коррекцион) мәктәптә укучы балалар белән эшләгәндә, күрсәтмәлелекнең роле аеруча мөһим булуны ассызыкларга кирәк. Язучы иҗатына нисбәтле дәресләрдә К. Насыйриның сурәте, язучы яшәгән дәверне, мохитне тасвирлаган рәсемнәр, әсәрләре буенча иллюстрацияләр эленә. Иллюстрацияләр, рәсемнәр, мисал өчен, укучыларның үзләре тарафыннан да эшләнелгән булырга мөмкин. Болар бар да дөньяны танып белү мөмкинлекләре чикле балаларга К. Насыйри иҗат иткән чор мохитен яхшырак күзалларга, абстракт фикер йөртү эшчәнлеген яхшыртырга, эчке дөньяларын баетырга ярдәм итә.

К. Насыйри – гомере буе киңкырлы эшчәнлек алып барган, искиткеч талантлы мәгърифәтче. Бер генә дәрестә балаларга язучы шәхесен, аның мәдәни-әдәби эшчәнлеген бөтен тирәнлегендә, төрле ракурста җиткерү мөмкин түгел. Шуңа да К. Насыйрига багышланган дәресләрдә авторның биографиясе белән укучыларны өлешләп таныштыру мөһим. Беренче дәрестә, мәсәлән, бөек мәгърифәтченең тормыш юлы гомуми, җиңеләйтелгән планда яктыртылса, алдагы дәресләрдә балаларның игътибарын К. Насыйриның әдәби, мәдәни һәм гыйльми эшчәнлегенә юнәлтергә, аның китаплары белән таныштырырга мөмкин.

Балалар галимнең кул хезмәте белән шөгыльләнүен, ял вакытларында үзе өчен кирәк булган көнкүреш әйберләрен барысын да үзе ясавын, бастырган китапларын да үзе төпләвен, агач эшен бик яратуын, карта сызу, рәсем төшерү кебек катлаулы эшләргә сәләте булуын да бик кызыксынып тыңлыйлар.

Белемнәрне ныгыту, татар һәм рус балаларында татар мәдәниятенә һәм әдәбиятына кызыксыну уяту, күзаллауларын киңәйтү максатыннан укучыларга мөстәкыйль эзләнү-тикшеренү таләп иткән, зур булмаган проектлар тәкъдим итәргә мөмкин. Мисал өчен, «К. Насыйри – атаклы галим», «К. Насыйри төзегән сүзлекләр», «К. Насыйриның өстәл календаре», «Әгәр мин Әбүгалисина булсам» һ.б. Гомумән, физик мөмкинлекләре чикле балаларны

укыту процессы укучыларга индивидуаль якын килүне таләп итә. Шул сәбәпле, мондый биремне укучыларга тәкъдим иткәндә, укытучы, һичшиксез, баланың мөмкинлекләрен истә тотарга тиеш.

Бүгенге көндә К. Насыйри иҗаты буенча шактый мәгълүмат табарга мөмкин. Шулар нигезендә мәгърифәтче иҗатына багышланган слайдлар эшләнә, презентацияләр ясала һәм дәресләрдә актив файдаланыла. Бу балаларда дәрес материалын үзләштерүне күпкә җиңеләйтә, аларның сүзлек запасын арттыра, бәйләнешле сөйләмен үстерүдә ярдәм итә.

К. Насыйри иҗатына багышланган дәресләрдә балалар белән өйрәнелгән материалны ныгыту, фикерләү сәләтен үстерү өчен төрле биремнәр үтәү мөһим. Мисал өчен, тексттан планга туры килгән абзацларны табып уку; план нигезендә сөйләп карау, биографик моментларны яктырткан җөмләләрне татарчадан русчага тәрҗемә итү, К. Насыйриның тәрҗемәи хәленә кагылышлы җөмләләрне тулыландырып язу һәм уку һ.б.

Дәреслекләрдә К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»ннан өзекләр дә тәкъдим ителә. Без укучылар белән бергәләп әлеге өзекләрне кычкырып укыйбыз, текст белән эшлибез. Балалар текст буенча сорауларга җавап эзлиләр, үзләре дә катлаулы булмаган сораулар төзеп иптәшләренә әйтәләр. Дәрестә аңлашылмаган, әйтелешләре һәм язылышлары катлаулы сүзләрне дөрес итеп әйтергә, язарга өйрәнәбез, мәгънәләрен ачыклыйбыз. Гомумән, һәр биремгә иҗади якын килергә тырышабыз.

Темага бәйле өй эшләре дә укучыларның физик мөмкинлекләреннән чыгып индивидуаль бирелә: «Әбүгалисина кыйссасы» буенча рәсем ясарга, әсәр үрнәгендә кечкенә генә әкият язып карарга, эчтәлек сөйләргә, диалоглар төзергә һәм башкалар.

К. Насыйри – XIX йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң күренеклесе. Тел галиме, мәгърифәтче, педагог, язучы, фольклорчы һәм тәрҗемәче К. Насыйри эшчәнлегенең әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Каюм Насыйри – татар тел белеме үсешендә, грамматикалар төзү тарихында һәм татар мәдәниятен үстерүдә зур өлеш керткән шәхес. Мәгърифәтче татар халкының аң-белемен күтәрүгә күп көч куя. Галим иҗаты хакында балаларга сөйләгәндә, без боларга да басым ясыйбыз. Дәресләрдә К. Насыйри шәхесе үрнәгендә укучыларда кызыксынучанлык, максатчанлык, тырышлык, иҗадилык кебек сыйфатлар тәрбияләргә тырышабыз. Яшь буын,

һичшиксез, нинди милләттән булуына карамастан, бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган шәхесләр турында белеп, алардан үрнәк алып үсәргә тиеш.

**Әдәбият**

1. Асадуллин А. Каюм Насыйри (Тууына 140 ел тулу уңае белән) // Совет мәктәбе. 1965. № 2. 15–16 б.

2. Гайнуллин М.Х. Каюм Насыйри (Тормыш һәм иҗат юлы. Тууына 150 ел тулу уңае белән). Казан. Татар. кит. нәшр., 1975. 36 б.

3. Гайнуллин М.Х. Каюм Насыйри (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан. Татгосиздат, 1948. 146 б.

4. Мамайчук И.И. Психологическая помощь детям с проблемами в развитии. СПб.: Речь, 2001. 220 с.

5. Левченко И.Ю., Приходько О.Г. Технологии обучения и воспитания детей с нарушениями опорно-двигательного аппарата: Уч. пособие для студ. сред. пед. учеб. заведений. М.: Издательский центр «Академия», 2001. 192 с.

## LEARNING KAYUM NASYRI'S WORKS IN SPECIAL (CORRECTIONAL) SCHOOLS

***Shaykhutdinova Gulfia Sahabettinovna,***
*the teacher of the Tatar language and literature*
*of the Kazan special correctional school № 4,*
*gsalina75@bk.ru*

The article is dedicated to learning of works of Kaum Nasyri in the special (correctional) schools. Author pays attention to the physiological and psychological aspects of pupils with the special needs. The importance of combination of development of the children's communicative skills, enriching emotional experience and thinking abilities is especially emphasized.

***Keywords:*** special (correctional) schools, Kayum Nasyri, Special needs education, thinking abilities.

УДК 821.512.145

# МИЛЛӘТ САГЫНДА ТОРУЧЫЛАР

***Васильева Ирина Ивановна,***
*ТР Зәй муниципаль районы 6 нчы номерлы*
*урта гомум белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*irina23.72@mail.ru*

Мәкаләдә дин мәсьәләсе, милләт язмышы, телне саклау һәм экологик проблемаларның татар әдәбиятында яктыртылышы мәсьәләләре күтәрелә. Шулай ук татар әдипләре иҗатының иң яхшы үрнәкләре мисалында XX гасыр ахыры – XXI йөз башы әдәбиятының кайбер үзенчәлекләре, актуаль мәсьәләләре билгеләнә.

***Төп төшенчәләр***: татар әдәбияты, туган тел, экология, әдәбиятта дини темалар.

Бүген РФ составындагы барлык әдәбиятлар, бигрәк тә татар һәм рус әдәбиятлары, эзләнү, үсеш-үзгәреш чорын кичерә. XX гасырның соңгы чирегендә барган сәяси яңарыш әдәбият өлкәсенә дә тәэсир ясады: әдәби әсәр Матурлык, сәнгати Камиллек, Әхлакый бөтенлек ноктасыннан бәяләнә башлады. Максатыбыз – XX гасыр ахыры – XXI йөз башы әдәбиятында күтәрелгән проблемаларны танылган татар әдипләре иҗатының иң яхшы үрнәкләре мисалында яктырту.

XX гасыр башында татар әдәбиятында күтәрелгән проблемаларның күбесе бүген дә актуаль. Шулар арасында дингә караш мәсьәләсен атарга мөмкин. Хәзерге әсәрләрдә, дини караш ялтырап ятмаса да, үзенең барлыгын сиздерә. Дини тормышны тулаем сурәтләгән әсәрләр булырга тиеш. Чөнки әдәбият – иң яхшы идеология коралы. Тик әле халык мондый әсәрләрне кабул итәргә әзер түгел. Күбесе, совет чорындагы әдәбият укып үскәнлектән, дини әсәрләрне вәгазь буларак кына кабул итәләр. Тик иртәме-соңмы, халык бу төр әсәрләргә таба борылыр дип уйлым. Чөнки

халык акрынлап дингә якыная, аның җанына шифа бирерлек әсәрләрнең кирәклеге шиксез [1: 34].

Билгеле булганча, XX йөз башы татар әдәбиятында милләт язмышы проблемасы еш күтәрелә. Милләт язмышы хакында уйланулар бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Татар милләтенең киләчәге бармы? Ул өметлеме? Гасырлар буе үзенә дәүләтчелек даулаган халык үз Ватанында мөстәкыйль тормыш алып бара алырмы? Телебез югалмасмы? Халыклар аренасында татар милләте лаеклы урынын алырмы? Менә шушы мәсьәләләр бүгенге аек акыллы яшь буынны, шул исәптән мине дә, борчый.

Милләт мәнфәгатьләрен кайгырткан, аның үткәнен,бүгенгесен бөтен барлыгы белән чагылдырган әдипләрнең берсе Фазыл Шәех иҗатына тукталасым килә. Ул гомер буе үз халкын көрәшергә, мескен булмаска өндәгән, рухи яктан көчле итеп тәрбияләргә теләгән. Мондый кешеләрне милләтнең каһарманы дип атыйлар. Тарихка әнә шулай зур өлешен керткән кеше ул [3: 65].

Татар милләте күпме изелүләргә дучар ителеп тә, бүген исән-сау икән, ул шулай ук Г. Исхакый кебек бөек шәхесләренә бурычлы, минемчә. Ул үзенең иҗатында татар милләтенең язмышы өчен борчылып кына калмыйча, ничек милләт буларак сакланып калырга икәнлеген дә күрсәтә. Чөнки милли үзаңы югары булган кеше генә шәхес булып формалаша ала. Әдипнең иҗатында чагылыш тапкан милләт мәсьәләсе бүгенге заман әдәбиятына да хас. Телебезне, динебезне саклап калуның киләчәк буыннар өчен нинди әһәмияткә ия булуын һәрберебез яхшы аңлыйбыз. Әгәр дә телебезгә, динебезгә хыянәт итәбез икән, милләтебезнең юкка чыгуына юл куябыз дигән сүз. Г. Исхакый кебек бөек шәхесләребезнең әсәрләре милләтебезне саклап калырга ярдәм итәр [4: 87].

Якташыбыз шагыйрь М.Әгъләмов татар шигърияттен үзенчәлекле иҗат мирасы белән баеткан, сүз сәнгатебезне алга таба үстерүче, аның милли рухлы традицияләрен дәвам иттерүче шагыйрьләрнең берсе булып тора. Аның поэзиясенә музыкальлек, классик татар поэзиясе һәм халык иҗаты традицияләреннән үсеп чыккан табигыйлек, эчке бер моң хас. Кечкенә генә поэтик деталь аша ул туган ил, милләт язмышы, аның үткәне, бүгенге хәле, киләчәге турында укучыны тетрәндерерлек гомумиләштерүләр ясау осталыгына ия.

Бүгенге көндә халык язмышы, телне саклау проблемалары үзенә зур игътибар таләп итә. 90 елларда кабынып киткән милли хәрәкәт, милли үзаң хәзерге вакытка әкренләп сүрелеп, югалып бара. Шушы ситуациядә татар халкын, телне саклап калуда шигърият үзенең зур ролен башкара, чөнки шигырьләр укучы күңеленә яхшырак сеңә, аларның укучыга тәэсир итү көче әдәбиятның башка жанрларына караганда күпкә ныграк. Аерым алганда, Ренат Харисның әлеге проблемаларга багышланган шигырьләрен укучылар арасында пропагандалау уңышлы нәтиҗәләргә китерер дип саныйм [6: 97].

Шунысы игътибарга лаек, Р. Харисның халыкка, телгә багышланган шигырьләрендә беркайчан да төшенкелек тойгылары чагылмый. Татар халкы изелгән, инде үлем хәлендә, мескен халык булып яши һ.б. кебек фикерләрне Р. Харис шигырьләрендә гомумән табып булмый. Ул һәрвакыт оптимистик рухта, якты киләчәккә өметләнеп яза, аның һәрбер шигыре күңелгә дәрт өсти, татар халкы киләчәгенә өмет чаткыларын уята [6: 103].

XXI гасырга без глобаль экологик проблемалар белән бергә кердек. Кеше үзен табигатьнең хуҗасыдай тоеп, аңа каршы чыкса да, бүген ул үзен табигатьнең бер кисәкчеге икәнен ниһаять таныды. Табигать җырчысы Г. Бәширов экология проблемасын XX гасырның 70 елларында ук күтәрә. Бу мәсьәлә хәзерге чорда бигрәк тә актуаль. Г. Бәшировның: «Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф-гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәҗрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи, әхлакый яктан рәнжетердәй башбаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшә», – дигән сүзләре бүгенге заман язучылары өчен дә эшкә чакыру булып яңгырый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: совет чорында милләт мәсьәләсен артык күтәрергә ярамаса да, Г. Бәширов, Ә. Еникиләр үз иҗатларында милләтебезнең матур гореф-гадәтләрен, асыл сыйфатларын саклап калу проблемасына мөрәҗәгать иттеләр, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, И. Юзеев һ.б.лар телебезне, табигатьне саклауга басым ясадылар, халыкны уятырга тырыштылар. Ә инде 90 нчы еллар башында сәяси, икътисади үзгәрешләр, борылышлар йогынтысында, татар халкының ачы язмышы турында уйланып, борчылып язылган, тарихи аң белән сугарылган шигырьпоэмалар, зур күләмле әсәрләр күбрәк күренә башлады. Әдәбият

милләт азатлыгын, татар телен, халыкның динен, гореф-гадәтләрен, меңәр еллар дәвамында камилләшә, чарлана килгән әхлак кагыйдәләрен саклау өчен көрәш юлына чыкты [5: 46].

**Әдәбият**

1. Әхмәтҗанов Р. Таш аргамак: Шигырьләр, поэмалар, балладалар. Казан: Татар.кит. нәшр., 2005. 274б.

2. Миңнуллин Т. Сайланма әсәрләр. Казан: «Хәтер» нәшр., 2008. 479 б.

3. Шәех Ф. Туган якның бер талы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 205 б.

4. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан, Татар. кит. нәшр.,1998. 191 б.

5. Шәех Л. Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 176 б.

6. Харис Р. Хәл-әхвәл. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 207 б.

## DEFENDING THE NATION

***Vasil'eva Irina Ivanovna,***
*the teacher of the Tatar language and literature*
*of the school № 6, Zainsk, Republic of Tatarstan,*
*irina23.72@mail.ru*

Paper analyses the religious topics, national revival, preserving of native language, ecological problems and other topics featured in Tatar literature. Author examine the key aspects of the modern Tatar literature.

***Keywords:*** Tatar literature, native language, ecology, religious topics featured in literature.

# СОДЕРЖАНИЕ

# ЭЧТӘЛЕК

## I. Научно-педагогическая деятельность Каюма Насыри

## Каюм Насыйриның фәнни-методик эшчәнлеге

*Шәкүрова М.М.* Каюм Насыйриның фәнни-методик эшчәнлеге ........ 3
*Батыршина Г.Г.* Татарская грамматика Каюма Насыри ........ 8
*Шәймәрданов Р.Х.* Габделкаюм Насыйриның иҗаты һәм эшчәнлегенең бүгенге көн әһәмияте ........ 13
*Хөснетдинов Р.Р.* Каюм Насыйри институтының татар теле укыту өлкәсендәге эшчәнлеге ........ 25
*Абызова Р.Р.* Влияние творчества Саади на формирование педагогических и просветительских взглядов Каюма Насыри ........ 30
*Яруллина Л.И.* К.Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә һәм «Ләһҗәи Татари» сүзлегендә сузык авазларның язуда бирелеше ........ 36

## II. Из истории преподавания татарского языка и образования на татарском языке

## Татарча белем бирү һәм татар телен укыту тарихыннан

*Шамсутдинова Р.Р.* Учебная литература для татар (XIX век) ........ 44
*Салахова Э.К.* Опыт создания учебных пособий у татар в конце XIX – начале XX века: деятельность Г.Н.Ахмарова ........ 51
*Ахтямова А.В.* Преподавание на татарском языке и татарского языка в 1920-х гг. ........ 58
*Шакирзянов Р.А.* Высшее строительное образование на татарском языке: история, настоящее и будущее ........ 68

*Мортазина Л.Р.* Ана телендә югары белем бирү мәсьәләләре (1990–2005 еллар) ... 83
*Туктамышов Н.К.* Новые времена, новые измерения родного языка в высшем образовании ... 94
*Салехова Л.Л.* О когнитивных издержках билингвального обучения средствами русского и татарского языков ... 106
*Садыйков Ш.Ф.* XX гасырның 20–30 елларында Татарстанда югары белем бирүнең торышы ... 116

## III. Актуальные проблемы преподавания татарского языка и образования на татарском языке

## Татарча белем бирү һәм татар телен укытуның актуаль проблемалары

*Харисова Ч.М.* Тел дәресләрендә нәтиҗәле чара ... 125
*Исхакова З.А.* Учебники по татарскому языку для русскоязычных учащихся как средство формирования билингвальной личности. ... 132
*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы ул – сөйләмгә өйрәтүнең нигезе ... 139
*Айдарова С.Х.* Заманча технологияләр куллану – дәүләт йомгаклау аттестациясенә уңышлы әзерлек чарасы ... 147
*Лотфуллин М.В.* Россия шартларында татар телендә уку әсбаплары әзерләү юллары ... 157
*Яруллина Ф.М.* Рус телле укучыларда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә мәдәни компетенция формалаштыру ... 160
*Нәбиуллина Т.Г.* Татар теле һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлеген үстерү чарасы буларак заманча технологияләр ... 167
*Шәйхетдинова Г.С.* Махсус (коррекцион) мәктәптә Каюм Насыйри иҗатын өйрәнү ... 174
*Васильева И.И.* Милләт сагында торучылар ... 178

**Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы**

*Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 15.10.2015 г.  Формат $60\times84\ {}^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 11,5   Тираж  100 экз.

Отпечатано в множительном центре Института истории АН РТ
г. Казань, Кремль, подъезд 5. Тел. (843) 292-95-68, 292-18-09

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф